ВӘКИЛ БЕЛАЛОВ

# Серне чишсәң дә була



ВӘКИЛ БЕЛАЛОВ

# СЕРНЕ ЧИШСӘҢ ДӘ БУЛА

Шигырьләр, хикәяләр

БРның "Нефтекама шәһәр типографиясе" ДУП
2004

УДК 82-1/-3=943.21
ББК 84(2РОС.ТАТ)
Б43

Әлеге җыентык миңа гомер бүләк иткән
изге җанлы әнкәем рухына багышлана.

Вәкил Белалов

**Белалов В.С.**

Б43 "Серне чишсәң дә була": Шигырьләр, проза / В.С. Белалов. – БРның "Нефтекама шәһәр типографиясе" ДУП, 2004.–116 бит.:ил.
ISBN 5-900898-34-2

Вәкил Белаловның бу китабы лирик һәм сатирик шигырьләр, прозаны үз эченә ала. Автор озак еллар эчке эшләр бүлегендә эшләгәнлектән, хикәяләрендә җинаять эшләрен ачу темасын оста яктырта. Шулай ук мәхәббәт темасы да ят түгел аңар.

В.С. Белалов күптөрле проблемаларны күтәреп, чишү юлларын күрсәтергә омтылуы белән укучылар күңелен яулар дигән ышаныч зур.

УДК 82-1/-3=943.21
ББК 84(2РОС.ТАТ)

ISBN 5-900898-34-2

© Белалов В.С., 2004
© Оформление. ГУП РБ "Нефтекамская городская типография", 2004



Вәкил Сәләх улы Белалов Яңавыл бистәсендә 1934 елның 27 мартында крестьян гаиләсендә дөньяга килә.

Яңавылда 1-нче санлы мәктәпне тәмамлаганнан соң, Уфа авиация институтына керү өчен имтиханнар тапшыра. Сугыштан соңгы елларда бөтен халык матди яктан авырлык кичерә, әлбәттә, Белаловлар гаиләсенә дә җиңел булмый. Шунлыктан Вәкилгә, укуын ташлап, Свердловск өлкәсе Березовский шәһәрендә Киров исемендәге рудникка эшкә керергә туры килә, ул анда электровоз машинисты була.

Туган як үзенә тарта, һәм Вәкил кайтып, Тәтешле районындагы Әрибаш урман училищесын тәмамлый һәм Зилаер районындагы Кананикольский леспромхозына эшкә җибәрелә. Соңрак туган җиренә кайтып, нефтьче булып эшкә урнаша. Аннары комсомол кушуы буенча эчке эшләр бүлегенә бара.

1964 елда Саратов хәрби училищесын тәмамлап, туган шәһәрендә ГАИ начальнигы булып эшли. 1972 елда Нефтекамага килеп төпләнә. Шул ук елда Краснокама районы оештырылгач, ГАИ начальнигы итеп билгеләнә.

Вәкил Сәләх улы читтән торып Уфа авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлый.

1993 елда хаклы ялга чыга. Шуннан соң да ун ел буе РОСТОның Краснокама бүлекчәсендә укытучы булып эшли.

Мәкалә, хикәяләр, шигырьләр язу белән мәктәп елларында ук мавыга. “Яңавыл таңнары”, “Алга”, “Кызыл таң”,“Кама таңнары”, “Өмет” гәзитләрендә чыгыш ясый. Якташы Низам Хәмзин оештырган “Инеш” иҗат берләшмәсе әгъзасы ул.

Вәкил Сәләх улына алдагы иҗатында да зур уңышлар, үткен каләм телибез. Каләме очыннан тамган шушы серләре шигырь сөючеләрнең күңеленә үтеп керер, ул гына да түгел, проза өлкәсендә яңадан яңа серләре дөнья күрер, дип өметләнәбез.

*Нәзирә Газизова,*
*“Инеш” иҗат берләшмәсе әгъзасы.*

## Акчарлаклар

Кама ярыннан торып күзәтәмен
Акчарлакның уктай атканын.
Ничек итеп аның тукланганын,
Яшәр өчен азык тапканын.

Акчарлакка беркем азык бирми,
Үзе таба, үзе эзләнә.
Кеше дә бит шулай, акчарлактай
Тырыша көн дә, шулай эзләнә.

Яшәр өчен тырышып дөнья көтә,
Тормыш дулкынында йөзә ул.
Үтә кыен, хәтта авыр чаклар,
Читенлекләр оч(ы)рый, түзә ул.

## Авыр икән көтүе

Күл өстенә килеп төште
Акчарлаклар көтүе.
Авыр икән озак күрми
Өзелеп, сагынып көтүе.

Әллә өзелеп яратканга
Төшемдә сине күрәм.
Күңелем болыны түреннән
Чәчәкләр җыеп бирәм.

## Ачы җилләр

Нинди ачу тотып җилләр
Тәрәзәмә кагасыз?
Керле күңелләрнең үчен
Әллә миннән аласыз?!

Кыйбладагы кискен җилләр
Бигрәк ачы искәндә.
Йөрәкләрем әрнеп куя
Бюро җиле искәндә.

## Болын чәчәкләре

Болын чәчәгенең хуш исләрен,
Искән җилләр аша җиткерсәм,
Чәчәкләрен үзем бүләк итәр идем
Өметемдә үзеңне күрсәм.

Сиңа җыеп бүләк итәр идем
Болындагы барлык гөлләрне.
Кабул итеп алсаң чын күңелдән
Онытмыйча шатлык көннәрне.

## Гайбәтчеләр

Хәйләкәр гайбәтчегә карап,
Ни уйларга белмисең.
Кәеф бозыла, күңел төшә
Әллә ниләр уйлыйсың.

Шундый чакта син ышанып
Сер сөйләмә аларга,
Алар керә йөрәгеңә
Серләреңне алырга.

Алар сизә, кулын суза,
Имеш, бирә йөрәген.
Боза, көлә, аерттыра
Эшли үзенә кирәген.

Гайбәтче ул явыз кеше.
Синнән ньк көнләшәдер
Әшәкелек теләп сиңа,
Җыелып серләшәдер.

## Күбәләк карлар

Әле генә коеп яңгыр узды.
Күбәләк карлар тиздән очтылар.
Сызгырып узган көзге ачы җилләр
Шәрә каеннарны елап кочтылар.

Котырынган җилдә күбәләк кар
Күзгә күренеп җирдә югалды.
Ермалак булып, эрегән карлар,
Инешләргә таба юл алды.

## Гаделсезлек

Гаделсезлек сөргән чорда
Гаепләндем бер дә юкка,
Ябыштылар каты итеп
Гаебеңне таны, диеп.

Сигезаяк хайван сыман
Чолгадылар кайсы каян.
Кыямәт көндәй кыйландылар
Төрле чара кулландылар.

Козгын өередәй ташландылар.
Хис иттем, газапландым.
Нәфрәт туды үзләренә,
Карап хәсис йөзләренә.

Дәрәҗә төшкәч гаҗәпләндем
Сәер булды күңелемә:
Яман дуслар читләштеләр,
Якыннары чикләштеләр.

Озак еллар бәхәсләштем.
Шул дәвернең тәртибендә.
Алдыма куйган максатымнан
Чигенмәдем авыр көндә.

## Көзге каеннар

Каеннар да тигез саргаймыйлар:
Берсе сары, берсе яшел төс.
Әфлисун төсендә калганнары
Ифрат матур быел көз.

## Көнбагышларым

*(Җыр)*

Көнбагышларга сөенеп карап,
Сокланам хәтсез күпкә.
Үзләренә хас матурлык
Балкыйлар зәңгәр күктә.

Хуш исләрен сибә таңда.
Нур чәчә көнбагышлар.
Серләшәм мин алар белән
Таралсын, дип сагышлар.

Әйтерсең алар сөйләшә,
Барчасы җыелып бергә.
Аңларга теләп уйларны,
Кушылып минем сергә.

Сылу кызлар арасында
Торгансыман хис итәм.
Берсен генә алып кулга
Сөйгәнем төсе итәм.

*Кушымта:*

Көнбагыш, көнбагыш,
Арчала хәсрәт-кайгыдан.
Китерә күрмә сагыш.

## Айлы төндә

Җәйге көндә, аяз төндә
Балкый күктә тулган ай.
Шатлыклы миңа елмая
Мине күптән белгәндәй.
Озак кына басып тордым.
Кыенсынып сорарга
Ничек кыюлыгы җиткән
Зөһрә кызны урларга?
Түзә алмадым бирдем сорау
Ничек итеп кыз алдың?
Ничек итеп сылу кызны
Син караттың, ала алдың?
Көлемсерәп ул аңлатты,
Күз төшкәнен сылуга.
Нурлар сипкән Зөһрә кызга
Чишмәгә килгәч суга.
Гүзәл, нәфис гәүдәсенә
Гашыйк булган, күз салган.
Көянтә, чиләкләреннән тотып,
Яраткан кызын алган.

## Зариф мулла вәгъдәсе

Хыянәт кылганга Зарифны
Дәрәҗәдән кактылар.
Чолгап алган якыннары
Төрле якка качтылар.
Кайгы, хәсрәт кичергәндә
Куылгач түрә эшеннән,
Файда күрде көтмәгәндә
Кимсетелгән кешедән,
Кире кайтты вазыйфасына
Гаять зур файда тигәч.
Шәфкатьлегә вәгъдә итте
Табында, түрәләр җыйгач.

Исемем Зариф булмас, диде
Үз сүземдә тормасам,
Кимсетсәм кабат яңадан
Булышмасам, хурласам.
Ит изгелек – көт явызлык,
Дип әйтелгән мәкальдә.
Мәкальне юньсез Зариф
Раслады һәрхәлдә.
Күтәрелгәч дәрәҗәгә
Мәхмүт җырын җырлады.
Вәгъдәсен салып таптады,
Үз сүзендә тормады.

## Матайкаем

Коммунистлар заманында,
Мотоцикл сирәк иде,
Кибетләрдә сатылмады.
Ә миңа кирәк иде.
Шул заманда матай алдым,
Ботарланган, череп беткән.
Яраксыздан төсе киткән,
Ташланырга вакыт җиткән,
Көнчелләре ашыктылар
Имзасыз хатлар язып.
Ачык көнләп күрәлмичә
Нахакка бәла ягып.
Райкомдагы имзасыз хат
Тиз тартылды тегермәндә.
Җәза булды минем өчен
Азык булды каһәрләргә.
Рәнҗедем мин андыйларга,
Нахак бәла якканнарга.
Булсын әйдә миннән дога
Каберендә ятканнарга.

## Оҗмах түрен күрерсең

Кереп күңел бакчасына
Гөлләренә үрел син.
Сулар сибсәң, шиңдермәсәң,
Оҗмах түрен күрерсең.

Гөлләреннән букет җыеп,
Кысып ал кочагыңа.
Кулларыңнан ычкындырма,
Ярсып сөйгән чагыңда.

## Сынау

Кыйбладагы кискен салкын җилләр
Яшь имәнне кысып селкетә.
Селкетә дә коя яфракларын,
Шәрә калдырып, көлеп кимсетә.

## Серле карашың

Күңел киштәсенә үрелдең
Йөрәктән ялкын алганда.
Мәхәббәтең ташып шашынганда,
Бергә чакта, якын булганда.

Нурлар чәчеп елмайганда
Кузгаттың йөрәк хисен.
Яратам, дип әйтүләрең
Шикле ул минем өчен.

Серле салып карашыңны
Нигә мине караттың?
Мин алданып сүзләреңә
Өзелеп, чиксез ярattым.

## Серләшәм төрле хакта

Ак каенны кысам, кочам
Серләшәм төрле хакта.
Җәйдәге яшел күлмәге
Сарыга кергән чакта.

Яфраклары әфлисун төстә
Эленгән матур чуктай.
Сокланып сөйгәнгә әллә
Гүзәлем истән чыкмый.

Хыялымда очып йөрим,
Ак каенымны эзлим.
Хисләремдә адашамын,
Адашканымны сизмим.

## Сандугачым

Сандугач баласын күрдем
Өнемдә, төштә түгел.
Кул суздым тотарга теләп,
Булмады, төште күңел.

Алма агачына кунып
Сайрады да ул очты.
Калдым карап, ямансулап,
Моңсуланып шул кичне.

Чыкмады озак күңелдән
Өзелеп-өзелеп сагынгач.
Кире килде язлар белән
Очып киткән сандугач.

Көтмәгәндә кунды килеп
Сайрады ул тагын да.
Сокланам мин сайравына
Матур язның таңында.

## Төнге учаклар

Онытылмас, калыр күңелдә
Төнге яккан учаклар.
Күктә йолдызлар санап
Хыялда очкан чаклар.
Теплоходка куллар болгап,
Яңгыратып, уйнап, көлгән.
Кама дулкынында тирбәлеп,
Саф суларында йөзгән.

## Төпчек кызым Гөлнара

*Әткәй миңа мирас итеп яшәү биргән.*
*Сиңа да мин яшәү бүләк иттем, балам.*

Тәрәзә кагып сызгырсалар җилләр,
Уятсалар таңда сөйгән баламны,
Минем өчен булыр чиксез шатлык
Тапшырсалар котлап сәламне.
Туган якның талгын таң җилләре,
Балкып чыккан кояш нурлары
Озата барсын тормыш юлларында,
Назландырсын күңелең җырлары.
Сөекле кызым, минем төпчек кызым,
Сылу кызым минем Гөлнарам,
Саф йөрәктән изге теләк телим
Якты булсын киләчәк көннәрең.
Ак бәхетләр, шатлык, куанычлар
Телим сиңа туган көнеңдә.
Күңелең чиксез сөенечтә үтеп
Тыныч көннәр торсын юлыңда.

## Туган ягым

Туган ягым гаҗәп сокландыргыч,
Яратам аны шунда яшәгәч,
Табигатен тиңлим курорт-илгә,
Дөресе дә шуңа охшагач.

Кама буйларына хәйран калам,
Һәрчак килеп ял итәсең.
Шул ямьле җирдә гел дә.
Кояш нурларына иркәләнеп,
Комлы ярда ятып кызынып,
Зәңгәр күккә карап, саф һавада
Назланасың ямьгә кызыгып.

## Ялвару

Ач, ялангач сугыш елларында
Кулсыз Мулланурга бардым ялварып,
Тамак ялы өчен матур җәйдә
Көтү көттем яшьли ялланып.

## Скандинавия циклоны

Скандинавия циклонының
Аңлаешсыз агышы.
Табигать белән чикләшми
Салды майга сагышны.
Кискен җилләр килеп майда
Каты итеп истеләр.
Зыян салып күп нәрсәгә
Туздырдылар, киттеләр.
Узып киткәч бозлы яңгыр.
Көлде майның кояшы.
Тиздән чәчәккә күмелде
Шулчак дөнья җиһаны.
Күңелләрдә шатлык туды.
Куанычтык, сөендек.
Кабат койды карлы янгыр.
Узып китте, көендек.
Бу елның да табигате
Майга карашы сәер
Бәлки карашын үзгәртер,
Ходайга бирсәң хәер.

## Ялкын сибә йөрәгем

Тулган айдай нурлар чәчеп
Балкып торасың алда.
Күзләреңнән нур чагыла.
Йөзләрең – пешкән алма.
    Кышкы көннең салкынында
    Ялкын сибә йөрәгем.
    Алма кебек йөзләреңдә
    Шатлык, сөенеч күрәмен.
Киләчәктә сөендерсен
Айның якты нурлары.
Искә алып хәтерләтсен,
Бергә йөрегән юлларны.

## Яңавылым

И туган як, туган авыл,
Синең исемең Яңавыл.
Туган җирем, үскән җирем
Күңелләрдә кала ул.
    И туган як, туган авыл,
    Сагынам сине, Яңавыл.
    Сагынганда моңсу чакта
    Сагышларга дәва ул.
Хисләремдә сагынып кайтам
Туган як тугайларын.
Моңнарыннан чыга алмыйм
Сайраган тургайларның.

## Ялкыннарга салмасаң

Нурлар чәчеп елмайганда
Табалмыйм һич тә урын.
Яратам, диеп сөендерүең
Кузгатты йөрәк түрен.

Серле күзләреңне текәп,
Алдың ялкын йөрәктән.
Чәчәк атты мәхәббәтем
Килгәч әллә еракτан.
Күңел ишекләрен ачып
Кердең йөрәк түремә.
Киштәсенә гөлләр элеп
Шатлыгыңнан сүрелмә.
Мәхәббәт хисләре көчле
Сөйгәнеңне аңласаң.
Нык яратсаң чын күңелдән,
Ялкыннарга салмасаң.

## Закир карак

Мәрхүм Ясәви сер сөйләде миңа
Кордаш малае Закир хакында.
Закир авылдаш егете белән
Җинаять кылган үскән чагында.
Алдан куйган максат тотып
Закир һич тә куркып тормаган.
Кара төндә колхоз абзарыннан
Сбруйлар кереп урлаган.
Милициягә җиткәч җинаять эше
Чара калмагач котылып калудан,
Хөкем җәзасыннан куркып Закир
Чыгып качкан туган авылыннан.
Гизә торгач Ырымбур далаларын
ФЗОга барып эләккән.
Шунда комсомолга кереп Закир
Җинаятен җуеп югалткан.
ФЗО эшенең авырлыгын сизеп,
Егет партиягә тиз кергән.
Җаен табып Совет заманында
Закир партиядә тиз үскән.
Партшкола бетеп көчкә, көчкә
Алга киткәч эше мескеннең.

Райком секретаре дәрәҗәсенә җиткәч
Онытткан ул ничек үскәнен.
Анонимкага ышанып көн уздырып,
Тикшергән кешенең начар якларын,
Күм-күк иреннәренә "Беломор" кабып,
Өстәлгә салган полиартрит аякларын.
Югәмәш үрдәгенә әйләндергән мәсьәләсен
Үзенә кабул иткән кешеләрнең
Намуссызлык көчле урын алган.
Башына җиткән бик күп эшләрнең.
Язмыш кушты миңа шул дәвердә,
Югәмәш үрдәгенең итен ашарга.
Анонимкага карап, мәнсез Закир
Мәҗбүр итте читкә китәргә.
Калдырып киттем, сөйгән туган якны
Язмыш мине кире бормады.
Минем язмыш керде Закир кочагына
Миннән калып күп тә тормады.
Карман ГРЭСы тотып төзеделәр
Ямьле Бәдрәш авылы урынына.
Истәлеге калды шул авылның
Закир карак малай турында.

## Хыянәтчеләр

Урта мәктәп тәмамлагач,
Тискәре генә бер адәм.
Сәләтлеге булмаганга
Калган ул яшьли надан.
Җиңел генә эш башкарып
Дәрәҗә алмакчы булган
Мәгълүматен арттырырга
Төрле чаралар корган.
Хезмәттәшләре белән серләшкәч
Сүз йөретергә яраткан.
Түкми, чәчми әләкче чатан
Күп сүзләрне кабарткан.

Тора-бара күтәрелгән
Теләгән дәрәҗәгә,
Аның яманлыгы тарткан
Дусларын маҗарага.
Хуҗа белән тиз килешеп
Эшне җайга салган ул.
“Уңай”га киткәч эшләре
Гаделсез булып калган ул.
Хуҗа алдында тикшерүчегә
Сихри тәкъдим ясаган.
Машинага мохтаҗ түрәгә
Табабыз, дип масайган.
Безнең дуслар ышанычлы:
Берсе – Фарси, берсе – Хөрмәт,
Алар аша була эшләп
Машина тормый кыйммәт.
Түрәне тиз күнектерсәк,
Тикшерү уңай үтәр, дип.
Хөрмәттән машина алсак,
Эшләр шома китәр, дип.
Тотынганнар бар да бергә,
Гаделсез юл эзләргә,
Машинага акт язып,
Калганын тиз эшләргә.
Машинкада акт язып,
Печать табып алганнар.
Инспектор имзасын җайлап
Пыяла аша салганнар.
Эшләре “уңайга” киткәч,
Чатан иблискә әйләнгән.
Әзерләгәч кәгазьләрен
Хәйрүш белән бәйләнгән.
Әзер акт күргәч Хәйрүш,
Кул сузган бу хуҗага.
Болай булгач машина сездә
Борчылмагыз нуждага.

Кылган эшкә акланырга
Гыйләҗ кәгазьләр җыйган.
Шакирханга аңлатса да,
Хәсәннән күргән зыян.
Борынбай Хәсәнгә язган
“Эш зарар күрмәсен”, дип.
Озак еллар тикшерделәр
Кимчелек булмасын, дип.
Хәсән җыеп урынбасарын
Эш кузгатырга теләп,
Бойрык биргән тикшерергә
Уңай чыксын дип теләк.
Анонимка акланмады
Тикшерү озак үтте.
Эшләре зарарга чыккач
Хәсән дә тиздән китте.
Иблис, Хәйрүш һәм хуҗа
Хыянәтчеләр алар.
Кылган яманлыклар өчен
Ходай аларны җәзалар.

## Карлыгачым

Ташкын Танып ярның оясында
Карлыгачым туып көч алды.
Үсмер канатларын сынар өчен
Кама ярларына юнәлде.
Газиз якларыннан яшьли очкач,
Юксынмады сылу карлыгач.
Гаҗәп оя корып Кама буйларында
Шатланды ул пары табылгач.
Матур якта тапса да иркенлек,
Туган җирен өзелеп сагына.
Канатларын җәеп кайчагында
Очып килә үскән ягына.

Каты җилдә кара карлыгачым
Ярга сугылып бәрде канатын.
Имгәнсә дә, рухы булды сабыр,
Бәрелеп сугылмасын кабаттан.
Зәңгәр күккә менеп карлыгачым,
Искә төшереп яшьлек чорларын.
Бала карлыгачка таңда очып
Юл күрсәтә алда ни барын.

## Яшьлек уза

Яшьлек уза, гомер үтә,
Төрле уйлар башымда.
Әллә ниләр эшләп карыйм
Шушы өлкән яшемдә.

## Ак томан

Ак томаннарга карасам,
Пәрдә элгәнен тоям.
Сине бераз күрми торсам,
Ямансуланып куям.
Шул томаннар арасыннан
Син килеп чыгарсыман.
Көтеп торам, син чыкмыйсың,
Таралып бетә томан.
Кояш чыга, көн яктыра,
Син никтер күренмисең?
Күңелемдә ялкын булып
Янасың, сүрелмисең.

## Их, Бүә сулары

*(Җыр)*

Бүә сулары чишмә суыдай,
Үзе тонык, төбе таш.
Ярларына ялга кайтам,
Йөрәкләрем ашкынгач.

*Кушымта:*

Их, Бүә суларында
Рәхәтләнеп йөзәргә.
Сандугачлар булып сайрап
Үзәгеңне өзәргә.

Ярларында бөдрә таллар,
Өзелеп сайрый сандугач,
Сандугачларга кушылам
Алсуланып таң тугач.

*Кушымта:*

Их, Бүә суларында
Рәхәтләнеп йөзәргә.
Сандугачлар булып сайрап
Үзәгеңне өзәргә.

Бүә суы ташып ага
Язгы көндә боргылып.
Суларында йөзәр идем
Аккан чакта ургылып.

*Кушымта:*

Их, Бүә суларында
Рәхәтләнеп йөзәргә.
Сандугачлар булып сайрап
Үзәгеңне өзәргә.

## Пар умырзая

Пар умырзая ал төстә
Очраттым мин урманда.
Шул умырзаядай хис итәм
Сине уйлап торганда.



Кискен җилгә баш имичә,
Буйсынмый көрәштеләр.
Бер берен кысып кочакка
Елмаеп гөрләштеләр.
Шинделәр алар бервакыт,
Койдылар үз чәчәген,
Пар умырзаялар кебек
Белмибез киләчәген.

## Син гөлем, сипкеллем

Матур гәүдәләрең күз алдымда,
Адымнарың җитез, күңелле.
Якты чырайларың кояш кебек,
Тибрәтәләр ачып күңелне.
Эш сөюең, ихлас күңелләрең
Ачык, турылык сиңа хас кына.
Изге теләкле күңелләрең
Шәфкатьлегең шашып ашкына.
Кимсенмә син, бозма кәефеңне,
Бар бит диеп минем сипкелем.
Күпләр карап сиңа сокланалар,
Мәңге шиңмәс матур син, гөлем.

## Даян хәсрәте

Кабинетка чакырды Даян,
Керергә кушты тиздән.
Хөрмәтулла эше буенча
Начар хәбәрләр сизгән.
Ни эшләргә белми Даян
Гариф тамга салганга.
Аннан узып эш иткәнгә
Гыйләҗгә машина сатканда.
Петросян кыйланган кебек
Сикереп куя кайчакта
Кесәсенә тыга кулларын
Чалбары төшкән чакта.

Ленинга охшатып үзен
Йөри ул әрле-бирле
Бишмәтенә тыгып кулларын
Мине җинаятьчегә күрде.
Ярсып җикеренә ул,
Өстәлгә сугып кулын.
Гаепсез каласы килә,
Эзли аклану юлын.
Аңлаешсыз кыяфәт чагылды
Карашын почмакка салганда.
Акайтып карады күзләрен
Миннән аңлатма алганда.
Кычкырып көләсем килсә дә,
Тыелдым телне тешләп.
Шундый кешеләр түрә булып
Йөрделәр шулай эшләп.

## Таң чыклары

Урман аша үрелеп кояш чыкты
Аның нуры төште агачка.
Кояш нурларында таң чыклары
Энҗе кебек булды шул чакта.
Таң чыклары ялтырый төрле төстә
Алсу төскә кереп җанланды.
Тонык яшел төскә әверелеп,
Нәфис зәңгәр төскә әйләнде.
Гәрәбә сыман агачларны урап
Таң чыклары матур нур чәчте.
Яфракларда тагын кабатланып,
Көтелмәгән чиксез хис ачты.

## Трудармия

*Әтиемнең 100 яшенә*

Килешүне бозды Гитлер,
Яуларга теләп безне.
Нәни газизләрен калдырып,
Сакларга китте илне.

Башлагач дошман сугышны,
Авырлык илгә төшкәч,
Сборный пункт Алкинода
Җыйдылар Ватан кушкач.
Каты сугыш вакытында
Генерал Власов сатылды.
Шул генерал аркасында
Башкортка ярлык тагылды.
Башкортка кушамат тактылар,
Хурлыкта кимсеттелар.
Барысын төяп поездга,
Тылга алып киттеләр.
Китерделәр Чибәркүлдән
Аларны Чиләбегә.
Башланды хезмәт язмышы,
Керештеләр чиләнергә.
Кирәк булды алар шул чакта
Трудармия өчен.
Снарядлар әзерләделәр
Ватанга җиңү өчен.
Йөкләмәне арттырып үтәп,
Җиңүгә әзерләнеп.
Ачы, суык казармада
Яттылар җәберләнеп.
Озак еллар интектеләр.
Түзеп авырлыкларга.
Ачлыктан үлде күпләре
Соңгы сабырлыктан да.
Кырык җиденче ел җитте,
Гомерләр шунда үтте.
Көткән көннәргә ирешеп,
Кайтыр сәгатьләр җитте.
Иске-москы кием биреп
Зиндандагыдай йөзләре.
Эчкә батып зурайдылар
Авырлыктан күзләре.

Ходай язмасын күрергә
Трудармия эшләрен.
Күз алдында тора, чыкмый
Газапланган кешеләре.
Бюрократлар язган юлдан
Булмады гадел үтеп.
Җәфа, язмыш, хәсрәт бергә
Тордылар алда көтеп.

## Мәктәп еллары

Беренче мәртәбә киттем мәктәпкә,
Кердем барышлый дустым Әхмәткә.
Киндер букчамны тотып кулыма,
Теләк теләп калды әнием улына.
Укытучы керде, зифа, сөйкемле
Дәрес башлады беренче көнне.
Басып шатланып каршы алдык,
Чибәрлегенә хәйран калдык.
Елмаеп кына саулык сорады,
Утырыгыз, диде, озак тотмады.
Класска карап күзен ташлады,
Журналын алып дәрес башлады.
Исемен әйтте, Мөхлисә диде.
Укытучы булам мин сезгә инде.
Кап-кара чәче озын, биленнән,
Ялтырап тора үргән җиреннән
Киндер букчалар әнкәем теккән,
Хәзерге көндә тетелеп беткән.
Бик нык сагынам мәктәп юлларын,
Исемнән чыкмый тәүге елларым.

## Күбәләгем

Бер күбәләк килеп кунды,
Үзе сары сипкелле,
Фәрештәләргә охшатам,
Бигрәк матур, сөйкемле.

Сокланып сөйләшеп тордым,
Очып киткәнгә кадәр,
Сөйләдем мин серләремне,
Нигәдер, ачып аңар.
Аңламады, очып китте,
Барып кунды куакка,
Тирбәлде ул шул куакта,
Түзәлмәде озакка.
Соң аңлады минем уйны,
Тагын кунды ул килеп,
Кумадым, аңлагач серне,
Алдым кулга сөенеп.

## Юбилей

Рәсим, сине без котлыйбыз
Илле яшең тулганда.
Табының да әйбәт кенә
Үзең гади булганга.
Бүген оештырган мәҗлескә
Санга сугып килгәннәр.
Күрше-тирә, якын дуслар,
Яр Чаллыдан туганнар.
Котлап алгач юбилярны,
Күмәкләшеп җырладык.
Беребез дә кыенсынмый,
Тартынышып тормадык.
Гормунчы күтәреп күңел
Күчте бию көенә.
Кунаклар кызып киттелар
Бар да дәртле, сөенә.
Бер-бер артлы сүз алдылар.
Теләделәр теләкләр.
Теләк белән чын күңелдән
Тапшырдылар бүләкләр.

Озын гомер, тазалыклар,
Сәламәтлек шул теләк:
Тыныч яшә тормышыңда
Изге теләк – зур бүләк.

## Тукран тәүбәсе

Тукран кунган наратка
Тукылдый да тукылдый.
Агачка ачу тоткандай
Борны авыртканын тоймый.
    Артык тукылдаганнан соң
    Мие селкенә, күрәсең,
    Башы авырткач, туктап кала
    Тәүбә итә, күрәсең.
Баш авыртканы басылгач,
Тагын тотына, тукылдый.
Оныта, хәтере начар шул,
Кабатлангач уфылдый.

## Таныш кызы

*(Җыр)*

Танышларга барган идем,
Чумып су керермен, дип.
Өметләнеп күп йөрдем,
Сине бер күрермен, дип.
    Кара кашларың астында
    Кара күзләрең матур.
    Шул күзләрең күңелемне
    Ничек итеп юатыр.
Өметләрем, күңелләрем
Синдә генә, гүзәлем,
Сине озак күрәлмәсәм.
Юксынамын, түзәлмим.
*Кушымта:* Их, мәхәббәт, мәхәббәт,
Ни эшләттең, шуны әйт.

## Сәлим җизни

Сәлим җизни хаклы ялда,
Ул танылган Ветеран.
Аның әйбәт, уңган ягын
Үрнәк итеп китерәм.
Еш катнаша уеннарда:
Хәйран халык, түрәләр.
Моңлы, матур җырларына
Хөрмәт, бүләк бирәләр.
Җырлар җырлап сабантуйда
Өстенлек ала һәрчак.
Аның моңлы җырлаулары
Алда шулай булачак.
Беркайчан да боекмый ул,
Сөенеп үтә һәр көне.
Моңлы җырларын еш җырлап,
Сокландырсын һәркемне.

## Ак томаннар

Кама ярыннан торып күзәтәмен
Матур булып таңның атканын.
Су өстендә, яланнарда
Түшәк кебек томан ятканын.
Әкерен генә томан күтәрелә,
Күтәрелде, күккә таралды.
Ак томанга ияреп кыр-каз тавышлары
Һава ярып, ерак таралды.
Кояш чыгып томан күтәрелгәч,
Ачыкланды күлләр, яланнар.
Кама өстенә чыкты акчарлаклар,
Күренделәр җылым салганнар.

## Дуслар

Дуслар сынала ул кыен чакта,
Аларга син кирәк булганда.
Чынлап аңлыйсың үзләрен
Мәшәкатең килеп туганда.

Көзге кебек алар күренәләр,
Изгелекне шуннан аңлыйсың.
Керсезләре кала күңелдә,
Юньсезләрен кабат таныйсың.

## Күк күгәрчен

Күк күгәрченнәр гөрләде.
Килеп таңда кунып киртәмә.
Охшаттым моңлы гөрләүне
Өзелеп сөйгән иркәмә.

Сокланып карап утырдым
Тын калып бераз гына.
Гөрләүләре матур таңда
Булды миңа наз гына.

## Ал чәчәгем

*Шаян шигырь*

Ал чәчәкләргә охшатам
Карап сиңа сокланам:
Карт әтәчләргә тиңлисең,
Ярсыйм шуңа, хурланам.
    Күгәрченнәр күк гөрләшеп,
    Ахирәттәй серләшәм.
    Ачулы йөрисең озак
    Берәр сәгать күрмәсәм.
Яратам сине өзелеп,
Сандугачларга тиңләп.
Ә син мыскыл итәсең.
Сары чәчләрдән көнләп.
    Чибәр булып, сөйкемләнеп
    Күренәсең күземә.
    Ә мин инде карт маймылдай
    Күренәмдер үзеңә.

# Шофер

Бер көн шулай каты суыкта
Кайткан чакта Сибай юлыннан.
Машина сунде, һич кабынмый,
Рукояткалар төшә кулымнан.

Кыш көнендә тиз караңгы төшә,
Машинам да бетте суынып.
Аккумулятор да заряд бирми,
Агач кабинада утырам сыенып.

Тәннәр кызды бераз утыргачтан,
Кырын ятып йоклап киткәнмен.
Килеп берәү кабинадан тартып алган.
Үзем сизмим туңып беткәнне.

Арттан килгән шофер аңлап алган
Машина сүнеп нәрсә булганны.
Басарга тырышам, басып булмый,
Күреп тора минем туңганны.

Заряд бетте, машина сунде, дип
Анлатырга аңа тырышам.
Рукоят тотып мотор әйләндерәм
Кабынмагач үзем орышам.

Хәзер кабына, тизләт, әйләндер, ди
Ашыктыра мине, кыздыра.
Мин тизләтәм мотор әйләндерәм
Шулай итеп вакыт уздыра.

Сүтеп алды генераторны тиздән
Ватык җирен табып төзәтте.
Тагып өстерәп машина кабызгач,
Алтанайга кадәр озатты.

Тәннәр җылынды фуфайка эчендә
Боргалагач туңган рульне.
Шатлык керде йөзгә, йокы очты,
Бара торгач утлар күренде.

## Күрше карчыгы

*Шаяру катыш*

Бер кызны күреп урамда
Гашыйк булдым үзенә.
Шундый чибәр күренде ул
Сагыш тулды йөземә.
    Һушым китте, аң югалды,
    Авып киттем артыма.
    Аңга килеп, күзне ачсам
    Күрше карчыгы тора.
Чәчләрен кызылга буяп,
Битләрен майлап куйган.
– Ни булды? Улым, нишләдең? –
Дип сорап тора туган.
    Кара сөрмә сөртеп куйган
    Йолкып алган кашын да.
    Күз тирәсе зәңгәр буяу,
    Күн эшләпә башында.
Кыска юбка, югары тездән,
Кәкре тоткан таягы,
Инопланетяннныкыдай
Күренеп торган аягы.
    Бераз торгач сорау бирдем
    Әби, ник болай булдың?
    Рекламадан үрнәк алып,
    Шулай төзәндем, улым.
Әбекәем, алай йөремә
Ирләр урлап качмасын!
Юкка сарыф итеп йөрмә
Пенсияңнең акчасын.

## Скрипкам

Скрипкам бар чагында
Дус-ишләрем килделәр.
Өйрәт әле уйнарга, дип,
Теңкәләргә тиделәр.

Бик ялынып сораганга
Өйрәттем мин уйнарга.
Сер тотмадым үзләренә
Үзем гади булганга.
Скрипкам ватылган иде
Кирәкмисең, диделәр
Хак дустым дип йөрегәннәре
Кимсеттеләр, көлделәр.
Ташласыннар һич үкенмим,
Мохтаҗ түгелмен аларга.
Скрипкамның ватылуы
Ярдәм итте аңларга.

## Яңа ел бүләге

Яңа елны котлап килгән –
Кар күмелгән урамнан,
Адашмаган, курыкмаган
Котырынган бураннан.
Ашыкты, озак тормады
Котлады да ул китте.
Бик сөендем котлавына
Миңа шунысы да җитте.

## Үзсүзле хатын

Каты җилдә сакланмады карчык,
Юка киенеп йөрде өстенә.
Салкын бәрде, шул чагында
Кайгы керде аның төсенә.
Күпме ялынсам да тыңламады,
Бармыйм, диде дәваханага.
Үзең ят кирәк булса әгәр,
Тик сүз чыгарма балачагама.
Бер атнадан тәмам хәлсезләнгәч,
Эчкә баткач зәңгәр күзләре,
Сүз башлады дәвахана, диеп
Күм-күк булгач матур йөзләре.

Үзсүзлелек харап итә язды,
Көчкә алып калдык карчыкны.
Дәваланып, файдаланып калсын
Минем кебек картлар барчакны.

## Яңа ел теләкләре

*(Җыр)*

Яңа елдагы теләкләр
Кабул булсын, гүзәлем,
Киләчәк өметләремдә,
Хыялларда йөзәмен.

Сүрелмәсен гомереңдә
Сөюең ялкыннары.
Мәхәббәткә булсын бүләк
Йөзеңнең балкулары.

## Тибрәттең кылларымны

*(Җыр)*

Кереп күңел бакчасына
Үрелдең гөлләренә.
Оҗмах кызы идең мина,
Нур идең төннәремә.
Гел изгегә юрап йөредем
Мин күргән төшләремне.
Ялгызлыкка түзә алмый,
Җыр иттем хисләремне.
Кереп күңел бакчасына
Тибрәттең кылларымны.
Йөгәнләргә көчләр эзлим
Хыялый уйларымны.

## Туган җирем Яңавыл

Яшәгән җирем Башкортстан
Туган җирем Яңавыл.
Үскән җирем, сөйгән җирем
Аталардан калган ул.

Матур Буә елгасының
Суы тонык, төбе таш.
Истән чыкмый туган җирем,
Яшьлегем шунда узгач.

Язлар җиткәч тугайлары
Матурлана, ямьләнә.
Чәчәк-гөлләргә күмелеп
Оҗмах түренә әйләнә.

## Син ник күренмисең

Кояш чыга, көн яктыра
Ә син ник күренмисең?
Күңелемдә ялкын булып
Янасың, сүрелмисең.
Җәйнең ямьле көннәрендә
Кояш чыга алланып.
Мин нишләрмен син килмәсәң,
Калсам әгәр алданып?
Янган ялкын эчләрендә
Урын тапмыйм үземә.
Ал чәчәкләргә охшатам
Син күренсәң күземә.

## Минем холкымда казынма

Минем холкымда казынма,
Җентекләп керләр эзләп.
Кереп качма йөрәгемә,
Кирәкмәгәнне күзләп.

Холыксыз тискәрлегең
Кәеф боза, ярсыта.
Ялкынлы саф йөрәгемне
Әрнү бураны сыта.

## Рәйнә

*Онытым Рәйнәгә*

Бер яшь тулып китте
Онытым Рәйнәгә.
Күгәрчендәй тоела ул
Яраткан нәнәйләргә.
Житешмәгәне юктыр ла
Үрелә бөтен җиргә.
Терекөмештәй җитез бала
Һич утырмый бер җирдә.
Үзе матур, үзе җитез,
Үзе бигрәк сөйкемле.
Елмая, көлә, үрелә
Ят итми ул беркемне.
Һәрчак көлеп йөри өйдә,
Үзенә безне карата.
Барысыннан да бигрәк,
Карт әтисен ярата.

## Урман

Җирне ямьләп, үсә шаулап
Яшел урман, ямьле урман.
Биек таудай торган сыман
Анда каен, анда нарат
Омтыла күккә карап.
Ап-ак каен, бөдрә каен
Зифа каен, күркәм каен.
Сокланам мин күреп аны
Яшелләнеп торган саен.
Килеп чыккан кискен җилдә
Нараткаем, имәнкәем,
Горур тора җилгә каршы
Бөгелми ул, имгәнми ул.
Имәннәре бөгәлмәгәч,
Наратларым баш имәгәч,
Ярсу белән ташлап китә
Ачы җилләр. Җиңәлмәгәч.

## Хәерле иртә

Хәерле иртә, урманнарым,
Хәерле иртә, кояшым,
Хәерле иртә, сөеклем, сине
Янымда килә күрәсем.

## Мотор җыры

Шома оча машина асфальт юлдан,
Мотор җырлый капот астында.
Мин дә кушылам аның моңнарына
Газга каты итеп басам да.

Юл буенда картлар печән чаба,
Чалгылары ялтырый чапканда.
Энҗе кебек күренә таң чыклары
Покослары сызылып ятканда.

Кояш балкый ачык зәңгәр күктә.
Машиналар шашып узалар.
Юлда яткан силос саламнары
Кышкы буран сыман тузалар.

Гаҗәп матур юл буенда кала
Яшь наратлар, таулар, елгалар.
Күтәренке күңел, иминлектә
Маҗарасыз үтсен юлдагылар.

## Зифа каеннар

Язлар җиткәч яшел күлмәк
Кия зифа каеннар.
Бер берегездән аерылмагыз,
Күрмәң хәсрәт, кайгылар.

Көзләр җиткәч каеннарның
Үзгәрә сурәтләре.
Озак тора саргаймыйча
Аларның сирәкләре.

## Кар бабай

Кар бабай ясый балалар,
Чыланып беткән өсләре.
Шаяралар, куаналар,
Алма төсле йөзләре.

## Көз

Котырып җилләр исә көзен,
Кара болытлар куктә.
Көннәр ямьсез, ява яңгыр.
Сузылыр микән күпкә?

## Замполит

Замполит Вәсби малае
Нәтиҗә бирде Муллага.
Явыз, тәртип Бозучы, дип
Күрсәтте ул Бюрода*.
Этеп – төртеп гәзит чыгарттым,
Дип белдерде замполит.
Күрсәтергә теләп үз эшен
Бюрода масайды бик.
Бюро карары каты булды:
Җавапка тарттырдылар
Сүз бирмичә акланырга
“Смирно!” бастырдылар.
Көтү көтә, җаен тапкан
Замполитым Кузгауда.
Кыяфәте күп эчкәннән
Охшап беткән бозауга.

** Бюро – Бюрократларның*
*Ю – югары*
*Р – рангтагы*
*О – оешмасы.*

## Мәрхүм әнием

Мәрхүм әнием, күрдем сине төштә
Ак яулык ябынгансың.
Әллә инде син дә сагынып
Кайтсын дип чакыргансың.

Йокым качып уйлап яттым,
Кичереп үскән якны.
Күңел белән урап уздым
Авылны, балачакны.

Шунда керде башка уйлар:
Һич кичекми кайтырга.
Күңелемнең тойгыларын,
Әнием, сиңа әйтергә.

Кайттым, әнием, сине сагынып
Тоясыңмы минем килгәнне?
Беләсеңме аяк очларыңа
Ал чәчәкләр сиңа куйганны.

Фәрештәләр күбәләк булып
Оча кәбереңөстендә.
Әллә җаның йөри шулай
Күбәләкләр төсендә?!

## Кара чебен

Кара чебен керде йортка
Безелди дә безелди.
Җанга тия, һич туктамый,
Үзенең язмышын эзли.

Тәрәзә ачтым чыгарырга
Җәлләдем бичараны.
Кичердем, кудым, булыштым,
Кулландым бар чараны.

Очып китә, кире килә,
Безелдәүдән туктамый.
Тыелмый тискәре чебен
Һич тынмый, комачаулый.

Тынып тора кыска вакыт
Теңкәгә тагын тия.
Очып куна коштабакка
Нык ачу чыгып куя.
Кара чебен аңламады
Нык түздем, булдым сабыр.
Мәҗбүр итте кулланырга
Иң каты чара хәзер.

## Гөлчәчәгем

Гөлчәчәгем, матур чәчкәм
Бер генә син болында.
Ай нурлары булсын юлдаш
Гомереңнең юлында.
Йөзләреңдә нурлар балкый,
Сүзләрең көмеш чишмә.
Төннәреңдә уянамын,
Күрәм дә сине төштә.
Күзләреңнән күземне алмыйм,
Күзләрең зәңгәр чәчәк.
Көлүләрең якты кояш,
Чибәрем син, Гөлчәчәк.
Ташкын Танып суларыдай
Үтсен гомерең Гөлчәчәк,
Болындагы чәчәкләрдәй
Булсын синең киләчәк.

## Мәхәббәт тә булмый курыксаң гөнаһтан

Мәхәббәткә булмый киртә корып,
Тоткарлык та юк бит аңарга.
Әҗәлдән дә көчле, гөнаһтан да
Куркаклык та юк бит аңарда.

## Бюрокретин

РК КПСС, кечкенә бүлмә,
Идәненә палас җәелгән.
Уртасында тора озын өстәл,
Яшел сукно аңа җәелгән.
    Өстәл артында партнаданнар,
    Өсләренә кара кигәннәр.
    Чырайлары сөмсез, эчпошыргыч
    Барысы да кара, көйгәннәр.
Бюрода гаепләнгәч хаклы кеше
Басып акланырга тырышты.
Югарыда карамаслык итеп
Бюрокретин гаепләргә кереште.
    Аңларга теләп берсе сүз чыгарды,
    Ташландылар аның өстенә.
    Икенчесе җайлап аңлатса да,
    Кереттеләр кәльбин* төсенә.

**Кәльбин – эт төсе*

* * *

Җирне ямьләп, үсә шаулап
Ак каеннар, имәннәр.
Ак каеннар зифа буйлы
Матур күлмәк кигәннәр.

## БЮРО

Чатан Демьян
Бюро җыйган,
Карала мәсьәлә
Түрә куйган.
    Яман Демьян
    Ара-тирә
    Бюро барганда
    Күкрәк кирә.

Бюрода бары да
Кияү, туган,
Кода, баҗа
Зина кылган.
Эшне аңлап,
Шома Муса
Мәнсез түрәгә
Күзен кыса.
Үҗәт Локман
Күзлек кигән.
Борынын чокый,
Башын игән.
Тыныч утырган
Озын Мәгъсум
Ник катнашмыйдыр,
Килә беләсем.
Катнашмас иде
Болагай Миркасим,
Түрә кырында
Курка, күрәсең.
Минем тәртибем
Бик нык каралды.
Канәгать булып
БЮРО таралды.

## Кайчан җылытыр көннәр?

"Кайчан көннәр җылыта?" –
Дип сорадым мин Илгиздән,
"Каян белим! — диде күршем
Әллә бездән ул бизгән".
Икенче күршемнән сорыйм,
"Фәнил! Кайчан җылыта?"
Кызык кына әйтеп куйды:
"Күрәсең, кояш ял итә.

Ник сорыйсың! Җылытыр әле!
Август айлары җиткәч",
Көлеп әйтеп куйды карчык:
– Я, кырказ, торна киткәч.

## Сабырлыгыма киңәш

Сабыр булдым, түздем күбесенә,
Барган юлдан читкә чыкмадым.
Сабыр иткән морадына җиткән, диләр
Сүзеннән дә болай чыкмадым.

Сабырлыкка киңәш биргән өчен,
Алып аттым юлдан киртәне,
Үз моңыма фатыйхасын биргән
Юлдаш иттем матур иртәне.

## Кәккүк тавышы

Таң атканда, кәккүк  тавышы
Яңгыратты урманны,
Сихри хискә салып куйды,
Моңланып торганнарны.

Кабатлады,тыңладым да
Сагыш булып таммадым.
Гомеремнең агышларын
Барлаучы дип аңладым.

## "Инеш"

Таулар тишеп, тонык булып,
Чыгасың син ургылып,
"Инеш", "Инеш" – көмеш чишмә,
Ялтырыйсың нур булып.
Сиңа килеп һәммәсе дә
Илһам алырга тиеш.
Каурый каләм бир кулларга
Иҗат чишмәсе – "Инеш".

***

Бер күрүдә яраттым мин,
Сокландым йөзләреңә.
Каш астыннан карап торган
Елмайган күзләреңә.

Ике күзең йолдыз кебек,
Балкып тора янымда,
Хыял утларында янам
Бер елмаеп алдың да...

Ерак мәхәббәт утының,
Ялкыннары көйдерә.
Буран өелә йөрәккә,
Бетереп булмый көрәп тә.

## Җәннәт Әль Асма

*Әнкәемнең 100 яшенә*

Гасырлар алышынганда,
Дөньяга килде Җәннәт,
Язарга булдым утырып,
Кичергәннәрен җәлләп.

Матур гына, үсмер чакта
Ата-анасыз калды.
Карарга алты ятимне,
Үзе өстенә алды.

Революция елларында,
Ач, ялангач торганда,
Адашкан чаклары булды,
Ачы җилле буранда.

Коточкыч ачлык елларга,
Яшьлеге туры килде,
Авыр көннәрдә сызланып,
Яшәде бөгеп билне.

Аны язмыш каты кысты,
Ачлык кулына ташлап.
Әҗәл арбасыннан котылды
Кәлҗәмә, үлән ашап.

Маңгаена язылганга
Җәфа этте артыннан,
Кулын тотып житәкләде,
Кисте юлын каршыдан.
Сүз әйтмәде, рәнҗемәде,
Оҗмахка сөенеп керсен,
Әниемнең изге җаны
Җәннәт түрендә булсын.

## Йолдызларга очардай булам

Сокланамын күккә карап,
Энҗе карлар очканда,
Йолдызларга очардай булам
Кысып сине кочканда.
Күңелләрең саф су сыман,
Сабырлыгың таш сыман.
Серләшүең нәкъ сандугач,
Сайрап торган кош сыман.
Кил әле, кочып үбәем,
Бик матур иреннәрең.
Калсын әле хыялымда
Шат, күңелле көннәрем.

* * *

Куллары корышсын иде,
Бурларның, каракларның.
Машина, бакча талаучыларны
Рәнҗеп, каргап калдым.

## Йөгәнләсәм яшьлегемне

Йөгәнләсәм яшьлегемне,
Тыеп тотармын микән.
Тезгененнән тоталмасам,
Ниләр эшләрмен икән?

Җибәрмәскә яшьлегемне
Тырыштым куплэр кебек,
Әйдә, дидем минем белән,
Калма артымнан көлеп.
Тоталмадым яшьлегемне
Узып барган чагында.
Исәп тоттым, кире кайтып,
Йөгәнләргә тагын да.
Буйсынмады тиле яшьлек,
Тыңламый, калды ерак.
Теләми бергә барырга,
Кушса да аңа йөрәк.
Яшьлегемнән калган моңнар
Һаман чыкмый күңелдән.
Шул моңнарны кабатлыймын
Йөрәгемнең түреннән.

## Гомәр

Язын якорь табып судан
Тазарттырды тутыктан.
Постаментка куйгач масая,
Әйтерсең үзе утырткан.
Җәй буе кәҗә кудыра,
Кереп ашаган гөлләрне.
Кәҗә куып җәфаланам,
Шулай үткәрәм көннәрне.
Көз буе яфрак җыйдыра,
Себерттерә калганын.
Вакытында акча түләми,
Яратмыйммын алдавын.
Кыш буе карлар көрәтә,
Һушны ала бу Гомәр,
Биш ай буе кар көрәүгә
Йөрәгем ничек түзәр.

## БЮРО

Бюро. Аптыраш.
Төрле караш.
Берсе улый.
Берсе елый.
Бары да пират.
Түз син, йөрәк,
Түзәргә кирәк.

## Узган гомер, үткән юллар

Күпме юллар уздым гомеремдә,
Санап бетереп булмый аларны.
Узган чакта минем үткен күзләр
Күпне күрде, кырны, даланы.

Руль артында узган чакларымда,
Борма юллар каршы алдылар,
Хәерле юл, изге сәгать теләп,
Урман, таулар озатып калдылар.

Җил, давыллы ачы бураннарда,
Узган юллар калды еракта.
Юлларымда көтелмәгән җәфаларым,
Мәңге сыкрар минем йөрәктә.

Юл газабы – гүр газабы, диләр.
Шофер гына аңлый, үткәрә.
Юлларында күргән авырлыкны
Кыю кеше генә күтәрә.

## Медицина кызлары

Ни өчен яратам икән
Медицина кызларын?
Тәнлә төшләремдә күреп,
Эзләп йөрим эзләрен.

Иң әйбәте шул кызларның,
Берсе иде Дамира,
Искә алсам да исемен,
Күңелемә дәрт бирә.

Икенчесе бигрәк сылу,
Исеме аның Рәвилә,
Аңлатырлык кына түгел,
Анысы бөтенләй әүлия.

## Нәфсе

Нәфсе алдый, өметеңне сузма,
Акча өчен сатма тәнеңне.
Тыныч көндә үткәр гомереңне,
Киләчәккә сакла даныңны.
Күреп башкалардан, җиңел кәсеп,
Табыш булыр, диеп ышанма.
Хурлык көнгә калма акча өчен,
Мохтаҗлык бит, диеп пошынма.

## Шатлыгыма сыймадым

Суырып үпкәч иреңнән,
Шатлыгыма сыймадым,
Мәхәббәт дулкыны кузгалды,
Ә син шуны тоймадың.
Сафлык сизеп йөрәгеңдә,
Тоттым нәфис кулыңны,
Мәхәббәттән алып ялкын,
Аңлыйм якын булуны.

## Яңгыр

Яңгыр тынмый, коя төне буе,
Тынгы бирми, йоклый алмаем.
Барабан каккан пионердай,
Төя тәрәзә тупсасының калаен.

## Кордашларым

Кайда хәзер авылдашларым,
Сабакташ, кордашларым?
Тормыш мәшәкате белән,
Моңарчы сорашмадым.

Өченче санлы мәктәбем
Гомерлек минем истә.
Беренче сыйныф сабакташлар
Чыкмыйлар истән һич тә.

Укыган китаплар күптән,
Искереп мүкләнгәндер.
Санап өйрәнгән таяклар,
Мөгаен, югалгандыр.

Коридорда чылбыр сәгать,
Кельт, кельт иткән телләре
Әле дә бит күз алдында,
Асылынган герләре.

Кайда хәзер кордашларым,
Күрергә иде сезне,
Балачакны искә алып,
Сөйләргә иде сүзне.

Тәнәфескә дип чакырган
Җиз кыңгырау телләре.
Әле дә бит күңелемдә,
Чыңлап торган моңнары.

## Кыр казлары китте

Кыр казлары китте каңгылдашып,
Тезелешеп бездән еракка.
Тавышлары күкне яңгыратты,
Моңсу сагыш салып йөрәккә.

Киткән чакта күрдем, күзләреннән
Сагыш тамчылары сибелде.
Алар киткәч туган җирләреннән,
Ялгызлыгым шунда сизелде.

Очрашырга теләп язлар җиткәч,
Кул болгадым алар артыннан,
Канат кагып миңа белдерделәр,
Рәхмәт әйткән сыман барсыннан.

* * *

Газиз әнкәм бирешмәде,
Котырынган буранда,
Салкын төндә чана тартты,
Утынсыз утырганда.

Сукранмады, зарланмады,
Горур булды әнкәем.
Үрнәк минем тормышымда,
Әнкәем бәгырькәем.

## Алланы искә алып

Буйсындырам!- дип кыланды,
БЮРО җыйды бигрәк еш,
Кимсетте, көлде кешедән,
Оргвывод ясый, имеш.

Уфтана хәзер көн саен,
Алланы искә алып,
Гөнаһларын кичерүен сорый,
Кәкре таякка калып.

Билләре катып кәкерәйгән,
Эшли алмый эшләрен,
Урам буйлап өстерәп йөри,
Куныччлы кәлүшләрен.

## Хәйрүш

Күпләрне кимсетеп Хәйрүш,
Биш-алты кабат борды,
Мәгънәсе бик аңлаешлы
Ришвәтен көтеп торды.

Озак еллар ришвәт алды,
Мескен шофер кулыннан,
Шулкадәр өйрәнеп китте,
Мөфтәхетдин юлыннан.

Хәтеремә сеңеп калган,
Хәйрүшнең яман ягы.
Күпләрнең җанын сыкраткан,
Шпорадай табандагы.

Ришвәте алга илтмәде,
Нәфесе әләкте тозакка,
Җиһазга булган комсызлык,
Сузылмады озакка.

## Чын мәхәббәт

Мәхәббәт ул килә көтмәгәндә,
Сизмәгәндә, басып тын гына.
Үтеп керә синең йөрәгеңә,
Хәбәр сала сиңа шым гына.

Сөю хисе көчле ташкын сыман
Килеп җитә белеп вакытын.
Ошатканын, яратканын күрә,
Шунда тоя һәркем бәхетен.

Нинди шатлык тәүге очрашулар,
Мәрхәмәтле матурны күрсәң.
Шул чагында сиңа була бүләк,
Әгәр аңа сөюең бирсәң.

# Серне чишсәң дә ярый

Авыл Советы секретаре Гөлсинә хәрби комиссариаттан алынган повестканы тапшырырга китте. Ул Әхмәтханнарның йортына килеп җиткәч, ишек алдында торган әнисен күреп:

– Кифая җиңги, исән-сау гына яшәп ятасызмы?–диде. Эндәшкән тавышка борылып карагач, Гөлсинәне танып алып:

– Бик әйбәт, Гөлсинә, үзең на хәлдә? Ни эшләр бетереп йөрисең? Әйдә, кер, чәй эчеп алырбыз! – дип кызны өйгә чакырды.

– Рәхмәт, кереп чәйләр эчеп торырга вакытым юк, эштән генә килдем. Менә Әхмәтхан абыйга военкоматтан повестка килде! – дип,киртә аша повестканы Кифая җиңгигә сузды. Әхмәтхан абый кайткач кулына тоттыр яме, Кифая җиңги, әгәр әйтелгән көнгә барып җитмәсә, мине гаепләүләре бар,– дип Гөлсинә китеп барды.

– Их, улым, улым, хезмәткә китәр вакытың да җитте, бик зур таяныч идең, син киткәч мин ни эшләрмен инде?-дип, моңсуланып торганда, урам башыннан Әхмәтханның кайтып килгәнен күреп, көтеп алырга булды ана. Капка төбендә басып торган әнисенә:

– Әллә мине каршы алырга чыктыңмы, әнкәй? – диде.

Әхмәтханга әнисе сәер булып тоелды. Ул әнисенең кулларыннан тотып, күзләренә карады да:

– Нәрсә булды, әнкәй? – дип сорады.

– Син кайтыр алдыннан гына авыл Советы секретаре Гөлсинә килеп китте, ул менә сиңа повестка китерде, дип кәгазен Әхмәтханга сузды. Аның күзләреннән яшь чыгып, битләреннән иреннәренә кадәр тәгәрәшеп төште.

Алар өйгә кереп чәй эчәргә утырдылар.

– Әнкәй, бик кайгырма инде, минем исән-сау хезмәт итеп кайтуымны телә. Исәнлек кирәк, исән булсам, кайтырмын. Өч ел менә үтә дә китә, – дип әнисен юатты. – Бөтенләй ике кулсыз калмассың әле, юк-юк та Фатих җизнәйгә мөрәҗәгать итеп торырсың. Мин дә әйтеп китәрмен аңа. Авыр елларда, сугыш вакытында арчаланып калганны, мин кайтканчы түзәрсең инде, әнкәй, – диде. – Ул бер чынаяк чәй эчте дә, чынаягын читкә этеп куйды.

– Китер, улым, тагын берне ясап бирим, – дип чәй тәлинкәсенә үрелде Кифая түти.

– Юк, рәхмәт, әнкәй, җитте, эчәсем килми, йөреп кайткач, тагын бер утырып эчәрбез, – дип җыенып, урамга чыгып китте.

Кая барырга дип торганда, тыкрык башыннан клуб мөдире Катиф килеп чыкты. Елмаеп килеп, Әхмәтханга кулын сузды.

– Нәрсә кәефең юк, энекәш? – дип сорады.

– Менә, бүген повестка китергәннәр, хезмәткә чакырып.

– Кайгырма, йөреп кайт, әйдә, менә мин дә хезмәт итеп кайттым. Солдатта кеше ныгый гына. Әйдә алай булгач киттек клубка, күңелең күтәрелеп китәр.

Клуб янында яшьләр җыела башлаган иде. Әхмәтхан күзләре белән алар арасыннан үзенең сөйгәне Наиләне эзләде, тик ул күренмәде. Катиф клубны ачып кереп киткәч, Әхмәтхан түбән оч Әмирҗан малае Риза янына килеп:

– Сәлам, Риза, хәлләр ничек? – дип сораганда, Ризаның йөрегән кызы Әнфисә белән Наиләнең килүен күргәч Әхмәтханның төшенке күңелләре күтәрелеп китте. Яшьләр клубка керә башлагач Әхмәтхан белән Риза да керде. Алар ишектән кереп сул як стена буена килеп бастылар. Яшьләр җыелгач, клуб мөдире Катиф, сәхнәгә чыгып басты да уң кулын күтәреп:

– Иптәшләр, тынычлык сорыймын! – диде.

Бар да тынычлана төшкәч, Әхмәтханны чакырып, сәхнәгә менүен үтенде. Әхмәтхан килеп менеп баскач.

– Иптәшләр, бүгенге кичә, башкаларына караганда да, күңеллерәк үтәргә тиеш, барыбыз да актив катнашыйк,–диде. Арадан кемдер берәү:

– Сәбәбе нәрсәдә соң? – дип сорады. Катиф, Әхмәтханга карап алды да:

– Сәбәбе бар аның, иртәгә Әхмәтханны хезмәткә озатабыз. Шуңа күрә, бүгенге кичә аның күңелендә хезмәт чоры үткәнче сакланырга тиеш! – дип аңлатты.

Арада басып торган Наилә, иптәш кызына таба авышкандай булды, күңелләре төшеп китте, битләре кызарып, маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Әхмәтханның да күңеле тулды,

шулай да тыелды, сиздермәде. Клуб мөдире үзенең бүлмәсенә кереп, магнитофонын кабызып танцы көен уйнатып җибәрде. Бар да парлашып танцевать итә башладылар. Әхмәтхан Наилә янына килеп кулларыннан тотып алды да биергә чакырды. Алар бер берсенә карап бераз биегәннән соң Наилә Әхмәтханның кулларын биленнән алып куйды. Әхмәтхан аңа:

– Наилә, әйдә тагын бераз танцевать итик инде? – дисә дә, Наилә эндәшмичә клубтан чыгып китте. Алар, кичләрен үзләре очраша торган елга буендагы тал янына килеп туктадылар...

– Наилә, мин сине нык яратам, син мине хезмәттән кайтканчы көтәргә ризамы?-дип сорады Әхмәтхан.

– Нигә сорыйсың! Беләсең бит, мин дә сине яратканны, әлбәттә, көтәчәкмен, – дип вәгъдә итте кыз.

Таң атканга кадәр аларның сүзләре бетмәде. Чылтырап аккан чишмә тавышы, таллардагы кошлар сайравы ике гашыйкның аерылу сагышын тагын да көчәйтте. Ниһаять, Наилә торып басты да:

– Ярый, әйдә, кайтырга вакыт, сиңа да юлга җыенырга кирәк! – диде.

Әхмәтхан өйгә кереп, шым гына койкасына менеп яткач әнисе:

– Кайттыңмы, улым, ярый әйдә ятып бераз ял итеп ал, – дип, килеп өстенә ябып куйды.

– Алҗыгансыңдыр, әнкәй, үзең дә ял ит инде? – диде улы.

Әхмәтхан иртән уянып, күзләрен ачып җибәрүгә, әнкәсе өстәлгә самавырын кайнатып, коймакларын пешереп әзерләп куйган иде. Ул торып юынып керде, бергәләп утырып ашагач, рәхмәт әйтеп өй алдына чыкты. Күп тә үтмәде Әхмәтханны озатырга күрше-тирә җыелды. Тиз арада колхоз рәисе Зөфәр абзый да, яхшы тарантаска җиккән кара айгыры белән Кәримҗан абыйны утыртып килеп җитте. Әхмәтхан белән күрешеп алгач:

– Менә сиңа транспорт, Кәримҗан абыең районга илтеп куяр! – диде. Җыелган халык Әхмәтханны авыл капкасын чыкканчы озата барды.

Әхмәтханны, районнан җыелган егетләр белән Уфага

җибәрделәр. Уфада кабаттан комиссия үткәч, поезд белән алып киттеләр.

Поездда унбиш көннән дә артык барырга туры килде. Бер көнне Әхмәтханнарны машинага утыртып Кытай белән чик буена алып килделәр. Кич, мунчага алып барып, юлдагы киемнәрен салдырып, чәчләрен алып, солдат киеме киендерделәр. Әле генә юлда дуслашып килгән егетләр, мунчадан чыккач бер берсен танымый тордылар.

Шулай итеп Әхмәтханның хәрби хезмәте башланды. Өченче көнне барын да сафка тезеп командир:

– Арагызда шоферлар бармы? Булса ике адым алга! –диде.

Электән дә шофер булырга өметләнеп, кызыгып йөрегән Әхмәтхан, шофер сүзен ишеткәч, бәлки, шоферга да укытырлар, дип уйлап, ике адым алга атлады. Старшина килеп аларны, чымылдыклар япкан машиналар янына алып килеп беркетә башлады. Әхмәтхан машина янында басып торган сержант белән очрашты. Бу сержант Башкортстан егете булып чыкты. Әхмәтханның урысчаны чамалы белүен күреп:

– Син каян? – дип сорады татарча.

– Мин, мин Башкортстаннан, Әхмәтхан булам! – диде тотлыгып.

– Ә, ә, якташ, әйдә алай булгач мине алыштыр, безгә кайтып китәргә вакыт җитте. Машинаны карап ал! – диде. Әхмәтхан аның янына якынрак килеп:

– Якташ, мин бит мондый машинаны күргәнем дә юк, ишеткәнем дә юк, йөри дә белмим, – диде.

– Ярый, кайгырма, мин сиңа аңлатып, күрсәтеп бирермен барын да, сиңа бу машинада бик йөрергә туры килмәс, чөнки бу спецмашина, синең эшең, сөртеп, майлап, карап торуда. Ул Әхмәтханга барын да аңлатып, күрсәтеп бирде. Шулай итеп Әхмәтханны берничә көн өйрәтте. Шушы көннән башлап аның шофер хезмәте башланып китте.

– Вакыт аккан судай уза, сизелми дә, Әхмәтханның да хезмәт итүенә өч ел тулды. Яхшы хезмәт иткән өчен аны сержант дәрәҗәсенә кадәр күтәрделәр. Хезмәттән кайту белән, шул ук кичне, Әхмәтхан үзенең яраткань Наиләне күрергә ашыкты. Аның белән күрешеп, өч ел арасындагы вакыйгалар турында сөйләшеп туя алмадылар.

Әхмәтхан, бер атна чамасы ял итеп, йорт тирәсендәге эшләр белән шөгыльләнгәннән соң, авылдаш егетләре белән аралашканда, авылларыннан ерак түгел, бер йөз километр чамасы җирдә нефтьчеләр шәһәре төзелә башлаганын ишетеп, шунда китәргә исәпләде.

Икенче көнне паспорт алу исәбе белән, справка сорарга колхоз рәисе, Зөфәр абзыйсы янына керде.

– Әхмәтхан энекәш, утыр әле! Ничек үтте хезмәтең, сөйләп җибәр...

– Әйбәт үтте. Зөфәр абый. Зөфәр абый, минем сезгә зур үтенечем бар.

– Я, сөйлә, тыңлап карыйк әле.

– Ерак түгел генә нефтьчеләр шәһәре төзелә башлаган дип ишеттем, эшчеләр кирәк икән, шунда барып эшкә урнашырга исәп иде. Паспорт алырга справка бирмәссез микән? – дип сорады Әхмәтхан.

– Кая военный билетыңны күрсәт әле, – диде Зөфәр абзый. Шунда колхоз рәисенең печатьле язуга күзе төште.

– Тукта әле, тукта, – дип кычкырып укый башлады,менә монда бит "Водитель-механик спецмашин" дип язылган түгелме соң? – Әхмәтхан энекәш, шушы көннәрдә безнең колхозга "Волга" машинасы бирәләр, миңа тәртипле шофер кирәк. Беркая да китмисең, үземә шофер итеп алам, үзеңне өйләндерәбез, менә дигән туй ясарбыз, йорт салырга ярдәм итәрмен! – диде Зөфәр абзыйсы.

Әхмәтхан аңа шоферга таныклык юк, дип аңлатырга тырышса да, колхоз рәисе тыңлап та тормады.

– Аңладыңмы? – Бар кайтып тор, районнан машина кайту турында шалтыраткач та, үзем хәбәр итәрмен! – дип, Әхмәтханның аркасыннан сөеп, озатып җибәрде.

Өч көн үткәч, колхоз рәисе Әхмәтханны чакыртып алып:

– Әйдә, Әхмәтхан, җыен, "Сельхозтехникага" машина алырга барасың, баргач үзең карап, тикшереп алырсың. Хәзер районга Кәримҗан абыең бара, аның машинасына утырып барырсың. Бар, юлдагылар юлда булырга тиеш, – дип Әхмәтханга ышаныч кәгазен тоттырды.

Урамга чыккач Әхмәтхан, берникадәр вакыт уйланып торды да:

– Армиядә өйрәтеп биргәнне, "Сельхозтехика"га баргач

берәрсеннән сораштырырман әле, – дип гаражга китте.

Авыл капкасын чыгып, үрне менеп бераз баргач, Кәримҗан абый зарланып:

– Эх, энем, энем, менә шушы сикертмәле юллардан йөреп гомерләр уза инде. Аны тигезләргә грейдеры да юк бит. Без асфальт юлларны төштә генә күрербез инде! – диде.

Алар начар юлдан селкенә, селкенә барып, олы юлга килеп чыктылар.

– Менә асфальтка да килеп чыктык,-дип шаяртып әйтеп куйды Кәримҗан абый. Бара торгач алда район биналары күренде. "Сельхозтехика"га килеп, Әхмәтханны төшереп куеп, Кәримҗан абый үзе эше белән китте. Әхмәтхан кулларын каешына тыгып гимнастеркасын рәтләп куйды да, кесәсеннән ышаныч кәгазен алып,"техотдел" дип язылган бүлмәгә кереп китте. Анда утырган бер яшь кенә кыз, солдатны күреп:

– Сез нинди йомыш белән килдегез? – диде.

– Мин Горький исемендәге колхоздан, машина алырга килдем, – дип ышаныч кәгазен сузды.

– Бераз көтеп торыгыз, мин хәзер! – дип икенче бүлмәгә кереп китте кыз. Озак та тормый чыгып:

– Барыгыз, завскладны күреп, бирерсез, дип елмаеп Әхмәтханга ышаныч кәгазен бирде. Әхмәтхан склад мөдирен табып, рөхсәт кәгазен тапшырды. Склад мөдире аны "Волга" янына алып килеп, алганлыкка имза салдырды, машина ачкычларын тапшырды да кире китте. Әхмәтхан ачкычларын кулына тотып, бераз торгач, ерак түгел генә торган "Волга"шоферы янына килеп:

– Ерактан килдеңме? – дип сорады.

– "Танып" колхозыннан.

– Күптән алдыгызмы "Волга"гызны?

– Икенче елга китте инде.

– Сиңа минем үтенечем бар. Безнең колхозга әнә теге "Волга"ны бирделәр. Ә минем җиңел машинада йөрегәнем юк. Тизлекләрен күрсәтеп бирмәссеңме?

– Була ул. Әйдә күрсәтәм, – дип машина янына килеп, Әхмәтханга барын да аңлатып, күрсәтеп бирде. Ул бик нык игътибар белән тыңлап торды.

– Менә шулай, анның бернинди дә кыенлыгы юк! – дип ачкычын тоттырды. Ул китәч Әхмәтхан кабинага кереп утырып, машинаны кабызып, байтак кына вакыт скоростьларга салып, өйрәнеп утырды. – Болай күпме утырырга була! – дип, беренче скоростька салып, әкрен генә кузгалып, территориядән чыгып китте. Аяклары протез кебек, дер-дер калтыранды. Ул юлның уң ягыннан, икенче скоростька салырга куркып бер ун километрдай ара үтте. Бара торгач юлның уң ягында бер зур ялан күреп, әзрәк өйрәнергә дип кереп китте. Мин барыбер өйрәнергә тиеш, дигән бурыч куйды үзенә. Аюны да өйрәтәләр, мин аюдан да киммени? – дип болында йөри башлады.

– Ярый, җитәр, кайткач тагын басу буйлап йөреп өйрәнермен әле,-дип олы юлга чыгып, кайту юлына таба борылды. Авылга кергәнче начар юлларны әкерен генә, сак кына узды. Кайтып кергәндә гимнастеркасы салып сыгардай булды. Машинаны гараж янында калдырып, кайтып китте. Аяклары һаман да ушсыз иде.

– Әнкәсе чәй кайнатканчы Әхмәтхан бераз ятып ял итеп алырга булды. Чәйдән соң, машинаны алып кайту турында колхоз рәисенә хәбәр итәргә китте. Зөфәр абзыйсы басуларны урап кайткач, Әхмәтхан аңа:

– Зөфәр абый, машинаны бер-ике көн майларын карап, обслуживать итеп алырга кирәк булыр инде, – диде.

– Карап ал, юлда туктап калырлык булмасын! – диде Зөфәр абзыйсы.

– Бу бер-ике көн аңа, машинаның китабын укып, танышып, бераз йөреп карарга кирәк иде. Иртәгәсе көнне Әхмәтхан иртән үк торып гаражга килде, машинасыннан китабын алып бик нык игътибар белән, җентекләп берничә кат укып чыкты. Аннан соң, басуга чыгып йөреп карады. Икенче көнне дә шуны кабатлады, заправкага барып машинасын да заправить итеп алды. Шимбә көнне Зөфәр абый Әхмәтханны чакыртып алып райкомга киттеләр. Начар юлларны ул бик сак кына җайлап узды. Олы юлга чыккач та йөреш тизлеген кырык, илледән арттырмады. Бераз баргач Зөфәр абыйсы:

– Әйдә, Әхмәтхан, бас газына, кызурак бар! – диде. Үзенең ныклап йөри белмәгәнен сынатмас өчен егет:

– Зөфәр абый, машина яңа бит әле, обкатка да үтмәгән,

бер-ике мең километр шулайрак үтәргә туры килер инде! – дип рәисне ышандырып куйды.

– Яхшы, яхшы, анысын үзең карыйсың, менә бер көнне ГАИга барып номерлар ал, учетка куярга кирәк булыр! – диде.

– Яхшы, Зөфәр абый, алырбыз,-диде йомшак кына итеп. Егетнең холыгы рәискә хуш килде.

Әхмәтханга, Зөфәр абзыйсы белән басулар буйлап, фермаларны тикшереп, күп йөрергә туры килде. Тузанга баткан машинасын һәрвакыт юып, сөртеп кенә торды. Бер еллап йөргәннән соң егеткә тәҗрибә килде. Бер елдан соң Әхмәтхан белән Наилә өйләнешеп, туй ясап, матур гына тормыш корып җибәрделәр.

– Шулай итеп Әхмәтхан утыз ел буе,беркайчан да юл кагыйдәләрен бозмыйча таныклыксыз Горький исемендәге колхоз рәисен йөртте. Тәртипле, әйбәт кенә йөргәч, аны беркайчан да туктатып, таныклыгын тикшермәделәр. Лаеклы ялга озатканда да, яхшы хезмәте өчен, колхоз утырышының карары нигезендә, аңа тотылган булса да "ГАЗ-69"маркалы машина бүләк иттеләр. Бер көнне Әхмәтхан болай таныклыксыз йөреп булмас, юл йөрү кагыйдәләрен күп укыдым, ГАИга барып таныклык сорыйм әле! – дип районга китте. Кабинетка кереп Әхмәтхан абый исәнлек-саулык сорашып автоинспекторның каршысына килеп утырды.

– Әхмәтхан абзый! Нинди җилләр алып килде? Әллә ялгышып, әллә адашып килеп кердеңме? – дип шаяртып көлеп куйды ГАИ начальнигы.

– Әйе, элек эштән бушап булмый иде, хәзер ялга чыккач, дөнья көтәргә тырышып йөрисең. Менә шулай яшь гомер, аккан су кебек, сизелмичә үтте дә китте, – дип Әхмәтхан көлемсерәп куйды да ГАИ начальнигына:

– Сез беләсезме минем нинди йомыш белән килгәнне? – диде.

– Юк, сөйләп җибәр әле, тыңлап карыйк, нинди мәшәкатьләр борчый икән үзеңне.

– Утыз елдан артык, таныклыксыз, колхоз рәисен йөреттем, юл кагыйдәләрен беркайчан да бозмадым, тырышлыгым өчен лаеклы ялга киткәндә мактау грамотасы белән машина

бирделәр. Хәзер йөрү өчен таныклык кирәк. Булыша алмассызмы? – диде Әхмәтхан абзый.

– Син шаяртып сорыйсыңмы? Көлепме? Әллә таныклыгыңны югалттыңмы? Әллә милиция эшчеләре алдылармы? – дип кызыксынды автоинспектор.

– Юк шаяртмыйм да, көлмим дә, әгәр беләсегез килсә серемне ачам инде! Утыз ел эшләп минем бөтенләй дә таныклыгым булмады.

– Ничек инде ул, утыз ел таныклыксыз, колхоз рәисен йөрттең? Тукта әле, тукта, бу бит бик гаҗәеп вакыйга! – дип кызыксынды ГАИ начальнигы. Шунда Әхмәтхан башыннан кичергәннәрен сөйләп бирде.

Колхоз рәисе КПСС райкомының бюро әгъзасы иде. Аның белән йөргәндә, беркем дә туктатмады, машинам һәрвакыт төзек, чиста булды. Андый машиналар бик сирәк иде бит. Укырга җитешеп булмады, төне-көне эшләргә туры килде, Үзлегемнән укып өйрәнеп эшләп киттем...

–Ярый, болай булгач сиңа шофер-профессионал таныклыгы бирергә дә була! – диде ГАИ начальнигы.

– Миңа автолюбитель таныклыгы булса да ярый, – диде Әхмәтхан.

ГАИ начальнигы сейфыннан таныклык бланкасын алып язды да:

– Менә ал, Әхмәтхан абзый, исән йөр! – дип таныклыкны кулына суздты.

# Качкылыкта үткән гомер

Атасы Шакир абзый фронтка киткәндә Мәҗиткә унбиш тулып уналтыга киткән иде, ябык кына нечкә, озын буйлы, ач яңаклы, чандыр егеткә әйләнгән иде ул. Бер көнне әнкәсе аны, яңа сауган сыер сөтен чирекле шешәгә тутырып, Карагыш авылы яныннан үтә торган тимер юл станциясенә сөтне солдатлардан сабынга алыштырап кайтырга, дип җибәрде.

Мәҗит чирекне биштәрләп станциягә килде. Озак та үтмәде фронтка китүче солдатлар төялгән товарняк килеп тә туктады. Солдатлар сикерешеп төшеп, кемнең нәрсәсе бар алыштыра башладылар: берсе солдат каешын – бәрәңгегә, кем перчаткасын – майга, кем гимнастеркасын тәмәкегә алмаша. Мәҗит исә, әнкәсе әйткәнчә, сөтен ике кечкенә кисәк кер сабынына алмашты. Биш минут та үтмәде, поезд кара төтеннәрен чыгарып кузгалып китте. Мәҗит сабыннарын кесәсенә тыкты да кайтыр юлга чыгарга дип торганда бер ак сакаллы картның тәмәке тартып торганын күреп, үзенең дә тартасы килеп китте. Карт янына килеп, йомшак кына тавыш белән:

– Исәнме, бабай? Хәлләрең ничек? – дип сүз башлады.

Бабай ютәлли-ютәлли:

– Аллага шөкер, улым, син кем буласың соң әле? Мин бит сине танып житкермимен! – диде.

– Мин Байтугай Шакир улы булам.

– Ә, ә. Әллә берәр йомышың бармы?

– Йомышым юк, бабай. Махорканңы гына тарттырмассыңмы? – дигән идем.

Бабай кесәсеннән майланып беткән самосад янчыгын чыгарып, янчыкка төрелгән гәзит кисәген ертып бирде. Бабай самосадын салгач, Мәҗит картларча гәзитнең читен телендәге төкерек белән юешләтеп бөтереп авызына капты да бабайның янып торган махоркасына үрелде. Бер-ике суыргач, каты тәмәке төтене авызына капланып, тын юлын кысты. Төчкереп жибәрде, буыла-буыла ютәлли башлады, күзләреннән мөлдерәп яшь бәреп чыкты.

– Әллә катыракмы, улым? Мондыйны тартканың юкмы, әллә? – диде бабай. Мәҗит дәшми генә ризалашып башын какты.

– Үзем үстергән самосад шул, өстәвенә трайнуй әҗикалун да кушкан идем, шуңа куәтле инде, – дип өстәп куйды.

Мәҗит тәмәкесен җиргә ташларга исәпләгән иде, ләкин бабайдан кыенсынды. Кулына тотып кайтыр юлына чыкты. Ул бераз юл узгач, тагын бер-ике суырып карарга булды. Башы әллә ничек әйләнеп китте, күз аллары томалангандай итте. Кызыксынып тәмәке төтеннәрен авызыннан чыгарып пырхылдата, пырхылдата, урман юлыннан кайтып килгәндә, каршысына мылтык тоткан ике кеше килеп чыкты. Аларның берсе алдына басты, икенчесе артыннан килеп җилкәсенә мылтык көпшәсен терәде. Куркудан Мәҗитнең авызыннан тәмәкеләре төшеп китте.

– Нәрсә эшләп йөрисең, малай кисәге? – диде каршыга килеп басканы.

– Станциягә барган идем.

– Анда нәрсә югалттың?

– Югалтмадым. Сабынга барган идем, – дип кесәсеннән ике сабын кисәген чыгарып күрсәтте.

Мылтык төзәп торганы килеп, сабыннарын алды да үзенең кесәсенә тыгып куйды.

– Кайсы авылдан? Исемең ничек? – дип сорады.

– Байтугайдан Мәҗит булам.

– Бар, юлында бул! Без сине, син безне күрмәдең. Әгәр сөйләнсәң, хәтерлә, эзеңә төшәрбез! – дип Мәҗитнең аркасыннан приклад белән төртеп җибәрде.

Авылга кайткач Мәҗит бу хакта беркемгә дә, хәтта әнкәсенә дә әйтмәде.

– Улым, сабын булмадымыни? – дий сорагач әнисенә:

– Булмады шул, – дип куйды күңелсез генә. Әнкәсе аңлагандай кабат дәшмәде.

Бу хәл Мәҗитне бик озак вакытлар борчыды. Шундый ачлык, авыр сугыш елларында илне дошманнан сакламый, ничек итеп урманда качып, кеше талап йөрмәк кирәк, дигән уйлар борчыды малайны.

... Язгы басу эшләре тәмамлангач сабантуйлар үтә башлады. Бер көнне Мәҗит тә авыл малайлары белән җыенып күрше авылның сабантуена китте. Авыр еллар булуга карамастан, халык дәртен, моңын, күңел ачуын югалтмады. Сабан туенда катнашучыларны хуплап бүләкләделәр. Арада Мәҗит тә бар иде. Ул үзе яраткан, халыкка да ошаган “Тамбов урманнары” дигән җырны җырлап бөтен мәйданны хәйран калдырды. Ул җырлаганда күңелгә дәрт керуп, йөрәк кылларын тибрәтте. Әйтерсең

талдагы сандугачлар чылтырап аккан чишмә суына кушылып сайрый иде. Халык аның башкаруын йотлыгып тыңлады. Җырлап туктагач халык алкышлар белән тагын җыр башкаруын сорады. Ул “Кара урман”ны башкарды. Халык арасында юл басып, Мәҗитнең сабынын алган кешеләрнең берсе, тыңлап утырган җиреннән: “Менә бу егет миңа кирәк!” – дип куйды.

Бер көнне Мәҗит Карагыш станциясеннән кайтып килгәндә, элек туктаткан кешеләр урманнан чыгып янына килеп бастылар. Теге вакытта мылтык терәгәне, бу юлы да шул ук гамәлне кабатлады.

– Син хәзер безнең белән барасың! – диде каршыда торганы.

– Юк, мин беркая да бармыйм сезнең белән! – диде Мәҗит, чыраен сытып, һәм шул вакыт кинәт кенә үзенең муенында бау тартылганын сизде. Муенчак бугазын шул кадәр каты итеп кысты ки, хәтта малайның тын алышы тукталды, күзләре акайды, тамагындагы бугаз сөяге сынгандай булды. “Синнән барасыңмы, юкмы, дип сораучы юк бит әле–, дип бугазыннан эләктереп тартып торган кеше бауны бушатып, көлемсерәп куйды: – Йә, уйладыңмы?”

Мәҗитнең куркудан чарасы калмады. Әллә урманга алып кереп асып куярлар, дип курыкты ул һәм ризалашты. Каршыда торганы куак арасына кереп, арбага җигелгән ат алып чыкты. Мәҗитнең күзен кара яулык белән бәйләп, арбага утыртып кузгалып киттеләр.



Байтак кына баргач, бер җирдә туктадылар, аны арбадан төшереп, җитәкләп ишектән алып кереп, сәкегә утырттылар һәм күзен бәйләгән яулыкны чишеп җибәрделәр. Егет куллары белән күзен уып, кая алып килделәр микән, дип як-ягына карап алды.

Аңа өстендәге ямаулы күлмәген салырга куштылар. Күлмәген салгач, аның ябыклыгын күреп:

– Син нәрсә? Әллә тире белән сөякләр җыелмасыннан гына торасыңмы? – дип берсе көлеп җибәрде. Мәҗит эндәшмәде. Ул үзенең ябаклыгына күнеккән, беркемнән дә оялмый иде.

– Бүгеннән соң үзеңнең Мәҗит икәнлегеңне оныт, син хәзер Шүркә буласың! – диде. Мусагат иптәшенә карап:

– Нигә аңа андый кушамат бирәсең?

– Чөнки ул ябык, озын, чишенгәч күрдең ич, Шүрәлегә охшап калды. Шуңа күрә ул хәзер Шүркә инде, – диде каршысында утырган кеше. Чөйдә эленеп торган гимнастерканы алып Шүркәгә ташлады.

– Бар, чишмәгә төшеп юынып мен, кача-нитә калсаң, менә бу куып җитәр сине, – дип карабинына күрсәтте.

Мәҗит чишмәгә төшеп салкын суда юынып менгәч, аңа кичтән калган итле аш салып бирделәр. Ул ашаган арада тегеләр үзләренең булачак эшләре турында сөйләшеп алдылар. Аларның сүзләреннән Мәҗит кая килеп эләккәнен төшенә башлады. Ул биредән болай гына котылып булмасын да аңлады. Кызыксынып аларга сорау да бирмәде. Алар үзара аралашканда каршысына чыгып басканы “Вәчкә”, ә артыннан җилкәсенә мылтык терәгәне Мусагат исемле икәнен аңлады. Шул чакта Мәҗит үзенең куркыныч хәвефле хәлгә эләккәнен төшенде.

Аны беркем дә үтерергә җыенмады. ”Нәрсәгә кирәк булдым икән мин боларга?” – дигән уй аның миен бораулады. Аның сәкегә ятып акырып елыйсы килде. Бу хәл аны бөтенләй бөкте. Ул нәрсә уйларга да белмичә аптырап утырды. “Әллә бүген төнлә муенга бау салыргамы? Әллә бу хәлнең азагына кадәр түзеп карарргамы? Азагы нәрсә булып бетәр микән?” – дип уйланды ул.

Вәчкә Мәҗитне тотып алып килүенә куанып түрдәге сәкегә менеп ятып, сызгырып җибәрде.

Мәҗит алар белән сүзгә кермәде, бары тик сөйләшкәннә-

ренә колак салып кына тыңлап утырды. Шунда ул Мусагатның фин сугышыннан кайткач, фронтка бармас өчен Вәчкәгә ияреп качкылыкка чыгып китүен аңлап алды.

Мусагат Мәҗиткә чиләк тоттырып, чишмәдән су алып менәргә кушты. "Хәзер син безнең повар буласың, чәй кайнат!" – диде. Үзе мылтыгына таянып, землянка баскычына утырып, Шүркәне күзәтте. Шул көннән башлап Мәҗитне эт йомышына да, кош йомышына да йөртә башладылар. Ул качсам, барыбер мине табарлар, тотып юкка чыгарырлар, дип куркып качмаска булды.

Өченче көнне Шүркәне разведкага әзерли башладылар. Каты итеп күрсәтмә бирделәр, почмакка кысып ант иттерделәр. Түзәр әмәле калмагач, ул барырга ризалашты. Аның беренче йөкләмәсе тирә-як авылларны йөреп, ни хәлләр барын, милиция эшчеләре юклыгын белү, ә кайтканда Факиягә кереп азык һәм үзенең тальян гармунын алып килү иде.

Мәҗит тирә-як авылларда йөргәннән соң, андый-мондый хәбәрләр ишетелмәгәч, үзенең авылына кайтып, әнкәсенең хәләхвәлләрен сораштырып, әтисеннән калган гармунын алып, әнкәсенең иске яулыгына төреп, култык астына кыстырды да:

– Ярый, әнкәй, минем барасы җирем бар, – дип ишеккә юнәлде.

– Кая барасың, улым, озаккамы?

– Юк, күрше авылга чакырдылар, анда иптәш егетнең туган көне, бармасам, ачуланырлар, бармый булмый, әнкәй, – дип чыгып китте.

Аларның өйләре иң кырыйда, урманга терәлеп үк тора иде. Ул Саклау урманы аша үтә торган юлга, урман эченә кереп китте.

Мәҗит тегеләр землянкасына якынлашканда кояш түбәнәйгән иде инде. Аяк тавышы ишетеп, Вәчкә белән Мусагат тиз генә агач арасына кереп посты. Мәҗит землянкага кереп, гармунын куеп кире чыкты да, тирә-якка озак кына каранып торды. "Кая булырга мөмкиннәр?" – дип гаҗәпләнде.

Вәчкә белән Мусагат Мәҗитне озак кына сынап күзәтеп тордылар. "Бу үзе белән кешеләр алып килмәде микән?" – дип куйды Вәчкә.

Бары да тәртиптә икәнлегенә тәмам ышангач кына, алар

агачлар арасыннан килеп чыктылар. Үләннән ышкылып килгән аяк тавышларын ишетеп, Мәҗит кисәк кенә тегеләр килгән якка борылды.

– Хәлләр ничек, Шүркә? Нинди хәбәрләр алып килдең? Ниләр күрдең? Йә сөйлә? – диде Вәчкә.

– Тирә-як авылларны йөреп чыктым, бернинди дә шикле хәбәр ишетелмәде, – диде Шүркә.

– Юлда арлы-бирле кешеләр очрап сөйләшмәдеңме?

– Юк, бер кеше дә күрмәдем.

– Ярый, алайса, әйдә керәбез! – дип землянкага алып кереп киттеләр.

Землянка авыллардан ерак, Байсар урманы эчендә иде. Землянкага кергәч, Вәчкә сәке астыннан имән мичкә өстерәп чыгырып өстәлгә китереп утыртты:

– Мусагат, йә сал әле. Мөнир картның Сакат тавы астындагы корт бакчасыннан чәлдергән әче балны авыз итеп карыйк әле, – диде.

Мусагат балчык кружкалар алып килде дә мичкәнең бөкесен ачып, агыза башлады. Беренчесен Вәчкәгә тоттырды, икенчесен – Шүркәгә, азактан агызып үзенә алды.

– Әйдә, дару өчен булсын Мөнир картның күчтәнәче! – диде Вәчкә.

– Безнең исәнлек-саулыкка! – дип өстәп куйды Мусагат.

Чәкештереп икесе берьюлы эчеп куйдылар. Шүркә, кружкасын тотып, тегеләрнең чырайларын сытканнарын карап утырды.

– Йә, нәрсә көтәсең? Әйдә салып җибәр! – диделәр тегеләр.

– Рәхмәт, минем эчкәнем юк! – дип аңлатырга тырышып карады Шүркә.

– Әйдә, эч, югыйсә җилкәңә салабыз! – дип Шүркәне кыстылар.

Болардан котылып булмас, ахры, дип көчкә-көчкә генә эчеп куйды.

– Вәт, хәзер син безнең кеше! – диде кызып алган Вәчкә. – Мусагат, әйдә парлы булсын, сал әле тагын берәрне!

Мусагат парлагач, башы әйләнеп, тәннәре йомшап китте, күзләре кысылды, куллары хәлсезләнгәндәй булды Шүркәнең.

– Әйдә әле, Шүркә, тальяныңны сузып җибәр! Сабантуй-

да уйнаткан кебек, – диде Вәчкә.

Шүркә карышып тормады, тальянын алып, “Идел бит ул киң бит ул” көен сузып җибәрде. Тальян тавышы тегеләрнең күңелләренә борыч сипкәндәй булды. Икесенең дә кәефләре күтәрелеп китте. Парлашып җырга кушылдылар. Землянка эченә сыймыйча җыр тавышы урманга таралды. Бу моңнардан соң алар тагын Мөнир бабай көчтәнәчен уртлады.

Бер көнне җыелышып Вәчкәләр Кырбарыс авылына килеп Фасиха әбинең үгез бозавын алып чыгып киттеләр. Әби, үкси-үкси елап утырганда шахтадан кайткан улы Зариф:

– Әнкәй, нәрсә булды? – дип сорады.

– Менә, улым, үгез бозауны урлап алып чыгып киткәннәр.

Зариф тикшерә торгач, арба кендеге җиргә эләгеп үләннәрне өзеп барган эздән урманга барып керде. Шул вакытта Зариф үгез бозауны суеп яткан урынга килеп чыкты. Вәчкә аны күреп иптәшләре белән уратып алды да: Нәрсә югалттың? Әллә менә монымы? – дип мылтык көпшәсен борын астына китереп терәде. Калганнары мал суеп яткан кораллларын әзерләп торды. Зариф агарып катып калды. Бандитлар Зариф белән бик каты итеп сөйләштеләр. Кире кайтырлык юлын калдырмадылар. Ант иттереп үзләренен төркеменә эләктерделәр. Шулай итеп Зариф әнкәсенең бозау итен алар белән бергә авыз итте.

* * *

Май азакларында райподан дүшәмбе көнне авылга азыктөлек китерергә тиешләр дигән хәбәр ишетелде Вәчкәгә. Якшәмбе көнне кич белән ул үзенең зимагурларын җыеп:

– Иртәгә юлга чыгасыз! Әзерләнегез! – дип боерыч куйды. Дүшәмбе көнне дүрт качкы Биекарка урманы аркылы үтә торган юлга чыгып китте. Килүчеләрне каршы алу өчен җайлы гына урын әзерләп куйдылар. Озак көтәргә туры килмәде. Төш вакыты узгач, Зариф шыгырдап килгән арба тәгәрмәче тавышын ишетеп, иптәшләренә:

– Туктагыз! Киләләр! – диде.

Бераз тынып калып, тыңлап торгач, чынлап та ат пошкырган, якынлашып килгән арба тавышлары ишетелде. Зариф иптәшләренә ымлап:

– Тавышсыз гына алабыз! Әзерләнең! – дип мал суя торган пычагын муен турысына куеп кисәтү ясады. Тегеләр аңлаганнарын белдереп баш какты. Күп тә үтмәде, әкрен генә атлап килгән ике җигүле ат күренде. Арбаларда икешәр хатын-кыз утырып килгәнен күреп:

– Болай булгач, эш җайланды! – дип сөенеп куйды Зариф һәм иптәшләренә баш бармагын күрсәтте.

Атлар якынайгач, Зариф куак арасыннан чыгып, алдан килгән ат башыннан тотып алып туктатты. Ә калганнары арба янына килеп, хатын-кызларның күкрәкләренә пычак терәп:

– Төшегез арбадан! – дип боерык бирде. Хатыннар берсүзсез сикереп төшеп арба артына барып басты.

– Атлар хәзер безнеке, барыгыз тавышсыз-тынсыз гына, чабаларыгызга тузан төшермичә сыпыртыгыз! Әгәр бу хәл турында сүз чыгарсагыз, хәтерләгез! – дип пычак янап куйды юлбасарлар.

Тик хатыннарның куллары кесәләрендәге корылган револьвер рукояткасын кысып тора иде инде. Аларның кинәт кенә барысы берьюлы каты тавыш белән:

– Туктагыз! Коралларыгызны ташлагыз! Кулларыгызны күтәрегез! – диюенә бер бандитның револьвер кургәч, кулыннан пычагы төшеп җиргә кадалды. Икенчесе агарынып катып калды. Өченчесе пычагы белән алга ташланды. Шул вакытта револьвердан аткан тавыш урманны яңгыратып җибәрде. Пычак күтәреп ташланган бандит гөрселдәп җиргә ауды. Шул арада кулларын күтәрергә өлгермәгәннәре күзләрен акайтып тын калды.

Револьвер тоткан хатыннар башларыннан яулыкларын, хатын-кыз күлмәге урынына кигән халатларын салып ташлагач, милиционер икәнлекләрен күреп, бандитлар урманга кереп шылдылар. Алар артыннан шатыр-шотыр сынган коры агач ботаклары тавышы гына ишетелеп калды. Милиционерлар туктарга кушып кычкырып, бертуктаусыз алар качкан якка атып калдылар. Берничә минут урман яңгырап торды. Яраланган бандитка ярдәм күрсәтеп, кулына богау кидереп, арбага салып алга атладылар. Юлда барганда ул милиционерлар соравына әкрен тавыш белән җавап биреп барды. Авылга кергәндә ул инде җан бирде. Авылда мәетне халык кулына

тапшырып, акт төзеп җирләделәр. Шулай итеп авыл халкының азык-төлеге үзенә ризык булды. Зариф кайтып "Райпо" операциясенең уңышсыз үтүен белдергәч, Вәчкәнең кәефе нык бозылды. "Сездән ул да тумас, кыз да тумас, туса да тормас",– дип каты итеп бандитларны әрләде. Үзенең аларга карата ышанычы югалуын белдерде. "Хәзер сезнең аркада безнең эзгә төшәчәкләр, тиз арада урынны алыштырырга кирәк! Мансур аларга әйтеп бирергә өлгергәндер" – диде.

Күптәннән кеше тормагандай итеп, землянканың астын өскә китереп, бөтен нәрсәне җимереп чыгып качтылар. Икенче көнне милиционерлар Мансур күрсәткән урынга килгәндә качкыларның эзе дә калмаган иде.

Качкыларны эзләү дәвам итте. Берничә көн үткәч, Зариф, Мансурны эзләп, авылга килде: булган вакыйгадан соң нәрсәләр сөйләде микән, дип белер өчен.

Зарифның күрәчәге булгандыр, күрәсең: шул ук көнне участковый да авылга килгән иде. Кешеләр участковыйга Зарифның килүе турында колак төшерделәр. Участковый инспектор сак кына барып, Зариф кереп киткән йортка артыннан ук бастырып килеп тә керде. Бер кулы белән револьверен төзәп, кулларын артына куйдырып, икенчесе белән Зарифның кулларына богау кидереп милиция бүлегенә алып китте.

Җинаять эшләре өчен дә, дезиртерлык өчен дә Зарифны җиде елга штрафной батальонга җибәрделәр.

Бер көнне көз айлары җиткәч, тукран тукылдаган тавышка Вәчкә йокысыннан уянып китте. Бераз күзләрен ачып, урман-җиргә казып ясалган торак ярыгыннан төшкән кояш нурына карап, бүгенге көне, алга куйган максаты турында уйланып ятты. Шулар арасында иң кирәклесе – ничек тә киләсе кышка азык әзерләп кую турында иде. Ничек итеп урмандагы торакны җиһазландырырга? Кышкылыкка үзе янында кемнәрне калдырырга? –дип, кулларын баш астыннан алып, икесен ике якка көч белән киерелеп сузды да сикереп торды. Өшеп оешкан тәннәрен берничә кабат боргалап, өч-дүрт кат чүгәләп алды. Тышка чыгып аяз күккә карап:

– Да, бүген көн шәп! – дип әйтеп куйды.

Вәчкә йокысыннан уянып чыкканда, Шүркә учак ягып,

корымга каткан чәйнүккә үлән яфраклары салып, чәй кайнатып йөри иде.

– Хәлләр ничек, Шүркә? – диде Вәчкә.

– Бер көе әле, Вәчкә, – диде аңа җаваплап Шүркә.

Чәй кайнап чыккач, Шүркә чәйнүген тышта эшләнгән өстәлгә китереп куйды. Балчыктан эшләнгән кружкаларга чәй салып, берсен Вәчкәгә бирде. Кружканы алып, чәенә өрә-өрә, Шүркәгә карап:

– Мин бүген юлга чыгам, атны әзерләп куй! – диде Вәчкә.

– Аңладым, хәзер җигеп куярмын!

Вәчкә чәен эчеп бетергәч, торакка кереп, нәрсәдер салган киндер капчыгын алып чыкканчы, Шүркә атны җигеп китереп куйган иде.

Вәчкә капчыгын арбага ташлады да менеп утырды:

– Әйдә, Шүркә, киттек! – диде.

Алар кузгалып китте.

Юлга чыгар алдыннан Вәчкә бер айдан артык сакалмыекларын кырмады, чәчләре дә хәтсез генә озын булып үскән иде. Юл буена Вәчкә бер сүз дә сөйләмәде. Шүркә дә аңа бернинди дә сорау бирмәде. Шулай итеп унбиш-егерме чакрым юл үткәч:

– Шушында тукта, мин төшеп калам, ә син кире борылып кайтып кит. Бүген кайтам, мин кайтуга ашарга әзерләп тор! – дип арбадагы капчыгын алып, төшеп калды. Шүркә борылып кайтып киткәч, Вәчкә капчыгын аркасына асып ары китте. Урманны чыгып, Кушимән авылына килеп җитәрәк, куак арасына кереп, капчыгындагы таушалып беткән кара киез эшләпәсен алып башына киде. Аннары иске генә тузып беткән ямаулы бишмәт белән чалбар алып киде. Чүпрәккә төрелгән агачтан эшләнгән аяк алып, тез башына кидереп каешы белән тарттырып бәйләп куйды. Кынысыннан пычагын алып бер корыган шомырт агачы кисеп алып таянды да аксаклый-аксаклый алга атлады. Бу кыяфәтендә ул җитмеш-сиксән яшьлек картка охшап калды. Берәү дә танырлык түгел иде. Шулай аксаклый-аксаклый "Киняпин" тегермәне янына килеп җитте.

Тирә-як авыллардан тегермән тартырга килгән кешеләр арасына килеп утырды да берникадәр вакыттан соң кесәсеннән



яулыкка төргән төргәк тартып чыгарды. Төргәкне ботына салып чиште дә акчасын алып санарга тотынды. Акчасы хәтсез күп күренде. Тирә-ягында утырган кешеләр аның акчасына күз салып куйдылар. Бигрәк тә здоровый гына битләре кызарып торган урысның күзе Вәчкәнең акчасына төбәлгән иде.

Вәчкә акчасын тотып, таягына таянып, сул кулы белән билен тотып, уфылдый-уфылдый, басты да бөкерәеп тегермәнгә килгән кешеләр янына барып:

– Кем монда он сата? Пожалуйста, сатыгыз әле? – дип сораштырып йөргән Вәчкә урыс янына да килеп:

– Мука продаем? – дип сораган булды.

– Нет, бабай, не продаем. Мука колхозная. Председатель ругать будет, – диде урыс Вәчкәгә.

– Айда, продай, моя много не просит, один пут тульке, – дип Вәчкә юри генә кысып карады урысны.

– Нет, нет, не продам, не своя ведь! – диде теге.

– Ну, ладны! – дип Вәчкә китеп барды. Барысы да аның үтенечен кире какты. Ул үзе дә авыр сугыш елларында колхоз онын беркем дә сатмаячагын яхшы аңлый иде. Закон бик

каты иде. Сорамыйча алынган бер кесә ашлык өчен кешеләрне төрмәгә ябалар иде.

Вәчкә тегермәнче янына килеп, капчыгыннан бер шешә аракы чыгарып бирде дә акчасына кызыгып күз салган урысның кайсы авылдан килгәнен сораштырды. Хәбәр алгач, теге урыс кайтырга чыгар вакыт җиткәндә генә, Вәчкә аның кайтыр юлына чыгып китте. Урман аша үткән тар гына ат юлыннан сызгыра-сызгыра атлавын дәвам итте. Күп тә үтмәде, теге урыс Вәчкәнең артыннан куып та җитте. Вәчкә юл биргән сыман мескен генә булып читкә чыгып басты. Вәчкәне күргәч, урысның, күзләре ачылып китте.

Бу бит акчалы карт! Моны утыртып алып барып югалтырга кирәк, дигән уй килде анын башына һәм атын туктатып:

– Айда, бабай, садись, далеко едешь? – дип эндәште.

– Деревня идем! – диде Вәчкә.

– Айда, айда, подвезу! – диде урыс.

– Ладно, ладно, спасибо! – дип Вәчкә, чатанлый-чатанлый килеп, уфылдаган булып арбага он капчыклары өстенә менеп утырды. Урыс кузгалып китте.

Урысны нишләтергә дигән планы Вәчкәнең алдан ук әзер иде инде. Урыс ниятләгән уйларын ничек итеп эшкә ашырырга, ничек итеп Вәчкәне югалтырга, дип барганда, Вәчкә, мал суя торган үткер пычагын әзерләп, җайлап тотып килә иде инде.

Урыс әкрен генә алга таба иелеп, капчык астына яшереп куйган балтасын үрелеп алып, Вәчкәгә таба селтәнгәндә, Вәчкә аның кабырга арасына очлы пычагын тыгып та өлгерде. Урыс “ых” та дияргә өлгермичә, тавышсызтынсыз гына арбадагы капчыклар өстеннән җиргә тәгәрәп төште. Вәчкә дилбегәне үзенә тиз генә алды да атны туктатты. Сикереп төшеп кигән ясалма агач аягын ычкындырып, салып ташлады да, урысның култык астыннан эләктереп алып, үле гәүдәсен урман эченә өстерәп алып кереп китте. Берникадәр барганнан соң, гәүдәсен корып ауган юан гына чыршы янына алып килеп, янәшә салды да, урысның балтасы белән агач ботаклары кискәләп, гәүдәсе өстенә ташлады, аннары берничә кочак абага үләне җыеп алып

килеп, ботаклар өстенә каплады. Мәрхүмне “җирләп” эшен бетергәч, урманнан чыгып, агач аягын арбага салды да, менеп утырып атны борып, кайтыр юлга чыкты. Урыска пычак казаганда да, аны “җирләгәндә” дә Вәчкәнен чырае да сытылмады, киресенчә барган җиреннән мыек астыннан гына көлемсерәп куйды. Атына чыбыркы тидереп, югырта башлады. Шүркәдән төшеп калган юл чатына килеп җиткәч, сулга борылып кайтасы юлына кереп китте. Туктап киенгән киемнәрен алыштырып капчыгына тутырды. Яши торган торагына кайтып җиткәндә кояш түбәнәеп, көн кичегеп килә иде инде. Сизгер Шүркә арба тавышын ишетеп, куак арасына кереп посты. Карчыганыкы кебек үткер күзләре якынаеп килгән Вәчкәне күргәч, Шүркә аны чыгып каршылады. Вәчкә арбадагы он капчыкларын күрсәтеп:

– Менә кышкылыкка он булды, урнаштырып куй! – диде.

Шүркә Вәчкәгә бер сорау да бирмәде. Җиргә чокып эшләнгән складка капчыкларны ташып урнаштырганнан соң, аш әзерләп өстәлгә китереп утыртты. Көне буе ач йөргән Вәчкә, аштан канәгать булып, сәке өстенә менеп ятты да гырылдап йоклап та китте.

* * *

Кышка керер вакытлар да якынлашып килгәнен сиздерә башлады. Көндезләрен кояшлы торса да, төннәрен шактый салкынайта иде инде. Көзге җилләр исеп, агач яфраклары саргаеп җиргә коела башлады. Әрибаш урманы эчендә кышлар өчен тау итәгенә казып эшләнгән зур гына торак ясатып, Вәчкә бергә йөргән егетләреннән аның эчен җиһазландырды. Анда мич чыгартып, сәкеләр, киштәләр ясатып, идәненә тиреләр җәйдерде. Торакка якын чишмә буена мунча да эшләтте, ягарга кышкылыкка җитәрлек итеп утын да әзерләтте.

Вәчкә җылы гына кояшлы көнне, торактан ерак түгел, корып ауган юан гына чыршыга чыгып утырды да пычак сабын юнырга тотынды. Агачның икенче очында калган качкылар утыра иде. Алар үзара ни турындадыр бәхәсләшеп, тәмәке көйрәтеп утыралар. Шүркә, бер ун-унбиш адым чамасы читкә китеп, карабинын чистартырга тотынды.

Вәчкә төньяктан кыйблага таба аккан көзге куе кара болытларга карап, башын уң якка борып:

– Да, егетләр, көз җитте, агач яфраклары да коела башлады, сезгә дә вакыт якынлаша, – дип борын астыннан гына ишетелер-ишетелмәс кенә итеп әйтеп куйды. Шүркәнең сизгер колагы бу сүзләрне ишетте. Аның һәр елны көз җиткәч, шушы сүзләрне ишеткәне булды. Кайбер артык егетләр шушы сүзләрдән соң югала иде. "Ә менә быел чират кемгә җитәр микән?" – дип уйлап куйды. Ул үзе гармунчы, җырчы булуы, өстәвенә сизгерлеге, җитезлеге һәм үткерлеге аркасында гына ничәмә-ничә еллар әҗәлдән котылып кала килде ич.

Быел ул үлемнән котылып калачагына никтер шикләнеп ышанмый йөрде. Аның сизгер, яшь йөрәге аңа: "Шүркә, сиңа да быел чират җитеп килә, ахыры!" – дип кисәтү ясап тора. Соңгы вакытта нигәдер Вәчкә белән мөнәсәбәтләре дә үзгәргәндәй булды.

...Шүркә карабинын тазартып бетерде дә биш патронлы магазинын карабинына тыгып, иплэп кенә затворын тартып куйды. "Барыбер быел мине юк итәсең!" – дип карабинын Вәчкәнең артыннан җилкәсенә төзәп, курогын тартып җибәрде. Урман яңгырап китте. Агач башындагы каргалар көтүе болытсыман күккә күтәрелде. Бәхәсләшеп утырган качкылар ату тавышына кинәт кенә борылып:

– Нәрсә булды? – дип аптырап калдылар.

Вәчкә артына борылып карады да:

– Сизденмени, Шүркә, югаласыңны? – диде.

Шүркә бер сүз дә дәшмәде.

– Алай булгач интектермә мине, әйдә тагын берне җибәр?! – диде.

Шүркә аның үтенечен кире какмады. Курогын тагын бер тапкыр тартты.

Вәчкә тынсыз калып, әкрен генә утырган агач буена авып төште. Бөтен дөнья тып-тын калды. Шүркә качкылардан чокыр казытып, Вәчкәне җирләтеп куйды.

– Бүгеннән соң эшегез бетте. Таралышыгыз, башкача очрашмыйк,-дип качкыларны таратты. Берничә көннән соң Шүркәне кулга алып, җиде елга тоткынлыкка җибәрделәр.

Төрмәдән кайткач, ул әллә язмыштан куркып, әллә үзе теләмичә, әллә авыл халкыннан оялып Урал якларына китеп шахтага эшкә урнашты.

* * *

Моннан берничә ел элек Байтугай авылының юбилеен билгеләп үткәндә Пермь өлкәсеннән Шүркә дә кайткан иде. Аның чәчләре агарган, һаман да төз буйлы, ак сакаллы, яхшы костюмнан, күзлек кигән. Карап торуга профессорлар кыяфәтендә, бер дә сиксән яшь бирмәссең. Һаман да шулай аз сүзле, көлемсерәп кенә тора. Беренче тапкыр сабан туенда катнашкан кебек матур итеп тальянын сузып, моңлы итеп үзенең яраткан "Тамбов урманнары" дигән җырын авылдашларына ишеттерде. Кайда гына булмасын, кайда гына йөрмәсен, ул туган ягын, яшьлеген нык сагына, күңеле белән Байтугай болыннарында, Ушья буйларында яшьтәшләре белән су кереп йөргән чакларын хәтерләп моңлана иде.

– Эх, Байтугай, Байтугай, ник таралдың син болай! – дип көрсенеп куя, авылының таралып бетүенә аптырап.

# Бил каешы сынатты

Көннәр кыскарып, көзге салкыннар башланды. Караңгы төшәр алдыннан Талип конный дворга килеп, керергә генә торганда, конюх Фатхый абзыйның чыгып килгәнен күреп, салам өеме артына кереп посты.

– Ах, черт, чак кына эләкмәдем бит, – дип көрсенеп куйды. Ул берничә көн Фатхый абзыйның эш вакытын күзәтеп йөреде. Фатхый абзый, конный двор капкасын ябып, келәсен элдерде дә билендәге каешыннан бияләйләрен алып, урамга чыгып китте. Ул һәр көн шулай, берүк вакытта, атларын карап, су эчереп, башаклар салып, кичке ашка кайтып әйләнә иде. Талип, Фатхый абзыйның ераклашканын карап торды да, конный дворга кереп, чөйдә эленеп торган йөгәнне үрелеп алып, колхоз рәисе җигеп йөри торган, елгыр-җирән айгырның янына килеп, башына йөгәнне кидерде. Айгырны алып чыгып, киртә янына килде дә, аркылы агачына басып айгырга атланып капкадан чыгып та чапты. Ул “төн юлыннан”, Яркәй урманына таба шылды. Урманга килеп кергәч, бераз барып, сул якка борылып кереп китте. Алда торган бер имән агачы төбенә килеп туктады да, тиз генә сикереп төшеп, каеш йөгәнне тарткалап тикшереп карады, ныклыгына ышангач, үрелеп тезгенне юан гына имән ботагы аркылы үткәреп алды да, каты гына итеп тарттырды. Атның башы күтәрелеп калгач, тезгенне уратып бәйләп куйды.

Мал суяр өчен, чалгыдан ясалган үткер пычагын, билендәге кынысыннан тартып алып, айгырның күтәрелеп торган муены аркылы көч белән сызып та җибәрде. Киселгән җиреннән, фонтан шикелле кып-кызыл кан сиптерә башлады. Аны күргәч Талип, тирә яктагы үләннәрне йолкып алып килеп, атның муенына каплады. Ун-унбиш минут узгандыр, хәлсезләнгән айгырның гәүдәсе гөрселдәп җиргә ауды. Талип, тартылып торган йөгәннең тезгененә үткер пычагын тидереп алды да, атны тунарга да керeште. Мал суеп өйрәнгән Талипка, айгырны эшкәртү өчен әллә ни күп вакыт кирәкмәде. Эшен тәмамлагач, ул тиз генә, урманнан чыгып, авылга кайтты. Өй алдына кереп, мунча чарачасыннан, балтасын, көрәген һәм полиэтилен пленкасын алып, мотоцикл коляскасына салып, кире урманга чапты. Килеп җиткәч, мотоцикл фарасын яткан ат

түшкәсенә таба юнәлтеп, фара яктысында, түшкәне тураклап, пленка җәелгән мотоцикл коляскасына урнаштырды. Аннары барып агачлар арасында чокыр казып, атның башын, тиреләрен, калган җирләрен күмеп куярга булды. Ашыгып эшләгәнгә күрә, тирли башлагач билендәге каешын ычкычдырып, агач ботагына элеп куйды. Эшен бетергәч, агач ботаклары, үләннәр җыеп алып килеп, чокырны ябып куйды. Авылга кайтып, бакча артыннан, мотоциклның утын сүндереп, әкрен генә, сарай янына килеп туктады. Ит түшкәләрен сарайга алып кереп урнаштырды да кирегә барып, калганын алып кайтты. Аларны урнаштырып, тирә ягын утын түмәркәләре белән өеп тә куйды һәм өйгә кереп ятты. Талиптан "кайда булдың? Нәрсә эшләп йөрдең?" – дип тә сораучы булмады. Сорар кеше юк та иде. Чөнки, әнисе Нәсихә карчык аның тормышы белән беркайчан да кызыксынмады. Ә үткән ел хатыны Нәфисә, Талип һәрвакыт эчеп, көн дә кырылышкач, ике баласын алып, авылларына кайтып киткән иде.

Талип өйгә кереп яткач, уйлары белән Сарапулга барып, шул итләрне сатып, үзенең матаен яңартырга исәп тотып йокыга талды. Кичке аштан соң Фатхый абзый:

– Тәннәрем дә авыртып тора, бераз черем итеп алгач барырмын әле, – дип йоклап алырга булды. Ул иртән торып, чәй эчкәч кенә киенеп чыгып китте. Конный дворга килеп, атларны карап йөргәндә, Орликның үз урынында юклыгын күреп, ушы китте.

– Кая булырга тиеш? – дип үз-үзенә сорау бирде. Йөгереп чыгып, дворны әйләнеп:

– Орлик, Орлик, – дип айгырны чакырып карады. Тынтавыш булмагач тәмәке кабызды. Кайгысыннан куллары калтырана башлады. Тиздән конный дворга, колхоз рәисе Шәрипов килеп җитте, ул ишек алдында торган Фатхый абзыйның калтыранган кулларын күреп:

– Фатхый абзый, әллә өшедеңме? Берәр җирдә кунакта булдыңмы? Нигә кулларын калтырый? – диде.

– Юк, юк, өшемәдем дә, кунакта да булмадым. Менә нәрсә дип тә аңлата алмыйм. Сүз таба алмыйм... ни дип тә әйтә алмыйм.

– Я, сөйлә! Нәрсә булды? – диде колхоз рәисе.

– Иптәш Шәрипов, кичтән, атларны су эчереп, башаклар

биреп, барын да тикшереп, кичке ашка дип кенә кайтып әйләнгән идем, килүемә сез йөри торган Орликны алып чыгып киткәннәр. – диде Фатхый абзый көрсенеп, рәиснең күзләренә карап.

Колхоз рәисе тыңлап торды да, нәрсә әйтергә белмичә, борылып идарәгә менеп китте.

Кабинетына кереп, озын кара драп пальтасын салып чөйгә элеп куйды да, телефон трубкасын алып, райкомның беренче секретаре Дәһшәтовка шалтыратты.

– Сезне "Эрнест" колхозының рәисе Шәрипов борчый, – диде.

– Тыңлыйм! – дип каты гына эндәшеп куйды Дәһшәтов.

– Үткән төнне, конный двордан, минем җигә торган атны алып чыгып киткәннәр, – диде рәис.

– Шул дәрәҗәгә җиттегезме? – дип ачулы гына әйтеп куйды. –Хәзер милицияләр барыр.

Социалистик Хезмәт Герое исеме алган колхоз рәисе беренче секретарьның сүзенә кимсенеп, телефон трубкасын салып куйды.

Дәһшәтов, милиция бүлеге начальнигы Дәшмиевне үзенең кабинетына чакыртып алып, аны ишек төбеннән дә уздырмыйча, аягүрә бастырып, күм-күк иреннәренә "Беломор" папиросын кабып креслосыннан да тормыйча, Дәшмиевкә сораулар яудыра башлады.

– Когда у вас порядок будет в милиции, понимаешь? – дигән, ташка язмаган сорау биреп һушын алды.

– У нас в милиции пока порядок, нарушений нет! – дип әйтергә бик исәбе бар иде дә, тик кайтарып сүз әйтергә ярамый. Югыйсә, тәртибең бюрода каралып, яраксыз кешегә әйләнүең бар. Шуңа күрә Дәшмиев тыелды, бер сүз дә эндәшмәде, тыңлап торуын дәвам итте.

– В колхозе "Эрнест" лошадь украли, поезжай, разберись и доложи мне! Понял? Все. Иди! – диде.

– Вполне понял, – дип Дәшмиев кабинеттан чыгып китте. Ул милиция бүлегенә кайтып җиткәнче, юл буйлап:

– Шундый әдәпсез кешеләр, югары урында эшләп, робот кебек, кеше нервасын какшатып утыралар. Исәнлек-саулык та сорау юк, утыр, дип тә тәкъдим итмәде. Когда у нас порядок будет, имеш? – дип утыра бит әле. Ул эченнән генә нәфрәт белдереп, юлга төкереп куйды.

ны читкә чакырып алды да, аңа үзенең шикләре турында сөйләп бирде. Әтисе тапкан каешны күрсәтте. Әхмеров милиция эшчеләре белән аралашкач, бу юраманы тикшереп карарга булдылар Талипны идарәгә чакыртып, каеш турында сөйләргә куштылар. Ул үзе каешыннан танмады. "Әйе, минем каеш бу",-диде.

– Ничек урманда булырга тиеш соң синең каеш? – дип сорау бирде Сәүбанов.

– Утын әзерләргә барган идем, онытып калдырганмын, – дип җавап бирде Талип. – Атна буена сездә яшибез, ишек алдында кисеп алып кайткан утыныңны күрмәдек! – дигәч, Талипның йөзләре агарынып китте, куллары калтырый башлады, йөзенә салкын тир бәреп чыкты, күзләре сәерләнде.

Аның шикле кыяфәтен күреп:

– Әйдә, барып утын кискән җиреңне күрсәт әле, – дип Талипны урманга алып киттеләр. Барышлый, кереп Әхмәтзыя абзый белән Зөфәрне дә ияртттеләр. Урманга кергәч Әхмәтзыя абзый, каешны кайдан тапканын һәм кайсы агачларны кискәнен күрсәтте. Аннары Талиптан кайсы агачларны кисүе турында сорадылар. Ул агачлар кисмәгәч, күрсәтә алмады. Зөфәрнең күзе кинәт кенә имән ботагына уралып торган каешка төште.

Ул кычкырып җибәрә язды, тыелып калды.

Участковый янына килеп:

– Әнә, карагыз әле имән ботагында нәрсә уралып тора? – дип күрсәтте. Якынрак килеп карагач, йөгәннең киселеп калган, тезген очы икәнлеге ачыкланды. Талипны каты гына итеп кысып алгач, әйтер сүзе калмады. Гәебен таныды, үзенең җинаяте турында сөйләргә ризалашты. Атның башы, тиреләре күмелгән урынны да күрсәтте. Чокып алганнан соң, ат башында калган йөгән каешы белән агачтагы тезген кисәген чагыштырып карагач та, аның берүк икәнлеге ачыкланды. Зөфәрнең сизгерлеге бу җинаятьне эшен ачарга ярдәм итте. Авылга кайтып Талиптан ат итен складка тапшырттылар. Алып китеп районда, тикшерү беткәнче ябып тоттылар. Суд тиешле җәзасын бирде.

Талип тоткыннан кайтуга, дөньялар үзгәргән иде, илдә демократая урнашты. Ул маллар алып, фермер булып китте. Ике катлы коттедж салып, машинада сотовый телефон белән генә сөйләшеп йөри хәзер абзагыз.

## Кызгылт-сары буяу

*(Булган хәл)*

Таң беленеп килгәндә ГАИ капитаны фатирында телефон шалтырады. Хуҗа күзен ачып, трюмо өстендә торган будильникка күз ташлады: сәгать дүртләр тирәсе икән. Телефон тавышына хатыны да уянды.

– Бу вакытта кем булыр бу? – диде ул иренә.

– Хәзер беләбез аны,–дип телефон трубкасын алды хуҗа.

– Иптәш капитан, сезгә җыенып ДТП (юл-транспорт маҗарасы) урынына барырга туры килә! – диде дежурный.

– Нәрсә булган?

– Нефтекама-Дүртөйле юлының 24-нче километрында мәет табылу турында хәбәр алдык, билгесез транспорт иясе фаҗига урыныннан качкан. Хәзер тикшерүче Хафизова җитәкчелегендә группаны анда җибәрәм.

– Яхшы, аңладым, – диде капитан.

Ул урыныннан торып, ванна бүлмәсенә юнәлде. Ул юынган арада хатыны чәй куйган, иртәнге ашны әзерләгән иде.

Тиз генә бер чынаяк кайнар чәй эчеп өстәл артыннан торды һәм киенә башлады...

Милициянең район бүлегендә нибары ике автомобиль бар: берсе искереп беткән ГАЗ-69 (кайчандыр республика Эчке эшләр министры урынбасарын йөрткәннәр). Милиция начальнигы аны күз карасы кебек саклый. Үзеннән башка берәүгә дә аның белән йөрергә рөхсәт итми иде. Икенче автомобиль АВТОЗАК ГАЗ-51 булып, аңа гадәттә дежур машина, дип йөртәләр иде, ул вездеход, яки теләсә нинди юллардан да йөри ала. Аңарда тоткыннарны да йөртәләр, бистәдә булгалаган гаилә җанҗалларын көйләргә да баралар иде. Ә менә янгын була-нитә калса яки юл-транспорт маҗарасы булган урынга бару өчен транспорт юк. Гәрчә бүлектә берничә “Урал” мотоциклы булса да, аларның берсе дә төзек түгел. Шулай булгач, милиция хезмәткәрләре маҗара урынына кем ничек булдыра ала, шулай бара.

Бүген дә капитан өеннән ерак түгел “Южный“ автобус тукталышына юнәлде. Ул анда ярты сәгать чамасы басып торгач, шәһәр ягыннан иске “Москвич” күренде. Капитан аны кул

күтәреп туктатты һәм бераз ара булса да илтеп куярга кушты. Чөнки машина иясе Агыйдел шәһәренә эшкә китеп бара икән, ә капитанның барасы җире Арлан янынындагы борылыштан арырак иде.

"Москвич"тан төшеп калган капитанга юлаучы транспортны озак көтәргә туры килмәде, капитанны күреп такси килеп туктады. Бу аның күптәнге танышы, 1577-нче колоннадан Сергей иде. Мажара урынына тиз генә килеп җиттеләр. Сергей мәет янына килеп җитәрәк машинасын туктатты. Егерме минуттан яшь тикшерүче лейтенант Хафизова белән юл-патруль хезмәте инспекторы Вәлиев та килеп җитте.

– Нәрсә булган, иптәш капитан? – дип сорады тикшерүче.

– Минемчә, мотоциклчыны бәрдереп киткәннәр, – диде капитан мәеткә ымлап.

– Мотоциклчының кайсы яктан килүен күз алдына китерә алмыйм, – диде тикшерүче. Мажара урынында мотоцикл фарасы ватыкларыннан башка бернинди эз дә юк иде.

Шәһәр ягыннан килгән "КамАЗ"ны туктатып, сержантка юлны бүләргә куштылар. Тиздән ак төстәге "Волга" машинасы килеп туктады. Аннан "Южарланнефть" идарәсе начальнигы чыкты. Мәетне күреп:

– Күңелсез хәл, миннән берәр ярдәм кирәкмиме? – дип сорады капитаннан.

– Сезнең рация аша бүлек дежурные белән элемтәгә керергә мөмкин булмас микән, – диде капитан, ярдәмнән баш тартмыйча.

Тиздән милициянең өлкән лейтенанты Кабышев белән элемтә урнашкан иде.

– Бу мин, Гурий Кабышевич, – диде капитан. – Барлык ГАИ инспекторларын мажара булган урынга җибәрегез. Мотоциклчыны бәрдереп гаепләнүче мажара урыныннан качкан...

Егерме биш ел хезмәт иткән чорда капитанга мондый маҗараларны бик күп тикшерергә һәм ачарга туры килгән иде.

Мажара урынын җентеклэп тикшерергә керештеләр. Капитан ике пүнәтәй чакыртты. Канга тузган ир кеше мәете юл уртасында коры асфальтта ята иде. Өстендә кара телогрейка, соры төстәге чалбар, аякларында иске кирза итекләр. Мәетнең бер документы да юк, җыелган халык арасында танучы фәлән булмады.

Маҗара урынындагы коры асфальтта әллә “Урал” маркалы автомобиль, әллә “Беларусь” тракторының тәгәрмәч эзләре бераз шәйләнә иде.

Тиздән юл-патруль службасы инспекторы килеп җитте. Капитан бурычны аңлатып, аларны барлык автохуҗалыкларга һәм оешмаларга озатты. Чөнки җинаятьче җаваплылыктан куркып, төн караңгылыгына кереп югалган иде.

Җылы май ае таңы атты. Тәүге кояш нурлары күренде.

Маҗара урынын карап, схемалар төзеп, протокол язуга шактый вакыт кирәк булды. Аннары мәетне моргка озатып, хәрәкәт юлын ачтылар.

Куе зәңгәр төстәге “Иж-планета-3” мотоциклы юлның көньяк читендә якынча утыз метрлап читтә юл өемендә тәгәрмәчләре белән өске якта ята иде. Мотоциклның дәүләт номеры булмагач, кемнеке икәнен дә, мәетнең кем булуын да ачыклап булмый иде.

Капитан мотоцикл янына килеп, аны җентекләп тикшерә башлады. Рамасының тырналуы, руленең бөгелүе һәм фарасының ватылуыннан башка берни дә юк шикелле. Ләкин капитанның очлы күзләре бер тиенлек акча зурлыгында руль кронштейнына буялган кызгылт-сары буяуны шәйләде. Бу бит ят буяу, кирәге чыгуы бар, дип, берекккән буяуны акрын гына пинцет белән алып, полиэтилен капчыкка сак кына салды. Бу исбатлау өчен кирәк булачак, экспертизага озатырга кирәк...

Транспорт чарасын карауны тәмамлагач, пүнәтәйләрдән кул куйдырып протоколның эшен бетерде.

Ярты сәгатьтән юл-патруль хезмәте инспекторы өлкән сержант Камалов бирегә килеп җитте һәм болай диде:

– Иптәш капитан, якын-тирә авылларны йөреп чыктым. Нугай авылы кибете сатучысы кичтән авыл кешесе Мисбах, ярты литр аракы алып, каядыр китте, диде. Миңа Мисбахның адресын да әйтте.

– Алайса барып, Мисбахның өйдәлеген бел, әгәр өйдә булмаса, аның мотоциклы белән кызыксын, сак кына итеп, хатынын яки берәр туганын моргка барып, мәетне карауларын үтен, танысалар, җентекләп рапорт язарсың, – диде капитан.

Сержант шунда ук бер машина табып, авылга юлланды.

Капитан исә инде бу урында ике транспорт чарасының бәрелешүе турында шикләнми иде.

Капитан Галиев тикшерү нәтиҗәсенең кайнар эздән эш иткәндә генә уңышлы булачагын белә иде. Зур күләмдә эш башкарырга туры киләчәк. Моның өчен йөзләрчә предприятиеләр, оешмалар, колхозлар һәм башка объектларның автохуҗалыкларын тикшереп чыгарга туры киләчәк.

Һәр автохуҗалык җентекләп тикшерелсә дә, беренче көн нәтиҗә бирмәде. Кечкенә генә кызгылт-сары буяу исә капитанга тынгылык бирми иде. Аның бу төсне кайдадыр күргәне бар төсле...

Кинәт яшен тизлеге белән бер уй капитанның башына килде: тукта әле, узган ел машиналарга техник осмотр уздырганда бер төзелеш оешмасының автохуҗалыгында берничә машинаны шул төскә буяганнар иде түгелме?! Капитан шунда ук әлеге автохуҗалыкка юлланды.

– Нинди җилләр ташлады сезне, – дип каршы алды эксплуатация начальнигы Александра Захаровна.

– Кунакка килдем, – дип шаяртып алды капитан һәм аннары җитди итеп: кичә бик соң гына кайсы машиналар рейстан кайтты, шуларны әйтә аласызмы?–диде.

– Безнең күпчелек машиналар республика күләмендә командировкада, хәзер кайтканнарын ачыкларбыз, – диде начальник.

Александра Захаровна транспорт чараларының китүе һәм кайтуы теркәлгән журналны актара башлады.

– Сер булмаса, сезне нәрсә кызыксындыра, нәрсә булган?–диде начальник.

– Сер түгел. Узган төндә Нефтекама–Уфа юлында бер мотоциклчыны бәрдергәннәр, ул шунда ук үлгән, маҗара урынында бер кечкенә кисәк кызгылт-сары ят буяу таптык. Хәтерем ялгышмаса, узган ел сез берничә машинагызны шундый төскә буяган идегез шикелле...

– Әйе, берничә “КрАЗны, – диде ул һәм шунда ук производство-техник бүлеккә шалтыратты:

– Олег Петрович, узган ел кызгылт-сары төскә буялган машиналар исемлеген әзерләгез әле, мәсьәлә җитди, ГАИ-дан кызыксыналар, тизләтез!

Берничә минуттан исемлекне китерделәр. Әмма Александра Захаровна шоферлар арасында шикләнердәйләре юк, диде

һәм диспетчер белән смена механигын чакырды.

Капка янында кизү торган смена механигы Фәрит:

– Александра Захаровна, кичә бер үзбушаткыч КрАЗ никтер рейстан кайтмады, мин аны командировкададыр, – дип уйладым, – диде.

– Кем?

– Күптән түгел эшкә кергән яшь егет.

Шулчак телефоннан капитанга мәетнең Мисбах булуы турында әйттеләр.

– Кичә кайтмаган үзбушаткычның гаражга ничек кайтып туктавын һич аңлый алмыйм, – диде механик.

Капитан механикны ияртеп, машинаны һәм шоферын эзләргә чыгып китте. Үзбушаткыч киртә буенда тора, ә шоферы урынында юк иде.

Капитан шунда ук ике пүнәтәй белән КрАЗны тикшерергә тотынды, ә Фәриткә шоферны эзләргә кушты.

Машинаны тикшергәндә руль механизмындагы гидроусительның алмаштырылуы, сул алгы крылосының яңа гына буялуы ачыкланды. Ремонтланган өлештә кызгылт-сары буяу күренә иде. Капитан протокол төзеп, КрАЗ крылосыннан буяуны экспертизага алды һәм эксплутация начальнигы кабинетына керде.

Бер сәгатьтән шоферны да таптылар.

– Йә, сөйлә, ничек булды? – диде капитан шоферны каршысына утыртып.

– Нәрсәне, кайда, ничек? – дип белмәмешкә салышты шофер.

Әмма капитан:

– Узган төн Нефтекама–Уфа юлына ничек барып чыктың?– диде.

– Мин анда булмадым, берни дә белмим, – дип үзенекен тукыды шофер.

– Ярый алайса, ә ник машинаның сул крылосы яңа гына буялган, электр үткәргечеңне дә яңа гына изолента белән урагансың. Моны ничек аңлатасың.

– Мин участокта ялгыш баганага бәрелдем...

– Яхшы, бәрелгән урыныңа барабыз. Тик менә бер сорауга җавап бир әле, Мисбах мотоциклының руль кронштейнында синең үзбушаткыч буявы каян барлыкка килгән соң?

Айрат (шофернын исеме шулай иде) бу сораудан соң югалып калды, агарынып китте, күзләре сәерләнде һәм шунда ук:

– Ярый, барын да сөйләп бирәм, – диде. Эштән соң авылдашым Хатип Борай районына әнкәләренә бер капчык он кайтарып бирүемне үтенде. Мин каршы килмәдем һәм без авылга киттек. Анда безне сыйладылар, мин бер стакан аракы да эчтем. Аннары кайтырга чыктык. Инде соң иде, тизрәк гаражга кайтып керер өчен ашыга идем. Кайтып җитәргә егерме километрлап калгач, каршыга килгән мотоциклны күреп калдым, тик инде соң иде. Читкә алдырып өлгерә алмадым, ул машинамның сул крылосына тиеп китте һәм юл читенә очты. Куркуымнан газга басып юлымны дәвам иттем. Белмәсләр, тапмаслар, дип уйлаган идем... Ул көнне гаражга кереп тормадым, ә икенче көнне гравий ташыган завод территориясенә кереп, машинаны ремонтладым да, механикның капкадан киткән уңай чакны туры китереп, гаражга кердем. Аннары төшке ашны ашарга киттем.

Ярый, киттек бүлеккә, анда җентекләп күрсәтмә бирерсең, – диде капитан.

Бүлеккә кайту белән Галиев Айрат машинасыннан алынган буяуны һәлак булучының мотоциклыннан алынган буяу белән чагыштыру өчен экспертка бирде. Бер сәгать тә үтмәде, эксперт шалтыратты:

– Иптәш капитан, буяулар туры килә, җинаять эшен уңышлы ачуыгыз белән котлыйм сезне.

Тикшерүче бу фаҗига буенча җинаять эше кузгатты. Мисбахны туганнары җирләделәр, ә маҗара урыныннан качып котылмакчы булган Айрат тиешле җәзасын алды.

# Бер савыт гөл

Район яңа гына оешканлыктан, күпчелек оешмаларга эш урыны җитми иде. Вакытлыча берничә оешма бер бинада урын алды. Әлбәттә, бу оешмаларга яшь белгечләр дә килгән иде. Шулар арасында яңа гына югары уку йорты тәмамлап кайткан Гаделҗан да бар иде. Ул үзенә бирелгән бүлмәне яхшы итеп ремонтлаткач, җиһазландыргач, эшен тәртипкә салып җибәрде һәм йомыш белән килүчеләрне кабул итә башлады.

Шушы ук бинада эшләүче Гөлбәдәр пөхтә генә йөргән, кара чәчле, чибәр егетне күреп, аңа күз салды. Яшь ханымның йөрәге дертләп китте, әйтерсең лә, бикләнеп туктап торган йөрәген кемдер серле ачкыч белән ачып җибәрде. Ул, егетне күреп, килгән җиреннән башын сәер генә читкә борып, адымнарын тизләтеп, күрмәмешкә салышып, яныннан узып китте.

Гөлбәдәр кабинетына кереп, өстәл артына утырды да үз-үзенә сорау бирде:

– Тукта, миңа нәрсә булды соң әле? Ни эшләргә, йөрәгем үзенә урын таба алмый, калтырый, нәрсәдер эшләргә куша төсле.

Шулай уйланып тынычлана алмый утырганнан соң, кинәт кенә урыныннан торды да тәрәзә төбендә үзе үстергән матур гөлләре арасыннан иң кадерлесен алып, каршы очраган егетнең кабинетына кереп, ишек яңагына сөялде. Алар бер сүз дә дәшмичә, бер берсенә озак кына карап тордылар.

Егет кызның сылулыгын күреп хәйран калды, аның күз алдында бер матур күлдә йөзүеннән туктап калган аккош торгандай булып тоелды. Кыз шул кадәр зифа буйлы, сөйкемле, чибәр иде. Ничек итеп сүз башларга, дип урыныннан торып басты. Шул арада кыз:

– Исәнмесез! Менә бүлмәгезне котлап, бүләккә сезгә гөл керттем. Рәхим итеп кабул итегез, – дип гөлне тәрәзә төбенә китереп куйды да елмаеп чыгып та китте.

Артыннан зәңгәр борчак төшкән ак күлмәге җилфердәп кенә калды.

Гөлбәдәр бүлмәсенә кереп урынына утыргач, уфтанып, көрсенеп куйды. Бу юлы аның тәнен иркәләп, җылы җилләр сыйпап үткәндәй булды. Иркенләп сулыш алып, тәрәзә төбендә утырган гөлләргә карап:

– Бүләгемне охшатыр микән? – дип уйлап алды.

Гаделҗан ул кызны башкача бинада күрмәде.

– Кем булды соң әле ул чибәр кыз? Кая булды? Фәрештә кебек күренеп китте дә күз алдымнан югалды, – дип берничә айлар юксынып йөрде.

Бер көнне шәһәр урамыннан үтеп барганда Гаделҗан теге сылуны очратты.

– Саумысыз? Ә мин сезне югалттым. Кая булды икән? – дип үземә урын таба алмый йөрдем. Гөл бүләк иткәндә нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап калган идем. Хәтта исемегезне сорарга да өлгермәдем. Болыт арасына кереп югалган кояш кебек, күземә күрендегез дә юк булдыгыз. Сезне кабаттан күрергә, дип күпме өметләнеп йөрсәм дә, нәтиҗәсе булмады. Исемегезне дә, кайсы оешмада эшләвегезне дә белми калдым. Ходай бар икән. Менә бит сезнең белән янә очраштырды! – дип, кызның кулларыннан йомшак кына алып:

– Ә хәзер сорарга рөхсәт итегез, исемегез кем була? – диде.

– Минем исеме Гөлбәдәр! – диде, кыз гөлен куеп чыгып киткәндәгедәй матур елмаеп.

– Ә минеке Гаделҗан! – диде егет. – Кая югалдыгыз, Гөлбәдәр? – дип сылуның күзләренә тутырып карады.

– Мин хәзер анда эшләмим, ясалма күн комбинатына күчтем.

– Нигә элекке урыннан киттегез? Әллә эшегезне ошатмый идегезме?

– Юк, эш анда түгел! Сәбәбе икенче, аны бер сүз белән генә аңлатып булмый. Ул күңелсез вакыйганы аңлатырга байтак вакыт кирәк! – дип көрсенеп куйды кыз.

– Ә мин ул вакыйганы белә аламмы? Әгәр ачсагыз, мин күпме вакыт кирәк булса да тыңларга риза булыр идем,– диде Гаделҗан, һаман да кулларын җибәрмичә.

– Ә сезнең вакытыгыз бармы соң?

– Бар, минем бүген ял көнем.

– Алай булгач, минем дә бүген эштә кыска көн булды. Кичке сәгать алтыларга гына кайтырга тиеш әле мин.

– Яхшы, әйдәгез киттек! – дип Гөлбәдәрне машинасы янына алып килде дә утыртып шәһәр читендәге яшь имәннәр

үсеп утырган яланлыкка килеп туктады. Алар җиргә төшеп, машинаның алдына килеп сөялделәр.

Гөлбәдәр шаулап үскән киң колачлы яшь имәннәргә карап:

– Менә аларның нинди хәсрәт-кайгылары бар микән? Карагыз әле нинди гөрләшеп үсеп утыралар, әнә җилдә бер берсе белән кочаклашып серләшәләр. Кешеләр бит андый түгел, – дип сүз башлап җибәрде.

– Нигә андый чагыштыру китердегез әле,–диде Гаделҗан кызыксынып.

– Кайбер кешеләр көнчелләр, бер берсен күрә алмыйлар, мәхәббәткә каршы киләләр. Менә, Гаделжан, син минем хәлләрне тыңларга ризамын, – дип әйткән идең! – диде Гөлбәдәр, әйтерсең алар бер-берсен күптән белгән кебек тартынмыйча, сүз башлап.

– Әйе, әйткән идем, тыңлыйм, йә сөйләгез! – дип Гөлбәдәрнең уйчан күзләренә карап алды.

– Гаделҗан, исегездәме, мин сезгә гөл бүләк итеп керткән идем?

– Әйе, исемдә. Ул көнне минем бер кайчан да онытачагым юк. Миңа гөлегез бик ошады, үзегез кебек бик матур. Кабинетыма килеп кергән саен, шул гөлгә карап, сезне искә алам.

– Менә шул көнне минем сезнең бүлмәгә гөл күтәреп кереп киткәнне юл төзү оешмасының өлкән бухгалтеры күреп калган иде. Шул хатын пычрак күңелле булып чыкты. Бу хәлне минем иргә җиткергән. Өйгә кайткач, зур тавыш купты. Ирем үз-үзен тота алмыйча, ярсый-ярсый тиргәп, мине каты итеп кыйнады. Күгәрмәгән җирем калмады. Шуннан соң берничә көн бик каты сызланып йөрдем. Сезне очратканнан бирле күтәренке күңел белән йөри идем. Бөтен җыелып килгән хисләремә киртә корды да куйды. Аннан китеп башка эшкә күчәргә кушты, – дип сүзен тәмамлады ул.

– Хәзер инде ничек? Сүрелдегезме. Шул киртәне күреп? – дип сорады Гаделҗан.

– Юк, киресенчә, миндә яңадан тагын да көчлерәк хисләр уянды. Менә бүген сезне күргәч, нәрсә эшләргә дә белми, югалып калдым! – дип Гаделҗан янына якынлашып, аның иңсәсенә кулын куеп, үзенең тойгыларын аңлатты.

Гаделҗан да араны кыскартып, Гөлбәдәрнең биленнән кочып алды.

Шунда ярсып торган иреннәре бер берсенә терәлде.

Шуннан соң алар бер-берсен яратулары турында белдерделәр.

– Гөлбәдәр, ирешнең шундый яманлыгыннан соң синдә нинди караш калды?

– Мин үземнең хисләремне яшермәдем дә. Әйе, ул егетне мин яратам, – дип ярып салдым.

– Алай кирәкмәс иде. Югыйсә киләчәктә ул сине һәрвакыт кимсетеп, каһәрләп яшәр бит.

– Мин риза төрле сынауларга да! Мин аңа яратып чыкмадым. Ул иптәшләре белән мине исерек килеш урлап алып китте. Алып килгәч, ризалыгымны да сорап тормады, үз максатына иреште. Шуннан соң мин аны ничек итеп яратып торырга тиеш соң, Гаделҗан? – диде дә мөлдерәп чыккан күз яшьләрен куллары белән сөртеп куйды.

– Шундый вөҗдансыз кешеләр дә бар икән бу дөньяда, – дип куйды Гаделҗан.

– Бар шул, бар, өстәвенә ул әле синнән үч алачагы турында да әйтте.

– Ничек? Минем аңа нинди зыяным тигән? – дип аптырап калды Гаделҗан.

– Мин дә аңа шул сүзләрне аңлатып әйттем. Аның гаебе юк, мин аны яратам, ә ул ятатамы,ө юкмы, анысын белмим, – дидем. “Безнең гаилә арасына кермәсен”, – ди. Ул керми, дип аңлатырга тырышсам да, аның мәнсезнең, үз туксаны туксан.

– Әйт әле, Гөлбәдәр, ә теге өлкән бухгалтерга нәрсә кирәк булган? Нигә ул гаиләгез арасына кергән?

– Күрәсең тар эчле. Аның күңелендә кешегә начарлык кына эшләү. Ул сөю дигән нәрсәне күз алдына да китерә алмыйдыр.

– Шундый шартларда гаиләңдә килешеп яшәве авыр булачак бит!

– Әйе, мин моны яхшы анлыйм, киләчәктә аның битәрләвенә килешеп яши алмыйм. Киләсе елга югары уку йортына яки техникумга укырга керергә иде исәбем, – диде Гөлбәдәр.

Сөйләшә торгач вакытның узганын сизми дә калдылар.

– Кайтырга вакыт, Гаделҗан, сүзләрем күп җыелган иде. Әгәр Ходай тагын очраштырса, сүзләребезне дәвам итәрбез. Ә хәзер юлга, кайтырга кирәк, – диде Гөлбәдәр.

Бер көнне телефон трубкасын алуга Гаделҗан таныш тавыш ишетте.

– Гаделҗан, бу мин Гөлбәдәр, сиңа үтенечем бар!

– Тыңлыйм сине!

– Исеңдәме, мин сиңа укырга керергә иде, дип сөйләгән идем.

– Исемдә.

– Мин бит быел керергә булдым. Документларымны туплап, Уфага финанс-икътисад техникумына җибәргән идем. Чакыру кәгазе килгән, иртәгәгә барып җитәргә кирәк. Чакыруны миңа бүген генә тапшырдылар. Күрәсең, аны кемдер тотып торган, минем укырга керүне өзәргә, комачауларга булган... Мине иртәгә иртә белән башкалага илтеп куя алмассыңмы?

– Яхшы, ярый, проблема түгел бу. Кайда очрашабыз соң?

– Мин сәгать алтыларда автовокзал янында булам.

– Аңладым, көт. Очрашканга кадәр, сау булып тор, Гөлбәдәр.

Гаделҗан алты тулганчы ук автовокзал янына килеп, Гөлбәдәрне көтеп алды һәм алар Уфага юл тотты. Юл Агыйдел күперенә җиткәнче диярлек нарат урманы аша сузыла. Иртәнге таңда ачык тәрәзәдән урманның хуш исләре аңкып, бөтереләп машина эченә тулды. Аларның күңелендә күтәренке хисләр уянды, булган мәшәкатьләре онытылып, артта калып югалды. Сөйләшеп бара торгач Агыйдел елгасына җиткәннәрен дә сизми калдылар.

– Гөлбәдәр, кара әле, нинди матур булып килә, – диде Гаделҗан, Агыйдел дулкыннарын ерып килгән ак пароходка ымлап.

– Хәзер, сезон, халык ял итә, бу туристлар пароходы, – диде ханым, чөнки аларның авыллары Агыйдел буенда урнашканлыктан, Гөлбәдәр кыз чагында елга ярына шомырт җыярга барганда, ак пароходларга сокланып аларны кул болгап озатып кала торган була. Бу юлы да ул пароходка кул болгавын сизми дә калды.

Бераздан урманнар бетте. Юлның ике ягында җәйрәп яткан иген басулары башланды. Шуларга карап Гаделҗан:

– Быел уңыш мул булмакчы, – дип куйды.

Юл буена сөйләшеп барып, алар бер-берсенең тойгыларын белдерделәр. Башкалага килеп җиткәч,

Гөлбәдәр уку йортына кереп чыкты да:

– Гаделҗан, миңа имтиханнарны тапшырырга кирәк. Синең белән кайта алмыйм. Исән-сау кайтып җит, дип саубуллашып кереп китте.

Бер көнне шалтыраган телефон трубкасын алып Гаделҗан:

– Тыңлыйм сезне! – диюгә, – Бу мин Гөлбәдәр, – дигән тавыш ишетелде.

– Гөлбәдәр! Син каян шалтыратасың? Хәлләрең ничек? – дип сорады Гаделҗан дулкынланып. – Я сөйлә нинди яңалыкларың бар?

– Яңалыкларым шул: имтиханнарымны яхшыга биреп кайттым. Эшемне дә алыштырдым, хәзер укуыма җайлаштырырга булдым. Мәгълүматлар җыю идарәсендә эшлим.

– Ярый, мин бик шатмын синең өчен. Минем дә хәлләр әйбәт, – диде Гаделҗан.

Аның күңелләре күтәрелеп китте. Гөлбәдәрне күреп, матур күзләренә карап, елмайган йөзләрен күрәсе килде. Күңеленең кыллары ниндидер якын моңлы көйләр хәтерләтте.

– Гөлбәдәр! Минем сиңа әйтер сүзем бар иде, тик телефон аша түгел!

– Яхшы, мин риза. Кайда очрашырга икәнен үзең әйт!

– Кафега барабызмы?

– Юк, минем андый тавышлы урында утырасы килми. Минем тыныч җирдә, саф һавада буласым килә.

– Ярый, аңладым. Су буена төшәрбез.

Иртәгәсе көнне Гаделҗан базарга кереп кирәгенчә җиләкҗимеш, яшелчә алды, юл уңаеннан сугылып кибеттән “Зимфира” дигән яхшы шәраб сатып алды. Гөлбәдәр сөйләшенгән урында аны көтә иде, алар кузгалып киттеләр. Ярты сәгатьләп юл үткәч, матур урынга, су буена килеп туктадылар. Су өстендә акчарлаклар канатлары суга тияр-тимәс кенә итеп кычкырышып очалар.

Гаделҗан пакетын алып Гөлбәдәргә тоттырды. Алар табын корып, бер берсенә капма-каршы утырдылар. Шулчак Гаделҗан ханымның нурлы йөзенә карап:

– Гөлбәдәр, син бик аңлы, тыйнак, саф күңелле. Нигә

барысы да сиңа каршы төшәләр. Теге өлкән бухгалтер да мәкерлелеге, эчкерлелеге белән сине авыр хәлгә дучар итте. Имтиханга унбиш көн алдан килгән чакыру кәгазен дә бер көн кала гына тапшырдылар. Сине кыен хәлдә калдырырга тырышыптыр, мөгаен, – дип кызыксынды.

– Беләсеңме, Гаделҗан, син үз соравыңа үзең үк җавап бирдең. Мәкерле һәм көнчел, дип. Дөрес, ул кеше тормышы белән хисаплашмый торган адәм. Ходай андый кешегә кирәкле җәзасын бирердер. Икенчедән, минем ир укымышлы кеше белән түгел, ә надан, авыл хатыны белән, аны үзенә буйсындырып яшәргә тели. Минем уку йортына керүемә күптәннән каршы төште. Шуңа чакыру кәгазен бирмичә, яшереп тоткан. Барып җитмәс, имтиханнарын тапшыра алмас, дип. Ә без җитештек, үземнең максатка ирештем. Сиңа зур рәхмәт, мине вакытында илтеп җиткергәнең өчен. Мин беренче күрүемдә үк синең гадел кеше икәнлегеңне аңладым.

– Әйе, усаллык һәм тискәрелек белән хатын-кыз күңелен яулап алып булмый. Яхшы ир тәрбияче, акыллы киңәшче булырга тиеш, ә ул киресенчә, сине аңлый алмый.

– Гаделҗан, син бит сөйләсе сүзем бар, дип чакырдың. Ә үзең сорау аласың...

– Әйе, гафу ит, – диде Гаделҗан көрсенеп.

– Тыңлап карыйк, нинди сихерле сүзләрең бар икән?

– Гөлбәдәр, мин сине тәүге күрүемдә үк ошаттым. Шуннан башлап күңелемдә тынгы юк.

– Андый сүзләрне кайсы язучы китабыннан укып сөйлисең әле? Син минем уйларымны минем үземә сөйләмә, – диде Гөлбәдәр.

Җыенып кайтырга чыгып бераз юл үткәч:

– Гаделҗан, минем бер алтын алкам төшеп калган. Кайда төште икән? – диде ханым.

Гаделҗан машинасын кире борып, ял итеп утырган җиргә килделәр. Бөтен җирне карап, эзләп табалмагач:

– Ярый инде, югалса югалыр, кайтабыз, – диде Гөлбәдәр.

Кузгалырга гына торганда, Гаделҗанның күз карашы үлән арасында ялтыраган әйбергә төште. Бу – алар эзләгән алтын алка иде.

– Менә таптым, – дип ханымга сузды.

– Рәхмәт, хәзер тынычланырга да була. Югыйсә яхшы кәефкә төшенкелек өстәлә язды, – диде ул.

– Гөлбәдәр, бүгенге очрашуыбызга үкенмисеңме?

– Юк, киресенчә, шатмын! Бүгеннән соң мин үземне икенче, ирекле кеше итеп хис итәм,– дип саубуллашып төшеп калды кайтып җиткәч.

Икенче көнне аралашканда Гөлбәдәрнең сәер тавышын ишетеп:

– Гөлбәдәр, әллә өйдә уңайсызлыклар килеп тудымы?– диде Гаделҗан.

– Әйе, кичә төшке ашка кайтмаганга мине югалткан. Безнең арада төпле сөйләшү булды.

– Бу очракта мин гаепле, гафу ит. Үтенеп сорыйм.

– Ярый, Гаделҗан моны куеп тор. Мин бер яңалык ишеттем. Теге бухгалтерны эшеннән куганнар бит. Минем йөрәк әрнүен Ходаем ишеткән, ахыры.

Күп вакытлар Гөлбәдәрне интектереп яшәткәне өчен Тимерханга да Ходайның карашы үзгәргән булса кирәк. Минминлеге аркасында Тимерхан исерек килеш мотоциклы белән авып, каты җәрәхәтләнеп, озак кына дәваханәдә ятып чыкты чыгуын, әмма элекке гадәтен барыбер ташламады.

Гөлбәдәр исә укуын уңышлы тәмамлап, яраткан эшендә эшләп, үзенә охшаган чибәр кыз үстерә. Кайчагында Гаделҗанны исенә төшереп куя.

# “Мәчтүрә” әби

Дежурныйдан мажара турында хәбәр алганда көндезге уникеләр тирәсе иде. Автоинспектор Вәлиев папкасын алды да, җыенып чыгып, үзенә беркетелгән “Урал” мотоциклын кабызды да мажара булган якка таба кузгалып китте.

Ул килеп җиткәндә, халык мажара урынын сабантуй сыман уратып алган иде, Вәлиев мотоциклын юлның уң як читенә туктатып, кешеләр янына килеп басты, халык шул кадәр күп җыелган иде, хәттә каян керергә дә урын тапмый торды. Ул бераздан:

– Кая, үтәргә рөхсәт итегез әле, юл бирегез,-дип мажара булган урынга этешә-төртешә үтеп керде.

Урам уртасында, юлга аркылы яткан бер карчыкның үле гәүдәсен кочаклап утырган бер картны, ике егетне һәм бер кыз-хатынны күргәч, ирексездән:

– Нәрсә булды?-дип сорады.

Мәетне кочаклап утырган кешеләр башларын да күтәрмичә үкси, үкси елыйлар, барысыннан да ныграк, әбинең башын тотып утырган кыз-хатын такмаклый, такмаклый акырып елый:

– Әникәем, бәгърем, ниләр булды сиңа? Нигәләр безне ташлап киттең? Әле генә исән идең бит.

Бу сүзләрне тыңлаган автоинспектор, елаган кыз, үлгән карчыкның кызы, янында утырган карт әбинең ире, теге ике егет уллары икәнлеген аңлап алгач:

– Ярый, җитәр, торыгыз әле! – диде. Тегеләр бераз тынычлана төшкәч шулай да:

– Кемегез була бу әби? – дип сорады елап утырган кыз янына килеп.

– Безнең әнкәй, безнең әнкәебез,– диде башын күтәрә төшеп үкси, үкси мәет янында утырган кыз.

Килгән тикшерүче лейтенант Даутовны күреп алгач автоинопектор:

– Ярый, без хәзер мажараны тикшерә башлыйбыз, ә сез хәзергә читләшеп торыгыз!–диде мәет янында утырган туганнарына. Алар, автоинспекторның сүзенә игътибар да итмичә, беркемне дә якын җибәрмиләр. Әбине кузгатырга да рөхсәт итмиләр. Хәтта тикшерүчене дә якын җибәрмәскә уйлаганнар иде.

– Мин тикшерүче булам! – дип каты гына әйткәч, әби

янында утырганнар торып бераз читләштеләр. Даутов автоинспекторга якын килеп, сораштырып вакыйга турында нәрсә булганын аңлагач, әбинең кызын читкәрәк чакырып алды да:

– Ярый, тынычланыгыз! Исемең кем була әле синең? – дип сорады.

– Мин Марфуга булам, – диде ул тотлыгып.

– Ә әбинең исеме кем, фамилиясе ничек? – дип сорады тикшерүче Марфугадан.

– Гатауллина Мәчтүрә була.

– Кайда яшисез? Ерак торасызмы?

– Әнә моннан ерак түгел, Октябрьская урамында яшибез.

– Марфуга әйт әле, әниең кая киткән иде?

– Әнкәем пенсия акчасы алгач, күптән түгел генә базарга барып чәй, шикәр комы гына алып кайтам, дип чыгып киткән иде, менә нәрсә булган бит,– дип кычкырып елап җибәрде.

– Тукта әле, тынычлан. Ә нәрсә булган соң? – дип сорады тикшерүче.

– Күрәсез бит нәрсә булганын, әнә теге тополь агачы арасына кереп кысылган автобус шоферы әнкәемне таптап, өстеннән үтеп киткән, диде үкси-үкси Марфуга.

– Чынлап та сезнең әниегезме? Таныдыгызмы? Улмы соң?

– Әйе, әйе ул, менә бит аның кара сумкасы. Марфуга мәет янында яткан сумкадан алган дисбесен күрсәтеп. Ул беркайчан да үзеннән калдырмый, сумкасында йөртә иде. Әнә аягындагы ак оекбашы, куныччлы галушы да аныкы бит.

Тикшерүче Марфугадан сораулар алгач, мажара урынын тасвирлау өчен папкасыннан протокол кәгазьләрен алып, үзенең матур хәрефләре белән яза башлады. Маҗара урынын язып бетергәч, чиста протокол бланкасын алып, үлгән карчыкны тасвирлап язарга кереште. Әбинең кызы Марфуга әйткәнчә, мәетнең башында чәчәкле яшел саргылт яулык, өстендә алсу чәчәкләр төшкән озын яшел күлмәк, аягында ап-ак йон оекбаш, куныччлы галуш. Гәүдәсе кыйблага таба караган, чалкан ята. Йөзе канга буялганга күрә битен танып булмый. Аяк очында кара сумкасы тора.

Тикшерүче протокол кәгазьләрен язып тәмамлагач, тикшерүдә катнашучыларны чакырып алып имзаларын куйдырды.

Мәетне тасвирлап бетергәч, папкасыннан кәгазь алып мә-

етне моргка җибәрергә юнәлеш кәгазе яза башлады. Язып бетерер алдыннан автоинспекторга карап:

– Ярый, хәзер мәетне моргка җибәрергә машина кирәк булыр инде,-диде.

– Яхшы, машина табарбыз!– дип җавап бирде автоинспектор аның үтенечәнә.

– Менә юнәлеш кәгазен алыгъыз!– дип автоинспекторга сузды.

– Тикшерүче белән автоинспекторның сөйләшүләрен тыңлап торган әбинең карты, малайлары һәм кызы Марфуга автоинспектор янына килеп:

– Иптәш лейтенант, зинһар өчен мәетне җибәрмәгез инде, үтенеп сорыйбыз, анда алып барып ярмасыннар инде. Үзебезчә, мөселманнарча гына тәрбияләп күмәрбез,– дип үтенеп сорый башладылар.

Вәлиев аларга карап:

– Эш миннән тормый бит, мин рөхсәт итә алмыйм, тикшерүче биргән юнәлеш кәгазен алгач боерыгъын үтәми булдыра алмыйм! – диде.

Шунда ук тикшерүчене уратып алдылар да автоинспекторга биргән сорауларны яудыра башладылар.

– Иптәш следователь, мәетне җибәрмәгез инде, автоинспекторга биргән юнәлеш кәгазен алыгыз инде,– дип ялынып сорарга керештеләр. Тикшерүче йомшак кына итеп:

– Иптәшләр, тикшерүләр беткәч, эш судка җиткереләчәк, тәртибе шулай булгач без хәл итә алмыйбыз, судта бу хәлнең нәтиҗәсе булмаса, суд эшне карамаячак. Тикшерүченең аңлатуына карамастан алар тынычланмыйча әбине кочаклап елый башладылар.

Әбине бәреп киткән ПАЗ автобусы, юлдан сул як читкә чыгъып, канауны аркылы үтеп, ике тополь арасына кереп кысылган. Әгәр дә өй алдында тополь агачлары булмаса, автобус өй эченә кереп киткән булыр иде. Автобус шоферы ишекләрен бикләп, кабинасыннан төшәргә куркып утыра, чөнки әбинең малайлары үч алабыз, дип шоферның котын алганнар, кабинасыннан тартып алып кыйнарга теләп, автобус тәрәзәләрен ватып, кырып бетергәннәр. автобус шоферы зур гәүдәле, киң күкрәкле, көчле егет булуына карамастан, куркуыннан агарып каткан, күзләре пыяла сыман ялтырап тора, ныклап сүзен дә аңлата алмый.

Автоинспектор, аның кыяфәтен күреп, автобусыннан төшмәскә кушты.

Базар ягыннан әкрен генә, ашыкмыйча, салмак кына басып уң кулына кара сумка тотып, башына чәчәкле яшел саргылт яулык бәйләгән, өстенә алсу чәчәкле озын яшел күлмәк, аягында оекбаш, кунычлы галуш кигән бер әби кайтып килә. Анда җыелышып торган халыкны күреп, әби адымнарын кызулатты.

– Нәрсә булды икән? – дип кызыксынып, җыелып торган кешеләр янына килеп басты. Әби бик кызыксынучан булып чыкты. Ул түземсезлек белән, нәрсә булганын үз күзем белән күрми торып, тынычлана алмыйм дип, сөйләнә-сөйләнә этешә-төртешә җыелган халык арасына үтеп керә башлады.

Кайгылы гына басып торган кешеләрнең берсе:

– Кая керәсең инде? Сиңа нәрсә калган анда! – дип әбине кертмәскә тырышып караса да, әби эндәшмичә генә үзенең юлын дәвам итте. Тырыша торгач, ниһаять, аларның алдына кереп басты.

Бераз басып торганнан соң, уң кулын кашлары өстенә куеп, уңга, сулга карый башлады. Карана торгач аның күзләре кинәт кенә мәет янында елап утырган кызы Марфугага төште. Ул кызы янына якынрак килеп басты да:

– Марфуга кызым, синме бу? Нәрсә булган?– дип эндәште. Марфуга янында карты белән малайларын да күреп алгач:

– Ә сез монда нәрсә эшләп утырасыз?– дип сорады Мәчтүрә әби. Таныш тавышны ишетеп Марфуга кинәт кенә башын күтәреп карады. Алдында әнисенең, Мәчтүрәнең басып торганын күргәч, сикереп торып басканын сизми дә калды, әнисенең кочагына ташланды. Аны кысып кочаклап алып, сөенеченнән тагын да ныграк акырып елый башлады:

– Әнкәем, бәгърем, син каян килеп чыктың? Синме бу? Күземә күренәсеңме әллә? Без бит бу мәетне син дип, күпме күз яшьләре түгеп утырабыз. Бөтен кигән киемнәре дә синеке төсле бит. Күршеләр килеп әйткәч, йөгереп килеп, куркудан сиңа охшаттык,– диде Марфуга сөенеченнән елый-елый. Кайгылы гына кыяфәттә, башларын түбән иеп басып торган кешеләр, бу хәлне күреп, барысы да берьюлы һаваны дулкынландырып:

–Ха-ха-ха,– дип көлеп җибәрделәр. Бөтен урам яңгырап китте.

– Ни булды икән, дигәндәй, автобус шоферы кабинасыннан атылып килеп чыкты, әллә әби терелде микән? – дип уйлап, автобус түбәсенә ничек итеп менеп басканын да сизми калды. Ул халык җыелган якка үрелеп-үрелеп караса да, халык арасыннан аңа бернәрсә дә күренмәде. Мәчтүрә әбине карты, малайлары һәм кызы күтәреп алдылар да мажара урыннан чыгып кайтып та киттеләр. Күп тә үтмәде, әйтерсең лә, җыелып торган халыкның барысын берьюлы җил очырып алып китте, берсе дә калмады.

Тикшерүче, култык астына кыстырган папкасын ныграк кысып, аптырап "Мәчтүрә" әбиләр киткән якка карап калды.

– Менә сиңа "Мәчтүрә" әби, һавадан төште дә бөтен халыкның һушын алып, безгә кабаттан эш ясап кайтып китте,– диде ул автоинспекторга карап. Автобус шоферының әлегә кадәр автобус түбәсендә басып торганын күреп:

– Төш инде, вакыт җитте, кил безнең янга,– диде тикшерүче.

Автобус шоферы әкрен генә шуышып төшеп аның янына килде.

–Я, сөйлә, ничек булды? дип сорады.

– Мин центрга бара идем, түбән тизлек белән. Әби юлны чыгарга уйлады булса кирәк, кинәт кенә минем як юлга чыгып басты да, бер уңга, бер сулга таба тайпыла башлады. Мин аны юлга чыгар, дип уйламадым, тормозга бастым, ләкин әбигә кадәр бик кыска ара калды, автобусны туктатып өлгерә алмадым, рулемне сулга борып юл читенә төшеп киттем, әнә теге агачлар арасына барып кысылдым,– дип аңлатып бирде.

Даутов белән Вәлиев җиң сызганып мажараны кабаттан тикшерә башладылар. Тикшерү беткәч, исемсез әбинең гәүдәсен йөк машинасы туктатып, морг бинасына салып җибәрделәр. Автоинспектор автобус шоферын мотоциклына утыртып экспертизага алып китте.

Редакциягә белдерү биргәннән соң, берничә көннәр узгач, туганнары килеп, мәетне танып, алып киттеләр. Автоинспектор "Мәрхүм Мәчтүрә" әбинең кыямәт көнендә урыны оҗмахта булсын инде, дип артыннан теләп калды.

# Чаган-Тау серләре

Таш-Елга авылына барыр өчен ике юл бар. Берсе Бүә елгасының яры буеннан үтә торган ат юлы. Бу юлның төньягында биек Чаган-Тавы, көньягында Бүә елгасының иске үзәне үткән текә яр, ә көнчыгыш ягында авылга таба төшә торган җире хәтсез биек, хәтта җәяүлегә дә менеп, төшеп йөрүе читен.

Ә икенчесе Чаган-Тауны урап бара торган юл, анысы шактый ерак, аны үтү күп вакытны ала, җитмәсә, ул юлның бик уңайсыз ягы да бар, коеп яңгыр явып узса, озак вакытлар кызыл балчык машина тәгәрмәченә уралып, үтәрлек булмый, трактор белән өстерәп йөрергә туры килә. Машина, трактор узганнан соң, калган колеялардан озак вакытлар йөреп булмый.

Авылда урнашкан малчылык фермасы, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары, совхозга зур табыш биреп, күп файда китергәнгә, "Буй совхозы" директоры Таш-Елга авылына турыга йөри торган ат юлын киңәйтеп, тигезләтергә булды. Ул кичтән тракторчы Хәмит агайны үзенең кабинетына чакыртып алды да:

– Хәмит агай, син бүген үк тракторыңны карап, кирәген тагып, әзерләп куй, иртәгә Таш-Елга авылына турыга йөри торган юлны машина белән үтәрлек итеп, киңәйтеп, тигезләргә барасың. Без менә идарәдә шундый карар кабул иттек,– диде совхоз директоры Вәлиев.

– Яхшы, аңладым, иптәш директор!- дип чыгып барганда, аны туктатып, –Кара әле, Хәмит агай, ул юлның бик тар җирләре бар, эшләгәндә сак бул, шәйләп эшлә!– дип кисәтеп куйды.

– Эшләрбез, борчылмагыз, иптәш директор! – диде Хәмит агай. Ул гаражга барып, ДТ-54 тракторына кирәген эләктерде дә, АЗСка барып ягулык тутырып, тракторын иртәнгә әзерләп куйды.

Иртәгәсе көнне Хәмит агай, әйтелгән урынга килеп, эшкә тотынды. Ул шул кадәр мавыгып эшләде, тракторыннан төшми, тәмәкесен дә руль артында гына тартып,

шактый күп араны кистереп, кырдыртып, тигезләп үтте. Хәтта хатыны Рәйсә җибәргән төшке ашын да тиз-тиз генә ашап, җиң сызганып, кабаттан эшкә тотынды.

Елга ярына якын булган тар араны, тау итәген кистерергә кереште. Тау итәгендәге кечкенә ялан буеннан биш-алты тапкыр узганнан соң, тагын бер кат үтәм дә, тигезләп алырмын дип, үз алдына сөйләнә-сөйләнә бераз сул як юлны киңәйтеп килгәндә, ниндидер сөякләр килеп чыкканын кабинасының ачык ишегеннән күреп алгач, тракторын сүндереп, сикереп төште, кистергән җиргә килеп, аптырап калды.

– Бу нинди җир? Нинди сөякләр булырга тиеш? Әллә зират урыны булган җирме?-дип эшен туктатырга уйлады. Хәмит агайның эше ничек бара икән?– дип кызыксынып совхоз директоры үзе дә килеп җитте. Ул УАЗыннан төшеп, Хәмит агай янына юнәлде.

– Молодец, Хәмит агай, тигезләп киткән юлыңнан шул кадәр күңелле баруы!– дип аның аркасыннан сөеп куйды. Ул Хәмит агайның ниндидер борчулы, сәер кыяфәтен күреп:

– Ни булды? Әллә тракторың ватылдымы?– дип сорады.

– Юк, ватылмады, иптәш директор, менә, килегез әле, карагыз, күрәсезме? Бу бит кеше сөякләренә ошый. Монда бит кайчандыр исә каберлек булган шикелле. Сөякләр дә гади кешенекенә ошамаган, әллә нинди эре сынлы сөякләр,-дип бульдозер көрәгенә эләгеп чыккан сөякләргә күрсәтте.

Совхоз директоры якынрак килеп карады да кеше сөякләре икәнлегенә тәмам ышангач, Хәмит агайга эшен туктатып торырга кушты, ә үзе тиз генә УАЗга утырып районга китте. Районда бу сәер хәл турында сөйләгәч, анда зират урыны булырга тиеш түгел дигән уйга килеп, башкалага, археологларга хәбәр итәргә булдылар.

Икенче көнне Уфадан биш-алты кеше килеп тә төште. Хәмит агайның сөякләр тапкан урынын җентекләп караганнан соң, аларда кызыксыну уянды. Алар җиң сызга-

нып эшкә дә тотындылар. Күренеп торган сөякләрнең өстеннән җир катламын сак кына кырып алдылар да пумалалар белән тазартып карый башлагач, табылган сөякләр, гади кешенекеннән үзенчә аермалы, бик озын гәүдәле кешенеке булып чыктылар. Бер атнадан артык тикшеренүләр барды. Бу урында егерме кеше сөяге табылды. Шунысы кызык, алар бер-берсеннән ерак түгел, бер метр чамасы арада күмелгәннәр. Шундый җыйнак итеп җирләнгәннәр. Башлары белән төньякка Чаган-Тауга таба салынганнар.

Табылган сөякләрнең һәрберсенең ике беләгендә дә бакырдан эшләнгән беләзек кидерелгән. Авызларындагы барлык тешләре дә тулысынча сакланган. Уң як кулларына янәшә, шулай ук бакырдан, бронзадан эшләнгән сөңге



уклары ята. Аларның баш очыннан бер метр чамасы алда, берсе аерым күмелгән, аның янында ат башы һәм бакыр бронзадан эшләнгән тезгеннәр салынган. Анысы инде хәрби җитәкчеләре булырга тиеш.

Археологлар җитәкчесе, болар бакыр буат чорындагы сугышчы егетләрнең бер отряды булырга тиеш, дип аңлатты. Күрәсең, алар бәрелеш вакытында һәлак булып, шушында җирләнгәннәр. Шулай итеп XIX гасырның икенче яртысында табылган сөякләр моннан берничә мең еллар, бакыр буат заманында яшәгән кабиләләр булырга тиеш.

Археологлар килеп чокыды,
Чаган-Тауның кырыннан,
Табылды корбан сөяге,
Бакыр буат чорыннан.
Таш-Елгадан ерак түгел,
Бүә суы буенда,
Егерме корбан җирләнгән,
Яңавылның җирендә.
Кемнәр алар, каян килгән?
Беркем белми аларны,
Кем җирләнгән, кем җирләгән,
Урысмы ул, татармы?
Яшь сугышчы корбаннарны,
Тезеп салганнар җыйнак,
Яннарында сөңге ята,
Очлы ук бакыр сымак.

## Сәер юлчы

Якшәмбе көнне Гомәр бик иртә уянды. Тиз генә сикереп торды да ишек алдына чыгып китте. Ишек алдында торган "Нива"сының, болай да сәгать кебек эшләсә дә, төзеклеген тикшерде, машинасының капотын япты да өйгә кереп иптәше Зөһрәне чакырырга булды. Бу көнне Гомәр үзенең сөекле тормыш иптәше Зөһрәне, әниләренә өмәгә, түшәм юарга илтеп куярга тиеш иде. Өйгә кереп:

– Зөһрә ханым, такси чакырткан идегезме?– диде шаяртып.

– Әйе, кичтән үк сөйләшеп куйган идем таксист белән,– дип җавап бирде Зөһрә шулай ук шаярып.

Алар бергәләп чәй эчеп алдылар.

Гомәр спортивный курткасын алды да кесәсендәге документларын барлагач:

– Зөһрә, мин сине машинада көтәм, җитешү белән үзең чыгарсың,– дип машинасы янына чыгып китте. Зөһрә чыгуга, Гомәр машинасын кабызып, урамга чыгарып куйган иде инде. Гомәр әкрен генә кузгалды да бераз баргач, тизлеген арттырып, барасы якка таба борылып китте. Асфальт юлга чыккач ул тизлекне тагын да арттыра төште. Зөһрә белән үткәннәрне сөйләшеп бара торгач, Гомәр әбиләренә килеп җиткәнне дә сизми калды.

Гомәр машинасын капка төбенә китереп туктатып, әнисенә күчтәнәчләр салынган сумкасын Зөһрәнең кулыннан алды да капкадан кереп китте. Машина тавышы ишетеп, Зөһрәнең әнисе балаларын баскыч башыннан каршылап көтеп алды.

– Әйдәң, әйдәң, исән-сау гына килеп җиттегезме? – дип сорады Зөһрәнең әнисе.

– Аллага шөкер! – диде кияве Гомәр

Алар өйгә кереп хәл-әхвәл сораштыргач:

– Мин озак тора алмыйм, әби, хәзер кайтып китәм, өйдә эшләрем күп,– диде Гомәр.

– Ярый, хәерле юл, исән сау гына кайтып җит, – дип Зөһрә урамга ирен озата чыкты.

Гомәр хушлашып, кузгалып китте.

Асфальт юлга чыккач, ул машинасының мотор тавышына кушылып "Сарман буйкайлары" көен авыз эченнән генә көйләп җибәрде.

Айбүләк авылы янындагы автобуслар тукталышына якынлашып килгәндә, кырык биш-илле яшьләр чамасындагы, өстенә кара бишмәт, аягына кирзы итекләр кигән, ялан баш, чәчләре тузган бер ир кеше кулын болгый-болгый машина каршысына чыгып басты. Гомәр, машинасының тизлеген киметеп, аның янына килеп туктады. Кулын болгап торган кеше машинаның ишеген килеп ачты да, исәнлек-саулык сорамыйча гына, кабинага кереп утырды, әйтерсең лә ул күптән машина чакырткан.

– Миңа Карманга,– диде бу ир Гомәргә. Аның авызыннан ачып чыккан күәс апрасы исләре килеп бәрелде. Шул ис бөтен салон эчен тутырды. Гомәрнең кисәк кенә кәефе китте, күңеле төште. Әмма түзде, юлчыны куып төшермәде. Аның моңа намусы җитмәде. Ул бу кешегә ачулы гына кыяфәт белән күз ташлады, аның бишмәт якасындагы яшел яфрак төсендәге эмблемасын күреп, бу кеше урман каравылчысыдыр, дип уйлап куйды. Бара торгач юлчы сүз башлап җибәрде.

– Менә, энекәш, хәзер халык бозылды, бик начарланды, наглыйга әйләнде, демократия дип бөтен урманны талый башладылар. Сораусыз-нисез, документсыз урманга керәләр дә күпме кирәк урманны кисәләр. КамАЗы-КамАЗы белән төяп ташыйлар,– дип зарланды. – Урманның экологик яктан файдасы барлыгын бөтенләй оныталар. Кырып бетерделәр инде урманны, нәрсә калыр инде балаларга, нинди экология булыр?– дип өстәп куйды юлчы.

– Ә син, менә кичтән аракы ишкәнсең дә иртәнге сәгатьтә торып баш төзәтеп чыккансың. Әллә үзеңнең хәләл акчаңа аракы сатып алып эчеп йөрисеңме? Гомерең буена агач сатып эчеп йөргәнсеңдер әле, – диде Гомәр болай да ачуланып барган җиреннән.

– Юк, энекәш, бу юлы мин агач сатмадым, бер ЗИЛ машинасы гына утын биреп җибәргән идем дус кешемә. Ничек инде бирмисең үзеңнең танышыңа, бирдем инде, – диде урман каравылчысы.

– Барыгыз да бергәлешеп талыйсыз урманны. Ә үзең тагын хурлап барасың, экология! – дип ачулы гына әйтеп куйды Гомәр.

– Тукта әле, исемең ничек әле синең?– дип каты гына сорый башлады Гомәр юлчыдан.

– Ярый инде, энекәш, җитәр, нигә кирәк инде минем исем сиңа?-диде ул. Бераз баргач, Карман авылына җитәрәк, урман каравылчысы Гомәрнең тәнкыйтен тыңлап барырга түземлеге калмагач:

– Энекәш, менә монда машинаңны туктат әле, зинһар,– дип сорады.

Гомәр аның күңеле болганадыр, дип машинасын юлның уң як читенә чыгарып туктатты. Юлчы кабинадан төште дә утыртылган агачлар арасына кереп китте. Озак кына чыкмый торгач, Гомәр аның артыннан керергә булды. Теге сәер юлчыдан җилләр искән иде. Агачлар арасындагы саф һаваны урман каравылчысы авызыннан чыккан әшәке исләр бөтереп алды, урман ямен җибәрде, экологияне бозды.

Гомәр кычкырып-кычкырып чакырып карады аны, бернинди дә җавап булмагач, кире машинасына килеп утырды да көлә-көлә Әмҗе авылына таба юнәлде.

– Менә сиңа эколог,-диде Гомәр. Күрәсең, урман каравылчысы Гомәрне берәр зур түрә, дип уйлады, әләгермен, тикшерә башлады, я хөкем итәрләр, сыпыртыйм әле, дип утыртылган агачлар арасына кереп шылды бугай.

# Башкача кабатланмас

Рамуз "Урал" машинасы белән эшчеләрне Графск промыселенә илтеп куйгач, мастер янына кереп путевкасына тамга салдырды да озак та тормый кире борылып базага кайтырга чыкты.

Промыселдан барып борылып килгәнче нибары унбиш-егерме минут вакыт узгандыр. Чөгәнәк авылы турысыннан бер-ике километр баргач, Рамуз юлның чокырлы җирләрен тигезләү өчен салынган гравий өемен узарга дип килгәндә, алда гравий өеме артында яткан мотоциклны күреп алды. Ә аннан ерак түгел генә бер кеше гәүдәсе яткан җиргә күзе төште. Машинасын туктатып, моторын сүндерде дә, мотоцикл янында яткан кеше янына килеп, аның хәрәкәтсезлеген күргәч, үлгән дип исәпләде. Рамуз кире машинасы янына килеп, кабинасын ачып керде дә рация трубкасын алып диспетчерга:

– Минем алда, юл уртасында үлгән мотоциклчы ята. Чөгәнәк авылыннан ерак түгел, бер-ике километр чамасы бар Арлан подстанциясенә таба. Унбиш-егерме минут үткәндер мин вахта белән узганда берни дә юк иде, күрәсең, мотоциклчы без узып киткәч Чөгәнәк авылыннан чыккан,– дип аңлатып бирде Рамуз. "Ярый, хәзер милициягә хәбәр итәм, алар килгәнче торып тор, китмә. Маҗара булган урынны сакла. Сине гаепли күрмәсеннәр!"– диде диспетчер.

Күп тә үтмәде, ике яктан да машиналар килеп туктады. Шоферлар, пассажирлар машиналардан төшеп, маҗара булган урынга җыелып, кызыксына башладылар. Araларыннан берсе:

–Бу кеше үлгән бит! Милиция чакыртырга кирәк!– диде Рамуз аларга:

– Мин рация буенча милиция чакырттым инде, хәзер килеп җитәргә тиешләр!– диде. –Дежурный телефоннан хәбәрне алгач, эчке телефон аркылы тикшерүче Исеметовка юл маҗарасы турында хәбәр итте.

Тикшерүченең папка кыстырып килеп кергәнен күргәч автоинспектор:

– Иптәш Исеметов, нәрсә булган тагын?– дип сорады.

– Арлан–Графск юлында үлгән мотоциклчыны тапканнар, җыеныгыз!– диде.

– Авария урынына бару өчен машина табу синнән инде!– диде тикшерүче.

– Ярый, әйдә, машина табарбыз! – диде капитан. Дорожный урамына таба юнәлеп. Бераздан УАЗик машинасын туктатып:

– Энекәш, безне Чөгәнәк авылы турысында булган маҗара урынына илтеп куй әле,– дип үтенде.

Маҗара булган урынга килеп җиткәндә бик күп машиналар җыелган иде. Автоинспектор белән тикшерүче килеп күренгәч шоферлар:

– Безне тизрәк үткәреп җибәрегез, ашыгабыз, соңга калабыз!— диештеләр.

– Ярый, хәзер үтәрсез, озак тотмабыз, күпкә түзгәнне азга түзәрсез инде!– диде автоинспектор. Ул арага кереп:

– Кем беренче булып күрде?– диде, җыелып торган кешеләргә карап. Рамуз алга чыгып:

– Мин беренче күреп килеп туктадым,– диде.

– Сәгать ничәләрдә булды бу хәл?

– Бер сәгатьтән артык буладыр инде хәзер.

Автоинспектор тикшерүдә катнашкан кешеләрдән йөз түбән яткан мотоциклчының гәүдәсен әйләндерүләрен үтенде. Әйләндереп салгач мотошлем каешы муенын буганга, йөзе көп-көрән төскә кергән, бите шешенгән, авызыннан күбекләр чыккан, аягындагы туфлиләре салынып икесе ике якка очкан, кулмәге күтәрелеп култык астына кысылган, тәнендә хисапсыз чирки, чебен кунган, карарга куркыныч иде. Бер сәгатьтән артык буылып яткан мотоциклчының каешын ычкындырып шлемын салдыргач:

– Уф! дип көрсенеп куйды, тын алып күзләрен ачып җибәрде. Берничә секундтан соң кан сауган йөзе агара башлады. Янында басып торган кешеләргә карап ятканнан соң кинәт кенә сикереп торды да, сазлык өстеннән юлдан ерак түгел генә куакларга таба йөгерде.

Терелгән мотоциклчы артыннан нәрсә әйтергә дә белми, халык аптырашып, авызларын ачып карап калды. Мотоциклчы куаклар янына барып җитте дә туктап калды. Кинәт кенә борылып юл өстендәге кешеләргә карый башлады. Автоинспектор аңа кул болгап:

– Әйдә, энекәш, кил безнең янга,– дип чакыра башлады. Ул егерме-егерме биш яшьләрдәге яшь кенә, кара чәчле чибәр егет булып чыкты.

Халыклар җыелышып торган җиргә егет кире килеп:

– Тартырга бирегез әле,-дип тәмәке сорады. Тикшерүче кесәсеннән сигарет пачкасын чыгарып мотоциклчыга сузды. Сигаретын кабызып берничә мәртәбә каты гына итеп суыргач:

– Нәрсә булган монда? Нигә кешеләр җыелган?– дип сорады.

– Без синнән сорарга тиеш нәрсә булганын! Син әйт, син бит монда үлеп ята идең, әнә мотоциклың ята!– диде автоинспектор.

Мотоциклчы сигаретын тартып бетергәч бераз уйланып утырганнан соң аңына килеп:

– Ә, ә мин мотоциклдан егылганмын бит,-диде.

– Исемең кем була? Кайсы авылдан син? Кая бара идең?

– Мин Ришат исемле. Үзем Кәчәүдә яшим. Чөгәнәк авылына картыйга сарай түбәсен ремонтлап бирергә дип килгән идем. Иртән эш тәмамлангач картый бер стакан үзе ясаган аракы салып биргән иде. Берникадәр вакыт үткәч кайтырга булдым. Мотоциклыма утырып авылдан чыгып киттем. Көн җылы, кәеф күтәренке, кояш балкып тора, мотоциклым әйбәт эшли. Күрәсең, кызурак киткәнмен, менә соңыннан нәрсә булганын хәтерләмим,– диде.

– Кай җирең авырта?-дип сорады автоинспектор.

– Юк, юк, бер җирем дә авыртмый!– диде Ришат.

– Кәчәүгә кайтып җитә аласыңмы?

– Кайтып җитәм, үземне әйбәт хис итәм, бер җирем дә яраланмаган,– дип Ришат барып мотоциклын бастырып юл читенә куйды. Автоинспектор җыелган машиналарны уздырып бетергәч:

– Кил әле, Ришат, минем янга,-дип чакырып алды. Менә документларың, мотаеңа утыр да сыпырт моннан, башкача Габдрахман Кадыйров кебек йөрмә.

– Ярый, әкрен йөрермен, бүтән кабатланмас!– диде егет сөенеченнән.

Ришат документларын алып кесәсенә салып куйды да, мотоциклын кабызды. Бер-ике кабат газовать итеп алганнан соң мотоциклына менеп атланды да:

– Иптәш капитан, сиңа бик зур рәхмәт. Мине әҗәлдән коткарып алып калган өчен мин сине бервакытта да онытмам!– дип саубуллашып, кузгалып китте. Аның артыннан тузан гына күтәрелеп калды.

# Тәвәккәл булсаң табыла

Берчак милициядә дежур торучыга ягулык ташый торган машина куылуы турында хәбәр килде.

– Ярый, хәзер хәл итәрбез! – диде дежурный телефон трубкасын салып. Рәттән торган рациядән:

– Барлык постларның игътибарына, 59-47 БАУ, ГАЗ-51 маркалы, ягулык ташый торган машинаны куганнар, дип җиткерде. Тагын да телефон трубкасы шалтырады. Бу юлы Ленин исемендәге колхоз рәисе шалтырата иде:

– Нефтекамск-Яңавыл юлында, Раздолье елгасының күперен чыгып, тау менгәч, малчылык комплексына борылганчы, юлның сул ягында ягулык ташый торган машина авып ята. Җәрәхәтләнгәннәр турында әйтә алмыйм, кешеләре күренми,– диде ул.

– Аңладым сезне, рәхмәт, хәзер безнең хезмәткәрләр чыгарлар,-диде, өлкән лейтенант Сабиров, ул эчке телефон трубкасын алып ГАИ начальнигы белән элемтәгә керде:

– Иптәш капитан, Нефтекамск–Яңавыл юлында маҗара. Куып алып киткән машина белән юл читеннән төшеп ауганнар.

– Яраланучылар бармы икән?

– Әлегә билгеле түгел, кабинада беркем дә юк, диделәр. Мин тикшерүчегә хәбәр иттем.

– Яхшы, хәзер җыенам,– диде капитан. Ул папкасын һәм оперативный сумкасын эләктереп икенче каттагы тикшерүче бүлмәсенең ишеген барып ачты. Күптән түгел генә югары уку йортын тәмамлап килгән яшь кенә кыз үзеннең кәгазьләрен актара иде.

– Сезгә дежурный маҗара турында хәбәр иттеме?– дип сорады капитан.

– Әйе, шалтыратты, мин әзер, хәзер чыгам,-диде.

– Яхшы, сезне урамда көтәм!

Урамга чыгып күп тә тормады, шул арада бүлек каршысына бер “Волга” килеп туктады, кабинасыннан УБР начальнигы урынбасары килеп чыкты, капитанга кулын биреп:

– Хәерле көн!– дип күреште.

– Безнең өчен бик хәерле түгел әле!

– Нәрсә булды?

– Күптән түгел генә билгесез кешеләр машина куып алып китеп аударганнар. Сез Рәҗәп әфәнде озаккамы? Кем янына килгән идегез?– дип сорады капитан.

– Мин угрозыск начальнигы Мусин янына килгән идем,–диде.

– Бәлки безгә машина белән булышырсыз? Милициянең транспортка кытлыгын үзегез да беләсез бит...

– Яхшы, барыгыз, дип Хәсәнов шоферына боерык бирде дә Мусин янына кереп китте.

Тиздән тикшерүче кыз да килеп чыкты. ГАИ начальнигы "Волга"ның арткы ишеген ачып:

– Рәхим итегез, Илүсә ханым!-дип чакырып утыртты, үзе шофер белән янәшә утырды.

– Кая барабыз?-дип сорады "Волга" шоферы.

– Нефтекамск–Яңавыл юлына, Раздолье күпереннән ерак түгел.

Шәһәрне чыккач "Волга" коры асфальттан җилдертте генә. Машинаның ачык тәрәзәсеннән кергән җәйге җылы, саф һава күңелгә бер төрле наз бирде. Раздолье күперен чыгып, үргә менеп берникадәр баргач капитан юлның сул ягында авып яткан машинаны күреп:

– Әнә ята!– диде. "Волга" шоферы маҗара булган урынга берничә метр барып җитмичә, юл кырыена килеп туктады.

Тикшерүче сумкасыннан протокол бланкаларын алды да, сумкасын "Волга" кабинасында калдырып, автоинпектор янына килеп, маҗара булган урынны тикшерергә тотынды.

Машина куучы юлдан ерак түгел генә урманда, агач арасында качып, кемнең нәрсә эшләгәнен күзәтеп утырган икән. Бары да машинадан төшеп киткәч, иелеп, әкрен генә, мәче сыман килеп, тикшерүченең сумкасын эләктереп, кире урманга качканда "Волга" шоферы күреп калып кычкырып җибәрде:

– Әнә берәү кабинадан сумка алып, урманга йөгерә!-диде. Автоинспектор күреп алып аның артыннан:

– Тукта, тукта!– дип кычкырса да, теге кеше борылып та карармады, урманга кереп шылды. Тикшерүче агарынып катып калды:

– Минем сумканы алган, минем анда партбилет, шәхси таныклык, документ һәм башкалар бар иде,– диде.

Автоинспектор аңа карап:

– Шулай, эшләр харап, шәптән түгел алайса,– диде.

Үз гомерен милиция эшенә багышлаган капитан, тиз арада чара күрүнең әһәмиятен нык аңлый иде. Ул менә шушы очракта үзенең тәвәккәллеген күрсәтте. Юлга чыгып басты да Карман ГРЭСы ягыннан вахта эшчеләре белән кайткан ике автобусны туктатып салон эченә керде һәм:

– Иптәшләр, әле генә машина куып алып киткән кеше “Волга” машинасы кабинасыннан документлар алып урманга кереп качты, шуны тотарга ярдәм итүегезне сорыйм,-диде. Автобус эчендәге яшь егетләр тиз арада ризалашып автобустан сикерешеп төштеләр. Автоинспектор икенче автобуска барып шуны ук аңлатты. Барысы да төшеп бер урынга җыелгач:

– Урманны уратып алырга кирәк, аралар бер-ике метрдан артык булмасын, ул ерак китәргә тиеш түгел,– дип аңлаткач илледән артык кеше урманга таба йөгерделәр.

Ун минут та үтмәгәндер, биш-алты егет кереп качкан кешене тотып, өстерәп тә алып чыктылар.

– Менә, иптәш капитан, куак арасына куян кебек кереп поскан, без якынлаша башлагач, сикереп торды да йөгерә башлады, көчкә куып тоттык!-дип китереп бастырдылар. Аның авызыннан аракы исе аңкып тора. Чәчләре тузып беткән, өстенә кигән спорт костюмы, трикосы катып беткән, сакалы-мыегы җиткән иде.

– Машинадан алып сумканы кая куйдың-дигәч:

– Бернинди дә сумканы белмим! Күрмәдем дә! Аңламыйм да!-дип оятсыз кыяфәттә әйтеп куйды. Аны тотып алып килгән егетләр арасында Афганстан сугышында катнашканнары да бар икән. Алар теге оятсыз, шома кешене сумканы кая куйганын тиз арада әйттерделәр.

Ул сумканы кая куюын, үз гаебен үзе таныгандай, ашыгыч күрсәтергә булды. Аны егетләр тагын җитәкләп урман эченә алып кереп киттеләр.

Бер йөз метр чамасы үткәч, агач төбенә яшереп, абага үләне белән өеп куйган җирне күрсәтте. Сумканы үзенә тоттырып кире алып чыктылар. Арадан берәү таза гына гәүдәле чибәр егет, качкыны тикшерүче янына алып килеп сумкасын бирдертте һәм гафу үтендерде. Машины куып алып китеп аударганы турында да үзенең гаебен таныды.

Тикшерүченең күңелләре күтәрелеп китте, йөзе ачылды, ярдәм иткән егетләргә зур рәхмәт бедерде.

Сөйләшеп куйганча, эзләргә кереп киткән кешеләр өч тапкыр озын итеп машина сигналын ишеткәч, янә җыелырга тиешләр иде.

Сигнал тавышын ишетеп барысы да урманнан чыгып, автобуска төялеп шәһәргә кайтып киттеләр.

Шулай итеп, капитанның тәвәккәллеге аркасында гаепләнүче дә, сумка да тиз арада табылды.

## Көтелмәгән "сыйлаучы"

Эш сәгате тәмамлангач, Рәмил автозавод проходноеннан чыкты да кайтырга торган танышларын күреп яннарына барып басты.

Аларның күтәренке кәефләрен күреп:

– Сәлам, егетләр! Хәлләрегез ничек?– дип әңгәмәгә керде.

– Привет, Ромка, әйдә безнең белән, сообразить итәбез,– дип куйды берсе. Икенчесе кесәсеннән яртылаш калган аракы шешәсен тартып чыгарды да, кәгазь стаканга салып өләште. Шайтан суы кергәч, берничә минуттан Рәмилнең тамак төбе кытыкланды, барыннан да артыграк сөйләнә башлады.

– Әйдәң әле, егетләр, тагын кабатлап алыйк!– дип котыртып куйды. Җитми калгач тагын аракы табып кабатладылар. Монысы да җитми калгач:

– Бүген минем дус малайның туган көне, шунда барып өстәп алабызмы? – дип тәкъдим ясады берсе. Бары да ризалашып, эт өере кебек җыелышып автобуска утырып "Төзүчеләр" тукталышына килеп төштеләр.

– Туган көнгә буш кул белән кереп булмый, Рәмил, бар, бер ярты кереп ал, – дип аңа басым ясап кибеткә кертеп җибәрделәр. Теләр-теләмәс кенә кереп, болай да саран кеше, иң арзан "Бәләбәйский" дигән аракы алып урамга чыкса, иптәшләреннән җилләр искән иде. Алар Рәмилне бик ышанычлы булмаганга, күп сөйләнгәнгә, читләшеп ташлап киткәннәр. Артларыннан керергә, тегеләрнең адресын да, кайда яшәгәннәрен дә белми, бераз басып торганнан соң: "Тукта әле, минем бит моннан ерак түгел генә бер танышым бар, шунда кереп сыйлап чыгыйм әле үзен!", дигән фикер белән танышына китте. Таныш дип йөргән кешесенә бер-ике тапкыр үзенең кирәкле йомышын эшкә ашырырга гына кергәне булды. Бик күптәннән күргәне булмаса да, кайда яшәгәнен онытмаган икән әле. Килеп звонокка бик озак кына басып торганнан соң, ишек ачылып:

– Сезгә кем кирәк?– дип сорады хуҗабикә.

– Мин Рәмил булам, апа, сезнең иптәшегезнең дусты.

– Ул өйдә юк,– дигәч тә, Рәмил мәҗбүри рәвештә хуҗабикәне этеп кереп, полиэтилен пакетын ишек төбенә идәнгә куйды да, аның өстенә курткасын салып ташлады.

– Мин хуҗаның кайтканын көтәм әле!– дип, түр бүлмәгә узды да, диванга кырын ятып, телевизор карый башлады. Озак та үтмәде, ишектә хуҗа күренде. Рәмил диваннан сикереп төшеп ишеккә таба юнәлде.

– Әй, якташ, хәлләр ничек? Тазалыкмы?– дип хуҗаны кочаклап алып, аракы йомшарткан күңелләрен тыя алмыйча елап ук җибәрде. Әйтерсең лә, әллә ничә еллар бер-берсен күрмәгән туганын очраткан!

– Әйдә, әйдә, чишен, мин сине сыйлыйм әле,– дип идәндәге пакетыннан "Бәләбәйский"ны тартып чыгарды да:

– Әйдә, хуҗабикә, безгә закуска әзерләп бир әле, дус белән сыйланып алыйк,-дип Рәмил хуҗабикәгә боерык бирде.

Хуҗабикә Рәмилнең елап та алганын күреп, болар чыннан да дуслардыр дип тиз-тиз генә өстәл хәстәрли башлады. Рәмил яртысын өстәлгә китереп утыртты да пробкасын ачып, үзенең рюмкасына тулар-тулмас итеп "Бәләбәйский"ны иләп кенә салды да берсүзсез эчеп тә куйды. Хуҗа белән хуҗабикә бер-берсенә сәер генә карашып иңбашларын сикертеп куйдылар. Эчеп алгач, тегеләй дә теле телгә йокмаган Рәмилнең сүзе тагын да күбәеп китте. Һич кенә дә туктатып булмый бит. Политикага да кысыла, авылларында салынган мәчеткә дә, бер абыстайны хаҗга барып кайткан өчен мулла итеп сайлап куйганнары, үзенең бер яртыга мәчеткә электр кертеп йөргәннәре турында да озак итеп тәфсилләп сөйләде. Хуҗалар аның сүзен бүлдермичә ризалашып тыңлап утырдылар.

Ул шешәсен алып тагын рюмкасын тутырып салды да, аптырап карап утырган хуҗага:

– Әйдә әле, якташ, сине дә сыйлап алыйм әле! – дип хуҗаның рюмкасына да яртылаш аракы койды. Бернәрсә дә аңламаган хуҗа эчсә дә эчте, эчмәсә дә эчте. Сыйларга килгән кунак, салган рюмкасын эчеп куйды да тагын сүз башлап "рамка"сыннан чыга башлагач хуҗа:

– Ярый, Рәмил, сыйлавыңа бик зур рәхмәт! – дип аны бүлдерде.

Аңлап алгач теге:

– Ярый, мине өйдә югалтканнардыр,– дип өстәлдәге бөкене алып калган "Бәләбәйский" горлышкасына борды да, барып идәндәге кара пакетына салды. Курткасын киеп, ишек төбендәге пакетын алып, "мин тайдым!" – дип саубуллашмыйча да чыгып китте.

Эчтәлек бит

Акчарлаклар....4
Авыр икән көтүе....4
Ачы җилләр....4
Болын чәчәкләре....5
Гайбәтчеләр....5
Күбәләк карлар....6
Гаделсезлек....6
Көзге каеннар....7
Көнбагышларым....7
Айлы төндә....8
Зариф мулла вәгъдәсе....8
Матайкаем....9
Оҗмах түрен күрерсең....10
Сынау....10
Серле карашың....10
Серләшәм төрле хакта....11
Сандугачым....11
Төнге учаклар....12
Төпчек кызым Гөлнара....12
Туган ягым....12
Ялвару....13
Скандинавия циклоны....13
Ялкын сибә йөрәгем....14
Яңавылым....14
Ялкыннарга салмасаң....14
Закир карак....15
Хыянәтчеләр....16
Карлыгачым....18
Яшьлек уза....19
Ак томан....19
Их, Бүә сулары....19
Пар умырзая....20
Син гөлем, сипкеллем....21
Даян хәсрәте....21
Таң чыклары....22
Трудармия....22
Мәктәп еллары....24
Күбәләгем....24
Юбилей....25
Тукран тәүбәсе....26
Танып кызы....26
Сәлим җизни....27
Ак томаннар....27
Дуслар....27
Күк күгәрчен....28
Ал чәчәгем....28
Шофер....29
Күрше карчыгы....30

Скрипкам....30
Яңа ел бүләге....31
Үзсүзле хатын....31
Яңа ел теләкләре....32
Тибрәттең кылларымны....32
Туган җирем Яңавыл....32
Син ник күренмисең....33
Минем холкымда казынма....33
Рәйнә....34
Урман....34
Хәерле иртә....35
Мотор җыры....35
Зифа каеннар....35
Кар бабай....36
Көз....36
Замполит....36
Мәрхүм әнием....37
Кара чебен....37
Гөлчәчәгем....38
Мәхәббәт тә булмый курыксаң гөнаһтан....38
Бюрократин....39
Җирне ямьләп, үсә шаулап....39
БЮРО....39
Кайчан җылытыр көннәр?....40
Сабырлыгыма киңәш....41
Кәккүк тавышы....41
"Инеш"....41
Бер күрүдә яраттым мин....42
Җәннәт Эль Асма....42
Йолдызларга очардай булам....43
Куллары корышсын иде....43
Йөгәнләсәм яшьлегемне....43
Гомәр....44
БЮРО....45
Узган гомер, үткән юллар....45
Медицина кызлары....45
Нәфсе....46
Шатлыгыма сыймадым....46
Яңгыр....46
Кордашларым....46
Кыр казлары китте....47
Газиз әнкәм бирешмәде....48
Алланы искә алып....48
Хәйрүш....48
Чын мәхәббәт....49
Серне чишсәң дә ярый....50
Качкылыкта үткән гомер....59
Бил каешы сынатты....74
Кызгылт-сары буяу....80

........................................................................86
Бер савыт гөл........................................................................94
"Мәчтүрә" әби........................................................................99
Чаган-Тау серләре........................................................................103
Сәер юлчы........................................................................106
Башкача кабатланмас........................................................................109
Тәвәккәл булсаң табыла........................................................................112
Көтелмәгән "сыйлаучы"

Литературно-художественное издание

**Белалов** Вакиль Салахович

ТАЙНУ МОЖНО И РАСКРЫТЬ
Стихи, проза

Ответственный за выпуск В. С. Белалов
ГУП РБ "Нефтекамская городская типография"
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Белалов** Вәкил Сәләх улы

СЕРНЕ ЧИШСӘҢ ДӘ БУЛА
Шигырьләр, хикәяләр

Чыгарылыш өчен җаваплы В.С. Белалов. Мөхәррир Ф.М. Садыйкова. Техник мөхәррир Т.П. Яникиева. Тышлыкны бизәүче Р.Р. Ситдиков. Н. В. Билалов сүрәтләре. Корректор Ф.М. Садыйкова. Компьютерда җыючы һәм версткалаучы Ф. Г. Әхмәдишина.

Җыюга тапшырылды 02.04.04 ел. Басарга кул куелды 12.07.04 ел. Форматы 60х84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. "Школьная" гарнитурасы. Ризографта басу. Шартлы басма табагы 6,74. Нәшер-хисап табагы 6,20. Тиражы 200. Заказ 1702.

БРның "Нефтекама шәһәр типографиясе" ДУП
452684, Башкортстан Республикасы, Нефтекама шәһәре, Социалистик урамы, 29.
Тел. 4-32-90, факс 4-11-70. E-mail:ngt@bashnet.ru.